ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN
ISSN 0130-2418
1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
№ 10 (357)
ОКТЯБРЬ 2021

ҖАНИСӘП: VIP-ЯКТАШЛАРЫБЫЗНЫ БАРЛЫЙБЫЗ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Авторлар: Илдус Зәһидуллин, Ксения Сёмина,
Луиза Шарова
Фотографлар: Александр Ефремов, Илнар Өметбаев
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Олег Бурилов
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыктагы фотода: «Төньяк елга флоты» АҖ генераль
директоры Айрат Чумарин

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: Е-3423
Басарга кул куелды: 22.10.2021
Басмадан чыкты: 28.10.2021
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79
Коммерция директоры:
Юлия Фасахова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә

Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

БАРЫСЫ ДА ЯХШЫ БУЛАЧАК!

Шулай килеп чыкты ки, безнең «ковид мена-менә бетәчәк» дигән фаразларыбыз башта әкрен генә «кайчан бетә инде бу ковид» дигән билгесезлеккә, ә хәзер «гомумән берәр вакыт бетәрме икән ул...» дигән салкын пессимистларча уйларга барып җитте. Инде нишләргә? Паникага бирелеп, кул кушырып утырыргамы? Нинди мәгънә? Давыллы туксанынчы елларны кичергән буын хәтерли: өметсезлек һәм акчасызлык ул вакытта сәламәтлекне, көчне теләсә кайсы вирустан да яманрак бетерде. Ләкин хәтта ул чакта да зирәк кеше табылды. Төнлә Казанның Ибраһимов һәм Декабристлар урамнары чатындагы мәңгелек төзелешне каплап торган коймага зур хәрефләр белән: «Люди, все будет хорошо!» дип язып куелган иде. Әлеге язу кешеләргә меңләгән психологның уртак хезмәтенә караганда йөз мәртәбә күбрәк тәэсир итте. Мөгаен, шуңа күрәдер әлеге язуны бетереп ташлау уе беркемнең дә башына килмәде. Язу, заманалар рәтләнгәнче, шомлы туксанынчы елларда казанлыларны рухландырып торуын дәвам итте.

Безнең куркулар да кайчан да булса бетәр. Иң мөһиме, ышаныгыз: барысы да яхшы булачак! Һәм тагын: прививка ясатыгыз!

Сезнең оптимист редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **960 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «ТАТАРСТАН» журналына

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары тик ТАТАРСТАНДА

АЛМАЗ КЕШЕ

Кайчандыр Татарстанда эшләгән күренекле җитәкчеләр арасында уникаль кыйммәтле ташка исем биргән шәхес тә бар. Якутиядә табылган 64,47 каратлы алмазга легендар идарәче, мәңгелек тунда дөньяда беренче ГЭС төзегән, ә аннан соң КАМАЗ заводлары корпусларын һәм Чулман ярында шәһәр салган җитәкче – Евгений Батенчук исеме бирелә. Ул «Камгэсэнергострой» җитәкчесе булып 25 ел хезмәт куя. Яр Чаллы һәм Ленск шәһәрләрендә аңа һәйкәлләр куелган, Арбузовның «Иркутская история» пьесасы, Видрашкуның «Набережная надежды» романы һәм җиде повесте аңа багышланган. «Дорога» нәфис фильмындагы төзелеш җитәкчесенең образы аның үрнәгендә язылган.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Мәскәүгә! Мәскәүгә!
Ни өчен безнең кеше капиталы гел кирәк

6. Яшьләрчә рухлы һөнәрмәнд
Россия күләмендә кем Татарстан тәҗрибәсен таратачак

12. Ирек Зиннуровның чит ил галәме,
яки Ни өчен Казанда Бакуга караганда җылырак

14. «Метеор»лар Себергә юл ала
«Төньяк елга флоты» башлыгы Казаннан Ханты-Мансийскига нәрсә алып китә

игелекле эшләр

26. Үзгәрешләр навигаторы
Милли проектлар тормышны ничек яхшы якка үзгәртә

36. Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт
Заманча версия

42. Йолдызлар арасындагы шар
Татарстанлылардан кем галәмгә ишек ачкан

46. Эссе җәйнең кайнар икмәге
Гадәттән тыш шартларда 2,4 млн тонна ашлыкны ничек үстерергә

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

мәңгелек кыйммәтләр

56. Гасырлар аша сәяхәт
Чүпче татарларын Кырым белән нәрсә бәйли

62. Өлкә комитет секретарьлары
Семён Игнатьев татарлар өчен нәрсә эшләгән

70. Тарих сәхифәләре
Татар патриоты – Һади Атласи

78. Безнең киштәдә
Чынбарлык турында – уйдырма дөньяда

82. Татар авыллары
Кояшлы Мортыштамак

Акыллы гамәлләр

24.09

Леонид Михельсон, «СИБУР Холдинг» ГАЖ директорлар советы рәисе, – Казанда, СИБУР белән ТАИФ арасында берләштерелгән компания төзүнең соңгы шартлары турында килешүне имзалаганнан соң:

– Әйтеп узганыбызча, дөньякүләм масштабтагы килешү бу. Дөньяда нефть-газ химиясе бизнесында бишенче урын ала алырлык компания оештырыла. Без моңа таба күптәннән атладык, бу юлны күптәннән тикшердек. Иң мөһиме – без үсеш юлыбызга бертөрле карарга тиеш, һәм максатлар да бер булсын.

30.09

Ирина Макиева, Моношәһәрләрне үстерү фонды генераль директоры, – Татарстанда «Озон» күмәртәләп сату-бүлү үзәген ачу тантанасында:

– Мин хәтерлим әле, берничә ел элек без «Яшел Үзән» мәйданчыгын карарга килгәндә, монда буш кырдан башка бернәрсә дә юк иде. Әлеге территориянең үзенә генә хас аерым бер тормыш белән яшәвен бик күрәсе килде. Ул вакытта, 2016 елда, проектны гамәлгә ашыру өчен Фонд – 930 млн сумнан артык, ә регион 350 млн сумнан күбрәк акча бүлеп бирде. Һәм менә үзара ышаныч һәм ярдәм бүген әлеге мәйданда урнашкан барлык предприятиеләрне «тукландырырлык» инженерлык инфраструктурасын төзергә мөмкинлек бирде. Бүген бирedә җиденче резидент эшли башлады. Якын араларда тагын берничәсенең эшләп китүе көтелә. Димәк, Яшел Үзән моношәһәре өчен яңа эш урыннары ачылачак.

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

1.10

Нияз Билалов, Чаллы егете, дзюдо буенча Россиянең яңа чемпионы:

– Кешедә иң яхшы сыйфатлар – эчкерсезлек һәм миһербанлык. Һәм, әлбәттә, характер да кирәк. Ихтыяр көче, үзеңне тәртипкә буйсындыру. Мин, гомумән, кеше талантлы булмаска да була, дип саныйм. Ә менә характерың бар икән, син чыгасың һәм теләсә кайсы көндәшең, тормышыңдагы теләсә кайсы проблема белән курыкмыйча көрәшәсең.

акыллы гамәлләр /

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстан кадрлары илне **НИЧЕК** күтәрә

Россия күләмендә **КЕМ** Татарстан тәҗрибәсен таратачак

НИГӘ Казанда Бакуга караганда җылырак

«Төньяк елга флоты» башлыгы Казаннан **НӘРСӘ** алып китә

PRESSA

БЕЗНЕКЕЛӘР БАШКАЛАЛАРДА

Фәнни потенциалы, куәтле сәнәгате, авыл хуҗалыгы, файдалы казылмалары булган Татарстанның тагын бер байлыгы – кеше капиталы бар. Бу иң кыйммәтле, төп капитал. Моңа дәлил – тормыш дәрәҗәсенең үсүе, икътисад, социаль сфералардагы уңышлар. Татарстан тәҗрибәсен үзәктә һәм башка регионнарда җентекләп өйрәнәләр һәм үзләренә үрнәк итәләр. Ә кеше капиталының иң яхшы вәкилләре – идарәче элита, фәнни кадрларны, әлбәттә, үзләренә алырга хыялланалар: хакимиятләр, чор-дәверләр алмашына, әмма «кадрлар барысын да хәл итә» дигән аксиома үзенең тормышчанлыгын раславын дәвам итә.

Бүген кайчандыр Татарстанда эшләп ныгыган кадрларны хакимият коридорларында, илнең иң шәп фәнни институтларында, театрларда күрү – гадәти күренеш. Кадрларның читкә китүенә республика ничек карый? Горурлык белән, аңлап. Беренчедән, бу тагын бер мәртәбә безнең кеше капиталының сыйфатын дәлилли. Икенчедән, Татарстандагы кадрлар резервы яңа бурычларны хәл итәргә башкалага киткәннәр урынына яңаларын табарга мөмкинлек бирә. Иң мөһиме, башкаладагы безнең кадрлар – илебез өчен кирәкле һәм файдалы.

Татарстаннан китүчеләргә туган якларыннан еракта ни дәрәҗәдә уңайлы, яңа шартларда, яңа вазыйфаларда үз потенциалларын һәрвакытта да гамәлгә ашыра алалармы? Әлеге максатларда «Татарстан» үзенең күренекле якташларыннан өч сорауга җавап бирүләрен үтенде:

1. **ТАТАРСТАНДА СЕЗ НИНДИ ТОРМЫШ ҺӘМ/ЯКИ ҺӨНӘРИ ТӘҖРИБӘ ТУПЛАДЫГЫЗ?**
2. **КЕЧЕ ВАТАНЫГЫЗДАН ЕРАКТА СЕЗ ТАТАРСТАН ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘДЕГЕЗ ЯИСӘ ЭШЛӘРГӘ ҖЫЕНАСЫЗ?**
3. **СЕЗНЕҢ БҮГЕНГЕ ТОРМЫШЫГЫЗДА ТАТАРСТАНДА ҮЗЕГЕЗ ГАДӘТЛӘНГӘННӘРДӘН НӘРСӘЛӘР ҖИТМИ? БҮГЕН СЕЗ ТАТАРСТАННАН НӘРСӘЛӘРНЕ ҮЗЕГЕЗ БЕЛӘН АЛЫР ИДЕГЕЗ?**

Сәлам
Мәскәүдән!

ДАМИР ФӘТТАХОВ,

МӘСКӘҮ

Казан башкарма комитетында балалар һәм яшьләр эшләре комитеты җитәкчесе, Киров һәм Мәскәү районнары хакимияте башлыгы, башкарма комитет рәисенең беренче урынбасары, Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгы җитәкчесе булган. 2021 елның сентябреннән – Яшьләр эшләре буенча федераль агентлык җитәкчесе урынбасары.

1

Барлык тәҗрибәмне диярлек республикада алдым. Бөтен гомерем Татарстан белән бәйле: тууымнан һәм мәктәп елларыннан алып Татарстан Хөкүмәтендәге вазыйфама кадәр. Бу минем Ватаным. Мин гомеремнең төрле чорларында үземне тәрбияләгән, өйрәткән укытучыларыма, остазларыма рәхмәтлемен. Life long learning* – минем принципларымнан берсе. Шунлыктан хәзер дә үз өлкәсендә һөнәрмәнд булган кешеләрдән уку-өйрәнүемне дәвам итәм.

2

Татарстан өчен нинди файда китерүемне мин үзем бәяли алмыйм. Яшьләр, Татарстан халкы бәяләсен.
Көченү турында карар кабул иткәндә башымдагы иң мөһим уйлардан берсе мондый иде: яңа вазыйфамда мин Татарстан файдасына эшләвемне дәвам итә алачакмын, әмма хәзер инде бер Татарстан өчен генә дә түгел. Минем федераль дәрәҗәдә файдаланырлык тәҗрибәм бар. Мине Федераль агентлыкка нәкъ менә республикада тупланган бәкграунд һәм тәҗрибәм булганга чакырдылар да инде. Татарстандагы иң яхшы проектларыбызны хәзер бөтен ил күләмендә гамәлгә ашырачакбыз.

3

Шөкер, Интернет бөтен җирдә бар, самолетлар оча, поездлар йөри, XXI гасырда чикләр җуела бара. Шунлыктан яңа шартларга ярашу бернинди проблема да тудырмый. Иң мөһиме, гаилә янәшәдә булсын. Минә монысы зур әһәмияткә ия. Гомумән, Россия Яшьләр эшләре агентлыгы инде кимендә өч ел буе Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгы тәҗрибәсен югары бәяли, төбәкләр рейтингындагы яшьләр сәясәте тармагында республика иң алда бара. Шунлыктан мин һәрвакыт коллегаларым белән элемтәдә. Шәхсән мин үзем Татарстан белән бөтенләйгә хушлашырга җыенмыйм.

* Өзлексез үсеш, уку-өйрәнү.

Сәлам Мәскәүдән!

РАВИЛ ӘХМӘТШИН,

МӘСКӘҮ

Россия Салым полициясе федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе башлыгы урынбасары, Россия Салым полициясе федераль хезмәтенең Мәскәү шәһәре буенча «Т» идарәсе башлыгы урынбасары. Соңрак – Эчке эшләр баш идарәсенең Мәскәү шәһәре буенча оператив идарәсе башлыгы, Россия Эчке эшләр министрлыгының башка җаваплы вазыйфаларында. 2010 елның апреленнән – ТРның РФндәге тулы вәкаләтле вәкиле, аннан соң ТР Премьер-министры урынбасары – ТРның РФндәге тулы вәкаләтле вәкиле.

1 **Татарстанда, беренче чиратта эти-әнием үрнәгендә, мин эшләргә һәм кешеләргә хәлдән килгән кадәр ярдәм итәргә өйрәндем.** Кече яшьтән урманга утынга йөрдем, көтү көттем, базарда суган саткан булды. Безнең Елхово авылын Чиполлиноград дип йөртәләр иде. Ничектер шулай килеп чыккан инде: элек-электән безнең авыл халкы суган үстерә. Шуңа да минем балачак хатирәләре яшелчә бакчасы белән бәйле: 30 сутый суган, шуның кадәр үк бәрәңге, әле болар янына колхозның ике гектар чөгендерен дә эшкәртә идек. Университетта укыганда, җәмәгать эшләре белән шөгыльләндем, экспедицияләргә йөрдем – гарәп телендәге сирәк китапларны җыя идем. Тупланган тәҗрибә, белем һәм танышлыклар миңа алга таба эшчәнлегемдә бик нык ярдәм итте. Казан университетының филология факультетын тәмамлап ике ел узгач, көч структураларындагы эшчәнлегем башланды. Язмыш мине менә дигән кешеләр белән очраштырды, тәҗрибәле хезмәткәрләр белән таныштырды.

2 **Мин – Мәскәүдә Татарстан Президентының вәкиле, шуңа да вәкаләтле вәкиллек, Мәскәү белән Татарстан арасындагы күпер кебек, күп профильле мәйдан булып тора.** Бездә республика турында актуаль мәгълүмат туплана, төбәкнең социаль-икътисадый, халыкара, инвестицион, мәдәни һәм башка бик күп проектлары башлангыч ала. Республика министрлыкларының хакимиятнең федераль органнары, Россия һәм чит илләр компанияләре, дипломатик корпус белән уртак проектлары нәкъ менә башкалада алып барыла. Вәкаләтле вәкиллек аппараты бу эштә актив катнаша, мәсьәләләрне тиз арада хәл итә. Чит ил илче һәм дипломатлары, эшлекле даирәләре, Россия һәм чит илләр инвесторларының Татарстанга эш сәфәрен әзерләү нәкъ менә Мәскәүдәге вәкаләтле вәкиллектә башлана. Алар белән очрашулар бездә уза. Республикага инде алар төбәкнең төрле өлкәләрдәге потенциалы турында мәгълүмат белән килә.
Без читтә күпмилләтле Татарстан турында уңай фикер тудырырга омтылабыз. 2011 елдан башлап, башкалада ел саен Татарстан мәдәнияте көннәре уза. Якташларны берләштерү, арабыздан киткәннәрне хәтердә саклау буенча эшчәнлек алып барабыз – һәйкәлләр ачабыз, алар турында фильмнар төшерәбез. Безнең өчен якташларыбызның мегаполиста югалмавы, бер-берсенә файдалы булуы мөһим.

3 **Асылда, мин ике шәһәрдә дә яшим. Эшем республика белән бәйле, Казанда – гаиләсе белән кызым, Мәскәүдә хатыны һәм өч баласы белән улым яши.** Мәскәү – бик актив, кызыклы һәм матур шәһәр. Әмма миңа туган җиремдә кешеләр ачыграк күңелле булып тоела. Анда дусларым яши. Нәкъ менә алардан һәрвакыт ихлас киңәшләр ишетүемә ышанам. Башкалага мин үзем белән туганнарымны һәм якын кешеләремне алыр идем, кайчагында алар белән аралашу, аларның теләктәшлеге җитми.
Мин Мәскәүдә эшлим, әмма минем өем Татарстанда. Республикада эти-әниемнең кабере, гомеремнең күпчелек өлеше шунда узды. Вакыты җиткәч, мин өйгә кайтачакмын.

Сәлам
Санкт-Петербургтан!

ИВАН ЕРЕМЕЕВ,

САНКТ-ПЕТЕРБУРГ

Санкт-Петербург прокуроры урынбасары, 3 нче класслы юстиция киңәшчесе. Аннан алдарак, 2007 елдан, Санкт-Петербургның Нева районы прокуроры вазыйфасын башкара. Төньяк башкалага Алабуга шәһәреннән күчәнә, биредә ул шәһәр прокуратурасын җитәкли.

1 **Югары юридик белемне Татарстан башкаласында алдым.** 1992 елда Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамладым. Ә аннан соң җиде ел дәвамындагы хезмәт эшчәнлегем – стажердан алып прокурор ярдәмчесенә кадәр – Кама транспорт прокуратурасында узды. 1999 елда мин Алабуга шәһәре прокуроры урынбасары булып эшли башладым, 2001 елдан Алабуга шәһәр прокуратурасын җитәкләдем.

2 **Минем нәрсәләргә ирешүем турында үземә сөйләү бик үк дөрес булмас.** Янәшәмдәге хезмәттәшләрем, коллектив белән бергә ирешкән уңышларыбыз турында сөйләү дөресрәктер. Кул астымда эшләүчеләрне нәтиҗәгә ирешүгә көйли, туплый алдым, дип уйлыйм. Бу гражданнарның бозылган хокукларын торгызу, аларның ышанычын һәм гаделлекне көтүен акларга тырышу. Эш юнәлешләре күп, аларның берсен дә игътибарсыз калдырып булмый. Илебез прокуратурасы органнары каршында куелган бурычларны уңышлы башкару өчен Татарстан Республикасы прокуратурасында эшләүче коллегаларым белән уңай тәҗрибә уртаклашу һәм фикер алышу бик мөһим, дип саныйм.

3 **Миңа бүген мегаполиста кече ватанымда калган кешеләр, традицияләр җитеп бетми.** Ләкин прокуратура эше бик күп вакытны ала, бу турыда җитди уйланырга мөмкинлек калмый диярлек.

Сәлам
Бакудан!

ИРЕК ЗИННУРОВ,

БАКУ

Су полосы буенча ике тапкыр Олимпия уеннары призёры, дөнья һәм Европа чемпионатлары призёры, VII чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты, 2020 елның декабреннән – БДБ эшләре буенча Федераль агентлыкның Азәрбайҗандагы вәкиллеге җитәкчесе.

1

Мин Казанда туып-үстем. Бу мине аякка бастырган туган шәһәрем, биредә мин берьюлы ике мәктәп – гомуми белем бирү һәм спорт мәктәпләрен тәмамладым. Мин Казанга ике меңенче еллар башында, инде җитлегеп әйләнеп кайттым. Спорт карьерамның тиздән тәмамланачагын аңлап, киләчәкне кайгыртырга кирәк иде. Һәм ул чакта Казан миннән сәясәт һәм идарә даирәсендә һөнәрмәнд ясады. Казан университетын «дәүләт һәм муниципаль идарә менеджменты» белгечлеге буенча тәмамлап, мин икенче югары белем алдым. Аннары исә – Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев һәм республикабызның хәзерге Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов эшен күзәтеп, бәя биреп бетергесез тәҗрибә тупладым. Бу инде бөтенләй башка дәрәҗәдәге эш иде! Республика бик тиз алга барды, биредә Универсиада, аннары башка зур чаралар үткәрелде. Алар минем һөнәри үсешем өчен дә гаять зур мөмкинлекләр ачты.

2

Мин VII чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты булдым. Парламентта эшләгәндә, күп юнәлешләр буенча Татарстан мәнфәгатьләрен кайгырттым, федераль һәм республика министрлыклары арасында эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруга булыштым, республикага федераль финансларны җәлеп итәргә тырыштым. Аннары исә миңа БДБ эшләре буенча Россия федераль агентлыгының Азәрбайҗандагы вәкиллеге җитәкчесе вазыйфасын тәкъдим иттеләр. Рөстәм Миңнехановтан киңәш соравымны хәтерлим. Һәм ул: «Ирек, әлбәттә, ризалаш! Кирәксә, бер-беребезгә ярдәм итешербез!» – диде. Азәрбайҗанда бик күп татар яши. Без милли җәмәгать оешмалары белән актив эш алып барабыз, күп чаралар үткәрәбез. Мәсәлән, без югары уку йортлары арасында хезмәттәшлек урнаштырабыз. Күптән түгел Бакуда КФУның Яр Чаллы институты директоры булып китте. Ул Азәрбайҗан техник университеты белән икеләтә дипломнар программасы турында килешү имзалады. Спорт тармагында да уртак мәнфәгатьләрне табарга тырышабыз. Азәрбайҗанның иң көчле спортчылары Казанга сумо буенча Европа чемпионатына килде. Күптән түгел Бакуда Татарстан китап нәшрияты мөмкинлекләрен күрсәттек. Әлбәттә, пандемия үз төзәтмәләрен кертә, уртак зур чаралар уздыруга комачаулый – Азәрбайҗанда катгый тыюлар гамәлдә. Шулай булса да, планнар бик күп. Бу – Татарстан театрлары гастрольләре дә, Азәрбайҗанда зур Сабан туе үткәрү дә, яшьләр сәясәте даирәсендә хезмәттәшлек тә...

3

Күптән түгел бер журналист миннән: «Үзегезне Азәрбайҗанда чит ил кешесе итеп тоясызмы?» – дип сорады. Мин, юк, дип җавап бирдем. Минем янәшәмдәге кешеләр үземне болай тоярга мөмкинлек бирми. Әмма шулай да, Азәрбайҗанда никадәр генә җылы булмасын – Бакуда хәзер исә 27 градус – Казанда барыбер җылырак! Ул бит минем ватаным, анда минем туганнарым, якыннарым, дусларым яши. Өй өй инде ул! Кызганычка, андагы бөтен нәрсәне үзең белән алып китеп булмый. Шунлыктан мин, ялга кая җыенуымны сорасалар, уйлап та тормыйча, шундук: «Өйгә!» – дим.

Сәлам Ханты-Мансийскидан!

АЙРАТ ЧУМАРИН,

ХАНТЫ-МАНСИЙСК

Түмән өлкәсендәге иң борынгы предприятиеләрдән берсе – «Судоремонт Сумкино» ҖЧҖ җитәкләгән, Иртыш пароходчылыгы башкарма директоры булып эшләгән. 2019 елдан – «Төньяк елга флоты» АҖ генераль директоры.

1

Мин Казанда иң яхшылардан саналган 102 нче мәктәптә укыдым. Аннары бик яхшы укытучылар һәм комсомол линиясе буенча менә дигән остазлар эшләгән Казан елга техникумында белем алдым. Аларның күбесе хәзер Татарстанда җаваплы урыннарда эшли. Гомумән, Елга техникумындагы безнең факультеттан унбишләп порт директоры һәм мин, пароходчылык директоры, чыккан. Минем Казанда алган белемем карьерамның нигезен тәшкил итә. Иң әүвәл мин Казан елга портында, институтны тәмамлагач, диңгез судноларында, аннары кабат Казанда, судночылык компаниясендә эшләдем. Себергә киткәч, башта Тубылда судонолар ремонтлау заводын, аннан соң Иртыш пароходчылыгын, хәзер инде «Төньяк елга флотын» җитәклим.

2

Хәзер Татарстанда безнең предприятие өчен ике яңа, конструкциясе буенча тиңдәшсез суасты канатлы суднолар – өр-яңа метеорлар төзелә. Тиздән алар безгә кайтачак һәм рейска китәчәк. Биредә, Көнбатыш Себердә, алар Татарстан имиджын таныта. Әлеге суднолардан файдалануның уңай тәҗрибәсе мондый метеорларның киләчәктә Иделдә дә, Себер һәм Ерак Көнчыгыш елгаларында да йөри башлавына этәргеч булырга мөмкин.

3

Чәкчәк һәм өчпочмак... Чынлап әйткәндә, әгәр башка төбәктә булсам, миңа зур проектларны гамәлгә керткәндә Татарстандагы кебек эшлекле якын килү һәм нәтиҗә булсынга эшләү җитенкерәмәс иде. Әмма Ханты-Манси автономияле округында да мин эшкә нәкъ шундый мөнәсәбәтне очраттым – биредә губернатор социаль һәм инновацион сәясәт белән актив шөгыльләнә. Мәсәлән, нигездә гражданлык, пассажир суднолары төзелә.
Самолетлар еш оча («ЮВТ Аэро» Казаннан Ханты-Мансийскига рейсны яңартса, ничек шәп булыр иде), шуңлыктан мин Татарстанга гел кайткалап йөрим һәм әллә ни сагынырга өлгермим. Әмма биредә, Себердә, Татарстаннан килгән танышларны очрату һәм алар белән чәй эчү үзенә бер төрле рәхәтлек бирә.

МИНИСТЕРСТВО
НАУКИ
И ВЫСШЕГО
ОБРАЗОВАНИЯ
РОССИЙСКОЙ
ФЕДЕРАЦИИ
Сәлам Мәскәүдән!

АЙРАТ ГАТИЯТОВ,

МӘСКӘҮ

ТР Төзелеш министрлыгы башлыгы ярдәмчесе, ТР Төзелеш министрлыгының дәүләт, максатчан һәм тармак программаларын формалаштыру идарәсе җитәкчесе, аннан соң ТР төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры урынбасары булган. Мәскәүдә 2019 елдан. РФ Фән һәм югары белем министрлыгының милек комплексын һәм бюджет инвестицияләрен үстерү департаменты директоры булып эшләгән. 2021 елның июнь аеннан – РФ фән һәм югары белем министры урынбасары.

1

Мин Казанда туып-үстем. Татар гимназиясен тәмамладым, аннан соң Казан федераль университетында һәм Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетында укыдым. Укыганда ук кызыклы һәм иҗади проектларда катнашырга теләвемне аңладым. Шулай рәвешле студсоветка килеп эләктем, аның рәисе булдым. Соңрак бүген ТР Яшьләр эшләре министрлыгын җитәкләүче Тимур Сөләйманов белән Татарстан студентларының футбол лигасын оештырдык.

Төзелеш һәм объектлардан файдалану өлкәсендә туплаган бөтен тәҗрибәм өчен мин Ирек Әнвәр улы Фәйзуллинга рәхмәтле, ул 2011 елда ТР Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын җитәкли иде. Без аның белән Бөтендөнья җәйге Универсиадасында Шэньчжэнь шәһәрендә таныштык, мин анда волонтёр булып барган идем. Ул мине үзенә ярдәмче итеп чакырды һәм Казандагы Универсиадага әзерлек буенча көндәлек җитди эш башланды. Искиткеч зур тәҗрибә! Мин үзебезнең профессионаллардан торган зур команда белән бергә үстем. ТР төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары вазыйфасына тәкъдим ителгәндә миңа 26 яшь иде. Моңа кадәр тупланган тәҗрибә һәм белемнәрне бу юлы инде үзем җитәкче буларак шунда кулланырга мөмкинлек туды. Су спорты төрләре буенча дөнья чемпионаты, футбол буенча дөнья чемпионаты, Конфедерацияләр кубогы һәм, ниһаять, WorldSkills... Ул вакытларны сагынып искә алам: дөнья күләмендәге зур вакыйгалар, һәм без аларны үзебездә – Татарстанда гамәлгә ашыра алдык. Үзара сөйләшкәндә дә, киң җәмәгатьчелеккә дә бер үк сүзне әйтәм: республика миңа потенциалымны ачарга мөмкинлек бирде. Әлбәттә, күп нәрсә безнең тормыштагы вакыйгаларга да бәйле булырга мөмкин, әмма һөнәри яктан үсәсе килгән кеше өчен Татарстанда бөтен шартлар җитәрлек.

2

Бүген минем вазыйфаларым элеккеге кебек үк төзелеш, капиталь ремонт, милек белән идарә итүгә бәйле, әмма хәзер инде болар ил күләмендә башкарыла. Татарстанда алган һөнәри тәҗрибәмне бөтенроссия күләмендәге зур программаларны – студентларның тулай торакларына, лаборатория корпусларына капиталь ремонт ясау булсынмы ул яки югары уку йортларының спорт инфраструктурасын үстерүме – әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда кулланам. Бу юнәлешләрдә республиканың Россия Мәгариф министрлыгы структурасына караган югары уку йортлары белән хезмәттәшлек тә минем карамакта. Моннан тыш, без илнең иң зур фәнни үзәкләреннән берсе – Россия Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең инфраструктурасын үстерү мәсьәләләре белән дә шөгыльләнәбез. Әле күптән түгел генә, 1 сентябрьдә, Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов Казан энергетика университетының яңа тулай торагын ачты. Киләсе елга КАИның алты йөз урынлык тулай торагын ачарбыз, дип өметләнәм. Әлеге ике объект буенча эш мин килгәнче үк башланган иде, әмма аны ахырына кадәр мин җиткерергә тиеш булуыма шатмын. Республика җитәкчелеге, аның министрлыклары һәм ведомстволары белән без һәрвакытта да элемтәдә. Татарстанда ничек өйрәткән булсалар, шулай эшлибез – нәтиҗәле генә түгел, ә бөтен нәрсә дә ачыктан-ачык.

3

Мәскәүдә без зур гомуммилли проектларны гамәлгә ашыру белән шөгыльләнәбез. Ул исә олы хезмәт куюны һәм Россия буйлап һәм аннан читтә дә йөреп эшләүне таләп итә. Әле күптән түгел генә башкалага Татарстанда күнеккән эш тизлеген алып килә алуым турында хезмәттәшләрем белән киңәшеп алдык. Биредә миңа әти-әнием, якыннарым, дусларым белән көндәлек аралашу гына җитми. Ул исә көч бирә. Айга бер тапкыр булса да өйгә кайтып килә алсаң, бик шәп инде!


Сәлам
Мәскәүдән!

РЕНАТ ИБРАҺИМОВ,

МӘСКӘҮ

Совет һәм Россия җырчысы, композитор, актёр. Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган, иҗат карьерасын Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында башлаган.

1 **Гомеремнең беренче яртысы Татарстанда узды.** Балалар бакчасы, мәктәп, музыка һәм сәнгать мәктәпләре, консерватория, опера театрында һәм филармониядә солист булып эшләү, коллективларның эшен оештыру, фестивальләр үткәрү... Боларның барысы да Казанда булды, шуңа да минем тормышымда һәм хезмәт юлымда туплаган тәҗрибәм турыдан-туры шушы шәһәр белән бәйле.

2 **Нигездә Татарстанда эшләдем, гәрчә ил буйлап, чит илләргә гастрольләргә еш йөрергә туры килсә дә.** Республика районнарына да концертлар белән еш чыга идем. Бик күп чыгышларым КАМАЗ һәм башка зур объектлар төзелеше белән бәйле. Хәйрия чараларында, балалар һәм сәламәтлекләре чикләнгән кешеләр өчен оештырыла торган концертларда еш катнаша идем, хәзер дә катнашам. Мин һаман сәхнәдә әле, ләкин, пандемия сәбәпле, концерт эшчәнлеге сүлпәнәйде, әмма мин студиядә эшлим, яңа программалар язам. Параллель рәвештә мине һәрвакытта да кызыксындырган тема – мәгариф һәм агарту өлкәсендә проектлар белән шөгыльләнәм. Әгәр дә инде туган республикам алар белән кызыксына икән, Казанда мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә мондый юнәлешләрдә эшләргә әзермен.

3 **Әлбәттә, Мәскәү – ни әйтсәң дә, туган җир түгел инде.** Үзем туган Львов шәһәрендә мин нибары биш яшемә кадәр генә яшәгәнмен. Үземне белә башлаганнан бирле гомеремнең иң күп өлеше Казанда узды. Биредә минем иң җылы хатирәләрем, туганнарым, дусларым. Әлбәттә, Мәскәүдә миңа болар җитми. Татарстаннан үзем белән нәрсә алыр идемме? Кызганыч ки, иске Казанның, аның балачагым, яшьлегем (гәрчә үземне әле дә яшь хис итсәм дә!) үткән урамнарының атмосферасын, рухын Мәскәүгә алып китеп булмый. Бу хисләрне кабат кичерим дисәң, Казанда булырга кирәк.

МӘСКӘҮДӘ ҺӘМ ТӨБӘКЛӘРДӘ

МАРАТ ХӨСНУЛЛИН,
РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары

ИРЕК ФӘЙЗУЛЛИН,
РФ төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры

ЛЕНАР САФИН,
Федерация Советының Икътисадый сәясәт комитеты рәисенең беренче урынбасары

ВАЛЕРИЙ ГЕРАСИМОВ,
РФ Кораллы көчләре Генераль штабы башлыгы

ТАТАРСТАНЛЫЛАРНЫҢ КУӘТЛЕ УНЛЫГЫ

РАВИЛ ГАЙНЕТДИН,
РФ Мөселманнарының Диния нәзарәте мөфтие

АРТЁМ ЗДУНОВ,
Мордва Республикасы башлыгы

ЧУЛПАН ХАММАТОВА,
актриса, җәмәгать эшлеклесе, «Тормыш бүләк ит» фондын гамәлгә куючыларның берсе

ГҮЗӘЛ ЯХИНА,
язучы

РӨСТӘМ ТАРИКО,
«Русский стандарт» холдингына нигез салучы һәм аның хуҗасы

ТАЛИЯ ХӘБРИЕВА,
РФ Хөкүмәте каршындагы Закон чыгару һәм чагыштырма хокук белеме институты директоры, Хокук аша демократия өчен Европа комиссиясендә Россия Федерациясе вәкиле

БАШКАЛАДА ТАТАРСТАНЛЫЛАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ УНЛЫГЫ.

ПЁТР ДЕМЕНТЬЕВ,
КПСС ҮК әгъзасы, СССР авиация сәнәгате министры (1957–1977)



ФИКРӘТ ТАБИЕВ,
СССРның Әфганстандагы Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле вәкиле (1979–1986), РСФСР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары (1986–1990), Россия Федераль милек фонды рәисе (1992–1993)

ГОМӘР УСМАНОВ,
КПСС ҮК секретаре (1989–1990)



ЮРИЙ ВОРОНИН,
РФ Югары Советы Рәисе урынбасары, соңрак беренче урынбасары (1991–1993)

РЕТРОСПЕКТИВА*

КАМИЛ ИСХАКОВ,
РФ Президентының Ерак Көнчыгыш федераль округындагы Тулы вәкаләтле вәкиле, РФ Куркынычсызлык Советы әгъзасы (2005–2007), РФ төбәк үсеше министры урынбасары (2007–2008), Согуд Гарәбстаны Корольлегендә Ислам конференциясе Оешмасы каршында РФнең даими вәкиле (2008–2011)

НИКОЛАЙ НИКИФОРОВ,
РФ элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры (2012–2018)



ВАСИЛИЙ ЛИХАЧЁВ,
РФнең Европа берлегендәге даими вәкиле (2011–2016)

НИКОЛАЙ ДЕМИДОВ,
СССР ЭЭМның социалистик милекне урлауларга каршы көрәш буенча Баш идарәсе башлыгы (1983–1989), СССР эчке эшләр министры урынбасары (1983-1991)

ФӘРИТ ГАЗИЗУЛЛИН,
РФ милек мөнәсәбәтләре министры (2000–2004)

РОАЛЬД СӘГЪДИЕВ,
СССР ФА академигы (1968 елдан), Россия ФА академигы (1991 елдан), СССР ФАнең Космик тикшеренүләр институты директоры (1973–1988)

** 1950 елдан 2020 елга кадәр*

Тәртип

Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!

tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar

App Store

Google Play

Реклама 6+

Акыллы гамәлләр

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Милли проектлар тормышны **НИЧЕК** яхшы якка үзгәртә

Петербургтан Мәскәүгә **НИЧЕК** барып җитәргә

Татарстанлылардан **КЕМ** галәмгә ишек ачкан

Корылыклы җәйдә **НИЧЕК** 2,4 млн ашлык җыярга

БИШ МИЛЛИ

«ДЕМОГРАФИЯ»
МИЛЛИ ПРОЕКТЫ

«МИН ҮЗЕМ» БАЛАЛАР БАКЧАСЫ

Коридорларда – бизибордлар, магнитлы шахмат такталары, ә спорт залында җиңел атлетика буенча Россия чемпионы Анна Крылова дәресләр бирә. Чит телләр инженерлык белеме дәресләрендә өйрәнелә, фойедагы экраннардан пешекчеләрнең ашарга әзерләвен күзәтергә мөмкин...

Сабыйларга боларның барысын да, шулай ук калдыкларны аерып җыю тәҗрибәсе, робот техникасы дәресләрен, мультфильмнар төшерүне язын Казанның Киров районы Пилот урамында ачылган яңа 101 нче «Мин үзем» полилингваль балалар бакчасы педагоглары тәкъдим итә. Бу – шәһәрдә ачылган алтынчы полилингваль балалар бакчасы. Биредә сабыйлар заманча интерактив җиһазлар ярдәмендә рус, татар һәм инглиз телләрен өйрәнә.

«Демография» милли проекты буенча төзелгән балалар бакчасына бүген **1,5 яшьтән 7 яшькә кадәрге 340 сабый йөри.**

2021 елда Татарстан Республикасында барлыгы **16 балалар бакчасы** төзелергә тиеш.

Моңа федераль бюджеттан – **2 миллиард сум,** республиканыкыннан **1,8 миллиард сум** акча бүленгән.

Фото: Александр Ефремов

ПРОЕКТ

БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН:

«Демография» милли проектының максаты – «халык санын, халыкның сәламәтлеген һәм иминлеген саклау». Ул һәр этапта гаиләгә төрле яктан ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән: бала табу һәм тәрбияләү, эшкә урнашырга булышу, өлкән яшьтәге гражданнар өчен актив озын гомер. Проект шулай ук сәламәт яшәү рәвеше һәм спорт белән даими шөгыльләнү өчен шартлар тудыруны да күздә тота.

«КУРКЫНЫЧСЫЗ ҺӘМ СЫЙФАТЛЫ ЮЛЛАР»
МИЛЛИ ПРОЕКТЫ

ЗУР КАЗАН БОЖРАСЫ

«Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» милли проекты буенча Россиядә **барлыгы 32 мең километрдан артык юл** салынган, реконструкцияләнгән яки ремонтланган. Шулардан берсе – Зур Казан божрасы. Идел һәм Кабан күлләре арасындагы сәнәгать зонасын шәһәрнең күллердән көнбатыштарак урнашкан торак өлеше белән тоташтыра торган иң кыска юл бу.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Зур Казан божрасын төзү – 2013 елгы Универсиадага әзерлектән соң ТР башкаласындагы иң эре инфраструктуралы юл проекты.

Бүген милли проект кысаларында Татарстанда гомуми озынлыгы **217,8 километр** булган автоюллар ремонтлана.

Фото: Александр Ефремов

БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН:

«Куркынычсыз һәм сыйфатлы юллар» – Россиядә гамәлгә кертелә торган ундүрт милли проектның берсе. Аның буенча 2019 елда барлыгы 16 мең километрдан артыграк автотрасса салынган, ремонтланган һәм реконструкцияләнгән. 2020 елда да шундый ук күрсәткечләргә ирешелгән.

«МӘГАРИФ»
МИЛЛИ ПРОЕКТЫ

187 нче «РИТМ» лицее

Ел саен яңа мәктәпләр файдалануга тапшырылуга карамастан, Россиядә укучыларга урын җитмәү проблемасы һаман хәл ителми – бүген дә меңләгән бала ике сменалы мәктәпләрдә укый. Халык саны бигрәк тә тиз арта торган шәһәр һәм районнарда вазгыять аеруча катлаулы. Һәм әлеге проблеманы бер генә юл белән хәл итеп була – мөмкин кадәр күбрәк мәктәпләр төзү. Яхшы мәктәпләр!

Казан, Нәҗип Җиһанов урамы, 4 нче йорт. Бу соңгы елларда ТР башкаласында «Мәгариф» милли проекты кысаларында файдалануга тапшырылган шундый алты мәктәпнең берсенең адресы. Мәгълүмати-технологик профильдәге суперзаманча «РИТМ» лицееның үз IT-полигоны, 3D-модельләштерү лабораториясе, телескоплар куелган астропланетарие бар... Мини-типография, фото- һәм телестудияләр, актлар һәм хореография заллы арт-блок, музыка мәктәбе, театр студияләре... Физика һәм химия кабинетлары – лабораторияләр, ә технология сыйныфы автоматлаштырылган станоклар, 3D-принтерлар белән җиһазландырылган. Спорт белән шөгыльләнү өчен ике бассейн һәм ике спорт залы эшли. Яңа уку елында өстәмә «IT-куркынычсызлык» юнәлешле кадетлар сыйныфы ачылган.

«Сириус» мәгариф үзәге җитәкчесе Елена Шмелёва, 187 нче лицейны карап йөргәндә, «Мәгариф» милли проектының төп бурычларыннан берсе – «кайда яшәвенә һәм нинди керемле гаиләдә тәрбияләнүенә карамастан, һәр балага сыйфатлы белем бирү һәм бертигез инфраструктура булдыру» икәнен билгеләп үтте.

Соңгы 5 елда Россиядә
690 мең урынлык
1623 мәктәп
төзелгән.

Фото: Александр Ефремов

БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН:

Россия Федерациясендә «Мәгариф» милли проекты кысаларында быелгы уку елына гына да 130 яңа мәктәп ачылган. 2025 елга кадәр тагын 1300 мәктәп салыначак. Моннан тыш, 7,3 мең мәктәп капиталь ремонт программасына кертелгән, барлык белем бирү программалары исә яңа мәктәпләрдәге кебек булачак.

«ХАЛЫКАРА КООПЕРАЦИЯ ҺӘМ ЭКСПОРТ»
МИЛЛИ ПРОЕКТЫ

«ЭЙДОС-МЕДИЦИНА» КОМПАНИЯСЕ

Алар сөйләшә, авыру билгеләреннән зарлана, күз каралары яктылыкны сизә, тәҗрибәсез медиклар ялгышкан очракларда исә хәтта йомык күзләреннән яшь тә агып чыгарга мөмкин. Бу – тере, чын пациентлар түгел, ә беренче ярдәм күрсәтү, анестезия процедурасын үткәрү, хирургик операцияләр ясау күнекмәләрен ныгыту өчен симулятор-манекеннар.

Барлык манекеннар да анатомия төгәллеге белән эшләнгән, аларның эчке әгъзалары һәм кан әйләнеше системасы бар, ә хирурглар өчен модельләрдә лапароскопия операцияләре ясау өчен тиредә тишекләр калдырылган һәм организм халәтенең виртуаль картинасы чагыла торган махсус экран да тәкъдим ителә. Медицина инструментларының сизгерлеге, кире элемтә механизмы хирургны өйрәнү өчен чынбарлыкка максималь якын модель белән тәэмин итә.

«Эйдос-медицина» компаниясе – «Сколково» резиденты – бүген уку-өйрәтү симуляторлары җитештерүче бөтендөнья лидерларының беренче бишлегенә керә, төп җитештерү процессы да Россиядә бара. «Халыкара кооперация һәм экспорт» милли проектына ярдәм чараларыннан файдаланып (күргәзмәләр эшчәнлегендә, Россия экспорт үзәгенең бизнес-миссияләрендә катнашу), ул югары технологияләр өлкәсендә «Ел экспортёры» конкурсында җиңгән.

Компаниянең Казандагы офисында журналистлар белән очрашуда импортны алыштыру программаларында катнашкан технопаркларга дәүләт ярдәме чаралары турында РФ Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов сөйләде. Ул:

– Бүген алга киткән дистәләрчә ил мондый инновацион товарны куллана... Безнең бурыч – товарны бөтен дөньяда көндәшлеккә сәләтле итү. Ул арзанрак, сыйфатлырак һәм нәтиҗәлерәк булырга тиеш, – дип басым ясады.

Фото: Александр Ефремов



БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН:

Елның җиде ае нәтиҗәләре буенча, чимал булмаган, энергетикага кагылмаган экспорт 6,5 процентка арткан, төяп-озату күләме исә 63,7 миллиард долларга бәяләнә. Шул исәптән алгарышлы темп белән дә – сәнәгать продукциясен тышкы базарда сату 10 процентка диярлек арткан. «Халыкара кооперация һәм экспорт» милли проектының төп максаты – 2030 елга чимал булмаган, энергетикага кагылмаган экспортның гомуми күләмен 70 процентка арттыру.

«КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫК»
МИЛЛИ ПРОЕКТЫ

«ӘЗЕРЛӘҮЧЕ» АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ КУЛЛАНУЧЫЛАР КООПЕРАТИВЫ

– Татарстан – чәй яратучылар республикасы, – ди «Әзерләүче» («Заготовитель») авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы рәисе Рамил Яруллин. – Бездә халык көн саен 6–7 чынаяк чәй эчә, бу бөтен Россия белән чагыштырганда 20 процентка күбрәк. Дусларым белән мин дә – чәйгә мөкиббән. Әмма бер тапкыр без кара чәй урынына үлән чәе эчеп карадык та, бу безгә бик ошады! Тәмле дә, файдалы да. Аннары инде әлеге мавыгуыбыз бизнеска әйләнде.

«Әзерләүче» Лаеш районы Сокуры авылындагы сәнәгать мәйданчыгы корпусларыннан берсен арендалаган, хәзер инде анда 95 пайчы исәпләнә. Нигездә бу илнең биш төбәге – Татарстан, Кырым, Адыгея, Алтай, Мәскәү өлкәсеннән крестьян-фермерлык һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар, шәхси эшкуарлар. Алар барысы да үлән, җиләк-җимеш үстерү яки әзерләү белән шөгыльләнә.

Бүген «Әзерләүче» кооперативының «Сәламәт туклану фабрикасы» дигән чәйләрен Россиянең зур сәүдә челтәрләрендә, шулай ук Франция, Германия һәм Кытайда очратырга була.

«Әзерләүче» кооперативы рәисе дә үз бизнесының тиз арада аякка басуын дәүләт ярдәме программаларына бәйли:

– Мин Икътисад министрлыгыннан 5 һәм 11 миллион сумлык ташламалы ике микрозайм алдым һәм бик канәгать калдым. Чимал белән тәэмин итүчеләргә үз вакытында түләгәч, табышка чыгу да җиңеләйде. Бу минем өчен бик мөһим иде. Шулай ук чималны саклау өчен яңа склад та төзи башладык.

2020 елда Россиядә **1200 дән артык фермер хуҗалыгы** «Агростартап» грантын алган.

Бу максатка федераль бюджеттан бүленгән акчаның гомуми күләме якынча **3,2 миллиард сумны** тәшкил иткән.

Фото: Александр Ефремов

БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН:

«Кече һәм урта эшкуарлык һәм шәхси эшкуарлык инициативасына ярдәм» милли проекты кысаларында Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы фермерларга ярдәм һәм авыл кооперациясен үстерү системасын булдыру чараларын гамәлгә кертә. 2020 елда аларны финанслауга федераль бюджеттан 3,8 миллиард сум акча бүленгән.



ПЕТЕРБУРГТАН МӘСКӘҮГӘ СӘЯХӘТ.

Автор:
Ксения Сёмина

Автономияле (үзидарәле) транспорт белән йөк ташу коридоры Татарстанны Европа белән 2025 елда ук тоташтырырга мөмкин.

ПИЛОТСЫЗ ВЕРСИЯ

М12 Россиядә пилотсыз йөк автомобильләре өчен икенче трассага әйләнергә мөмкин. Бу хакта сентябрьдә узган Kazan Digital Week форумында Россия транспорт министры урынбасары Кирилл Богданов хәбәр итте. Ә Россиядә пилотсыз йөк машиналарын юлга чыгарып җибәрү премьерасы 2024 елда Мәскәү белән Санкт-Петербургны тоташтырган «Нева» М11 трассасының пилотсыз коридорында булырга тиеш. Салонында машина йөртүче утырган һәм йөртүчесез автомобильләр бер үк хайвейдан барачак.

М11 трассасындагы пилотсыз коридор – илебезнең йөртүчесез хәрәкәт белән бәйле колачлы проектында бер өлеш кенә. Әлеге проект кысаларында цифрлы инфраструктура белән җиһазландырылган 20 мең км федераль автомобиль юллары төзү һәм шул рәвешле Европа һәм Азия

М12 автотрассасы төзелеше.

арасында пилотсыз коридор булдыру планлаштырыла. Шулай итеп, Кытай белән хезмәттәшлекне глобаль дәрәҗәдә үстерү, әйтик, 2030 елга әлеге ил белән йөк әйләнешен 10 тапкыр арттыру күздә тотыла.

Проектның инфраструктура нигезен «Нева» М11 (Санкт-Петербург – Мәскәү), ЦКАД (Мәскәү янында Үзәк божра автомобиль юлы, төзелеше тәмамланган диярлек) һәм Мәскәү – Казан М12 (төзелеше 2024 елда тәмамланачак) автотрассаларыннан торган тизйөрешле юллар челтәре тәшкил итә. Санкт-Петербургтан Финляндия чигенә кадәр «Скандинавия» трассасыннан барып җитәргә мөмкин. Шулай итеп, М12 ярдәмендә Казан Европа белән тоташачак.

– М11 – бик күп йөк ташыла торган трасса, әмма икътисадый нәтиҗәлелек озак вакытны күзаллаганда булачак. Әгәр без 2025 елга Казан – Финляндия трассасын төзи алсак, пилотсыз йөк ташуларга ихтыяҗ артачак, – дип саный Богданов.

Йөртүчесе булмаган, сынаучы инженер катнашыннан башка йөрүне күздә тоткан пилотсыз транспортның хәрәкәтен тәэмин итү өчен, 660 км дан артык озынлыктагы М11 трассасында, Мәскәү һәм Санкт-Петербургка килеп җиткәндәрәк, махсус хаблар булдыру планлаштырыла. Бу исә хәзерге этапта үзидарәле йөк машиналарының шәһәргә кереп китүенә юл куймас өчен кирәк. Пилотсыз йөк машинасының хәрәкәте түбәндәгедән гыйбарәт: машина йөртүче автомобильгә йөкне төйи һәм аны трассада билгеле бер урынга кадәр китереп җиткерә, аннары автомат идарә системасын куша һәм кабинадан чыгып китә. Машина үзен башка йөртүче каршы алачак ноктага кадәр мөстәкыйль рәвештә бара, бу йөртүче автопилотны сүндереп, автомобильне складка кадәр алып китә. Пилотсыз машиналар үсешенең киләсе этабында кабиналар алып ташланачак, ә йөк машинасы хәрәкәтен читтән оператор контрольдә тотачак. «Коридор» сүзе бу очракта пилотсыз автомобильнең бөтен юлында, хаблардан тыш, тапшыру җайланмалары урнаштырылачак дигәнне белдерә, алар ярдәмендә автомобиль оператор, мәгълүматлар базасы һәм башка машиналар белән элемтә тотачак.

ФЛАГМАН ҖИТЕШТЕРҮ ХӘЛЕБЕЗДӘН КИЛЕРЛЕК

Экспертлар фикеренчә, илебездә бу кадәр зур планны тормышка ашыру өчен кирәкле бөтен нәрсә бар. Татарстанның гасыр проектына кертәчәк өлеше – «КАМАЗ»лар, М11 һәм М12 пилотсыз коридорлары аша алар беренчеләрдән булып юлга кузгалачак.

Болар ADAS системасы белән җиһазландырылган К6 тибындагы кабиналы йөк машиналары булыр, дип көтелә. ADAS – йөртүчегә автомобиль белән идарә итәргә булышу системасы. Ул никадәр югарырак дәрәҗәдә булган саен, автомобиль шулкадәр мөстәкыйльрәк. Мәсәлән, 3 нче дәрәҗәдәге система машина үзе бара, тик аны теләсә кайсы вакытта идарәне үз кулына алырга әзер кеше контрольдә тота дигәнне белдерә. 5 нче дәрәҗә исә квалификацияле йөртүче күнекмәләренә ия автопилот режимын аңлата. К6 «КАМАЗ»ы 4–5 нче дәрәҗәле ADAS белән җиһазланачак.

Прототипларга тест уздыру эше киләсе елда ук башланачак. Аларның элгәресе – ADAS 3 көйләнгән К5+ тибындагы КАМАЗ-54907 җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде инде. Аны серияле җитештерү 2023 ел ахырында башланачак.

Конвейердан чыгарга әзерләнгән пилотсыз проектлардан (электрлы чүп ташу машиналарыннан башлап, пассажирлар йөртәчәк шаттлларга кадәр) кала, компания иң заманча йөк ташу флагманын – кабинасыз технологик платформа булдыру белән дә шөгыльләнә.

Инновацияле «КАМАЗ»ларның баш конструкторы Сергей Назаренко сүзләренә караганда, ADAS 5 урнаштырылган кабиналы автомобильнең бәясе якынча 11-12 млн сум тәшкил итәчәк.

– Пилотсыз машина тәүлегенә 24 сәгать юлда булып, йөртүчеле гадәти автомобиль белән чагыштырганда, йөкне ике тапкыр күбрәк ташый, күбрәк акча эшли алачак. Йөк ташучылар үз финанс модельләрен әнә шул нигездә төзергә тиеш. Безнең ниятләр буенча, чыгымны каплау срогы 8–9 ай тәшкил итәчәк, – ди Назаренко.

Сүз уңаеннан, проектның өметле булуы күпмедер дәрәҗәдә анда катнаша торган компанияләр белән дә раслана. Алар арасында Volvo, «Россия почтасы», «Дәүләт транспорт лизинг компаниясе» һәм «ВТБ Инфраструктура холдингы», «Цифрлы транспорт һәм логистика» ассоциациясе, «Милли телематика системалары», «СберАвтоТех», «Эш линияләре», Globaltruck, «Беренче экспедиция компаниясе» (ПЭК) һәм X5 Group ширкәтләре бар.

Барлык машиналар да төзелеше 2022–2023 елларга планлаштырылган полигоннарда тикшерү узар, дип көтелә. Пилотсыз автомобиль берничә төрле тест биремен үтәргә тиеш булачак. Аннан соң ул тест режимында юлга чыгачак һәм, билгеле бер күләмдәге километрларны узгач кына, Федераль сак хезмәте, ЮХИДИ, Транспорт министрлыгы һәм Федераль иминлек хезмәте вәкилләреннән торган комиссия аны тулысынча файдалануга тапшыру һәм магистральгә чыгару турында карар кабул итәчәк.

ЦИФРЛЫ ЮЛ ЧАТЫНДА

Пилотсыз транспорт «күрү сәләте» (лидарлар) һәм «ишетү сәләте» (радарлар) белән җиһазландырылган һәм теориядә гадәттән тыш хәл очрагында дөрес эш йөртә ала (куркынычсыз рәвештә юлдан чыгып китә), ләкин нормаль хәрәкәт өчен аңа элемтә каналларына тоташтырылган, машинага читтән торып оператор яки идарә үзәге белән мәгълүмат алмашырга мөмкинлек бирәчәк махсус инфраструктура кирәк.

Мәскәүдәге Үзәк боҗра автоюлының шундый тапшыру җайланмалары белән җиһазландырылган участогын хәзер пилотсыз транспорт проектының иң актив инфраструктуралы партнерларыннан берсе булган Росавтодор компаниясе тикшерә. Тестлар әлегә пилотсыз машиналарда түгел, йөртүчесе булган автомобильләрдә уза, алар системага тоташтырылган, идарә итү системасы белән мәгълүмат алмашу мөмкинлеге биргән техника урнаштырылган. Сентябрь аенда «Эш линияләре», «ИТЕКО Россия», «Даймлер Камаз Рус», «Меркатор Холдинг», «ГЛОНАСС» АҖ, «Казан-Телематика» һәм «Капш Траффикком Руссия» Росавтодорның проект буенча партнёрларына әйләнде. Беренче нәтиҗәләр ел азагында күренәчәк.

Росавтодорның интеллектуаль транспорт системалары һәм цифрлаштыру буенча идарә рәисе урынбасары Виктория Эркенова сүзләренә караганда, М12 трассасында (йөк ташу базары вәкилләрендә ул аеруча зур кызыксыну уята) моңа тиңдәш система кертеләчәк. Хәзер пилотсыз автомобильләрне инфраструктурага һәм идарә үзәгенә тоташтыру схемалары эшләнә, юлның цифрлы «игезәге» – күчермәсе булдырыла, аны үзидарәле автомобильнең һәм/яки аның операторының компьютеры күрергә һәм «укып барырга» тиеш.

– Әлбәттә, юлдагы вазгыять – андагы тамгалар, билгеләр, вакыйгалар, һава торышы турында барлык мәгълүматның машина операторына онлайн режимда тапшырылып торуы зарур. Без моңа әзерләнәбез, – дип билгеләп үтте Эркенова.

Юлдагы Интернетка тоташтырылган транспортның бу челтәргә зур йөкләнеш китерүен исәпкә алып, Росавтодор 5G һәм DSRC ярдәмендә мәгълүмат тапшыруның төрле модельләрен тикшерә. Зур күләмдәге мәгълүматны куркынычсыз тапшыру – пилотсыз хәрәкәтне башлап җибәрүне тизләтәчәк төп мәсьәләләрнең берсе.

Транспорт министрлыгы күзаллавынча, юл инфраструктурасы белән дәүләт операторы идарә итәргә тиеш, ул юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркынычсызлыгын тәэмин итүгә җаваплы булачак. Пилотсыз машинаны исә коммерцияле тармак операторы контрольдә тота

КАМАЗ-54907.

Ralient компаниясенең пилотсыз автомобиле.

ала. Кирилл Богданов билгеләп үткәнчә, аларның үзара төгәл эше Россия территориясендә пилотсыз транспорт хәрәкәтен иң куркынычсыз итәчәк. Шул ук вакытта аларның вәкаләтләр балансын чынбарлыктагы йөк ташу тәҗрибәсеннән чыгып исәпләү планлаштырыла. Моның өчен пилотсыз автомобильләр М11 трассасында миллионнарча чакрым узарга тиеш. Эшне тизләтү өчен, йөк төялмәгән үзидарәле машиналарны М11 трассасының аерым участокларында киләсе елда ук йөртә башлау планлаштырыла.

БЕР КИРТӘ, ТАГЫН БЕР...

Әмма әлеге проектның төп максаты итеп каралган юридик затлар – эре ретейлерлар һәм йөк ташучылар моңа әзерме?

– Мин бу инициативаны хуплыйм, икътисадый яктан нәтиҗәле булачак ул. Әмма магистральләрдә йөк ташуга бәйле бөтен икътисад юл уңаенда илтелә торган йөкне китереп бирүгә нигезләнүен дә игътибарга алырга кирәк, шуңа күрә машиналар һәрвакытта да шул ук юлдан әйләнеп кайта алмаска мөмкин, – ди X5 Group компаниясенең транспорт директоры Кирилл Кузьменко.

Аның фикеренчә, финанс моделе булдыру өчен әлегә мәгълүматлар җитәрлек түгел – югары технологияле автомобильләргә хезмәт күрсәтү һәм юл инфраструктурасын куллануның коммерсантлар өчен күпмегә төшәчәге хәзергә билгесез.

– Транспорт компанияләрен һәм ваклап сату челтәрләрен нәтиҗәлелекне арттыру һәм табышны зурайту мөмкинлеге кызыксындыра. Пилотсыз проект аңлаешлырак булсын өчен, анда катнашучылар санының бик күп булуы кирәк, – ди Кузьменко. – Әмма эшләтеп җибәрү чорында һәр инновацияле проект бик кыйммәткә төшә. Бу максатка ярашлы субсидия яки махсус лизинг программалары булдырылсын иде. Ул чакта без, бизнес вәкилләре, күпләп шушы ысулга күчү турында уйлар идек.

Кирилл Богданов сүзләренә караганда, бу юнәлештә эш алып барыла инде – дәүләт чыннан да пилотсыз транспорт кулланып йөк ташуны субсидияләү мөмкинлеген тикшерә.

Проектка бәйле сораулар коммерция тармагы гына түгел, ә җәмәгать оешмалары вәкилләрендә дә туа.

– Проектны эшләүчеләр өчен төп бурыч – андагы технологияләрнең аңлаешлылыгын тәэмин итү. Хәзер бу проектның мәгълүмати кыры бик тар. Пилотсыз транспорт турында кешеләр гаммәви мәгълүмат чаралары аша нәрсә белә? Пилотсыз машинаның велосипедчыны бәрдергәнен яки Казанга барып җиткәненме? Ә асылда барысы да ничек булачагын бик азлар гына күз алдына китерә. Пилотсыз «КАМАЗ»ны эшләтеп җибәргән вакытта, ерак арага йөк ташу-

чылар трассага чыгып: «Без бер касә дөге өчен йөртәчәкбез», – дип әйтер дә бәлки, – ди РФ Дәүләт Думасы депутаты, Гомумроссия халык фронты Үзәк штабы әгъзасы, «ГХФ юл инспекциясе/Ватык юллар картасы» проекты координаторы Александр Васильев.

Васильевның гражданнарның юлдагы транспорт арасында роботлаштырылган күршеләрне психологик яктан кабул итәргә әзерлегенә бәйле шикләрен Кирилл Богданов та уртаклаша.

– Бездәге психологик киртә – бу процессның мөһим өлеше. Әйтик, «Яндекс.Такси» бик гадәти нәрсә кебек кабул ителә. Ә 20 тонналы йөк машинасы кабинада шоферсыз килеш кенә бара, ди, юлда аның янәшәсендәге автомобильдә исә – тәҗрибәсез шофер. Бу бит авария хәле китереп чыгарырга мөмкин, – дип саный ул.

Моннан тыш, пилотсыз транспортның гамәлләре һәм аның катнашында төрле ситуацияләр өчен җаваплылык мәсьәләсе ачык кала. Кайбер Европа илләрендә шәһәр эчендә автоматлаштырылган техника хәрәкәте кануннар белән күптән төгәлләштерелгән. Мәсәлән, Таллинда робот ярдәмендә продуктларны китерү хезмәте инде берничә ел эшли. Ул урам буйлап 6,5 км/сәг тизлек белән хәрәкәт итә, ә аның гамәлләре өчен, юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча, тулысынча оператор җавап тота.

Бу һәм башка күпсанлы мәсьәләләр чишелеш таләп итә – вакытында тормышка ашырылган пилотсыз коридор проекты илгә берничә юнәлеш буенча технологик лидерлык позициясен кире кайтарырга мөмкинлек бирәчәк.

– Хәзер Россия бик отышлы позициядә, шул исәптән Транспорт министрлыгы башлаган проект хисабына да. Пилотсыз транспорт белән шөгыльләнә торган компанияләр инфраструктураны тәэмин итүчеләр, ахыр кулланучылар белән элемтә урнаштырып җибәрү мөмкинлегенә ия. Көнбатыш компанияләре туктап калган проблемалы нокталарны урап узу өчен, бу – алдан хәстәрлек куелган бик шәп эш, – ди «СберАвтоТех» генераль директоры урынбасары Дмитрий Агафонов. – Рәсми регуляторны, юл хуҗаларын һәм пилотсыз автомобиль эшләүчеләрне түгәрәк өстәл артына беренче булып утырта алган кеше бу проектны дөньяда беренче булып тормышка ашырачак.

ИННОПОЛИСТА СЫНАЛГАН

Россиядә пилотсыз транспорт куллана башлау стартын якынайтуга пассажирлар ташу тармагы вәкиле зур өлеш кертә ала.

Көзен «Яндекс» компаниясе белгечләргә илдә беренче экспериментал хокукый режим программасы проектын тәкъдим итте. Ул үзидарәле автомобильләр, беренче чиратта – пилотсыз таксиларга – тест үткәрү өчен махсус зоналар булдыруны күздә тота. Документ пилотсыз автомобильнең гомуми транспорт агымына чыкканда үз-үзен тотышын, аның кулланучы һәм оператор белән үзара бәйләнешен, авария очрагындагы эш гамәлләрен һ. б. тасвирлап бирә.

«Яндекс»ның экспериментал хокукый режим программасы белгечләрнең беренчел бәяләмәсен алган инде, хәзер ул яхшыртыла, эшкәртелә һәм тиздән профильле министрлыкларга тапшырылачак. Пилотсыз таксиларга тест бу көздә үк башланачак, дип планлаштырыла. Шулай итеп, Мәскәү пилотсыз такси хезмәте эшли башлаячак Европада беренче һәм дөньяда икенче (Пекиннан соң) башкала булачак. Әмма Россиядә пилотсыз такси йөри башлаган беренче шәһәр Татарстан Иннополисы булды, анда йөртүчесез таксилар 2018 елда юлга чыкты (һәм шушы вакыт эчендә бер юл-транспорт һәлакәте дә булмады).

«Яндекс»ның пилотсыз транспорт тәҗрибәсе гамәлдәге законнарга кертелергә тиешле төзәтмәләрнең нигезен тәшкил итәчәк. Пилотсыз автомобильләр өчен экспериментал хокукый режимны гамәлгә ашыру өчен хокукый кыр әзер диярлек. Гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында югары дәрәҗәдә автоматлаштырылган һәм тулысынча автоматлаштырылган транспорт чараларын тәҗрибә рәвешендә куллану эксперименты рөхсәт ителгән 14 төбәк расланды, «Югары дәрәҗәдә автоматлаштырылган һәм тулысынча автоматлаштырылган транспорт чаралары турында» Федераль закон проекты, РФ Транспорт министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясендә Интеллектуаль транспорт системаларының илкүләм челтәрен булдыру һәм эшләтү концепциясе проекты әзерләнде.

* «Экспериментал хокукый режимнар турында» Федераль законга РФ Президенты Владимир Путин 2020 елда кул куйды. Экспериментал хокукый режим турында закон инновацияле цифрлы проектны гамәлгә ашыру өчен канундагы аерым таләпләрне үзгәртү мөмкинлеген бирә. Моның өчен проектның инициаторы үзенең программасын якларга тиеш (*Ред. искәрмәсе*).

Үзәк божра автомобиль юлы.

ЙОЛДЫЗЛАР АРАСЫНДАГЫ ШАР

Кешелек тарихының космик чоры башлану 1957 елда дөньяның ПС-1 дип тамгаланган беренче ясалма иярченен галәмгә җибәрү хөрмәтенә, рәсми рәвештә 4 октябрьдә билгеләп үтелә. Космоска ишек ачкан күренекле галимнәр командасында якташыбыз Урал Закиров та була.

Автор:
Ксения Сёмина

– Без Җирне түгәрәк формада дип санарга күнеккән. Ә чынлыкта ул – эллипс. Җисем Җир тирәли әйләнгәндә, һәр нокта өчен гравитациясе төрлечә булачак, – дип сөйли Урал Закиров. – Орбита буенча хәрәкәт итәчәк очу аппараты траекториясен исәпләү өчен, очышның теләсә кайсы мизгелендә әлеге гравитациянең нинди дер уртача зурлыгын санап чыгарырга кирәк. Ә 1950 нче елларда кулыбызда ЭВМнар юк иде әле. Барлык исәпләүләрне дә кулдан башкардык!

Легендар 4 нче фәнни-тикшеренү институтына (хәзер Россия Оборона министрлыгының 4 нче Үзәк ФТИ) Урал Закиров ПС-1 аппараты җибәрелгәннән соң бер ел узгач кабул ителә.

ГАЛӘМ ПИОНЕРЛАРЫ

Яшерен 4 нче ФТИ җыйнак кына Болшево бистәсендә (хәзер – Юбилейный микрорайоны, Мәскәү өлкәсендәге Королёв шәһәренең тарихи өлеше) зур бина билгәгән. Һәр тарафтан матур авыл манзарасы урап алган институт эчендә эш даими кайнап тора. Әйтик, зур кабинетта кызларның, ару-талу белмичә, өстәлләрдәге арифмометрлар тоткасын әйләндерүен күрергә була. Илебездәге беренче очу аппаратларының траекториясен исәпләү әнә шулайрак башкары-

ҖИРНЕҢ БЕРЕНЧЕ ЯСАЛМА ИЯРЧЕНЕНЕҢ ОЧЫШЫ
ПС-1 ИЯРЧЕНЕН 228 КМ БИЕКЛЕККӘ Р-7 РАКЕТАСЫ ЧЫГАРА. ИЯРЧЕН ҖИР ТИРӘЛИ 1440 ӘЙЛӘНЕШ ЯСЫЙ, аның радиотапшыргычлары очышның беренче өч атнасы дәвамында һәр 0,4 секунд саен эфирга «бип-бип» дигән хәбәр җибәреп тора. 1958 елның 4 гыйнварында иярчен атмосфераның тыгыз катламнарына керә һәм янып бетә.

ла. Әлеге 4 нче институтта беренче электрон хисаплау машинасы 1950 нче еллар азагында гына пәйда була.

– Безгә кадәр астрономия – галәмдә барлыкка килеп торган яки анда булган җисемнәр турында фән генә бар иде. 4 нче институт хезмәткәрләре, кешелек тарихында беренчеләрдән булып, Җир өслегеннән очып киткән һәм орбита буенча очышын дәвам иткән яки башка планетага юнәлгән җисемнәрнең траекторияләрен исәпләде, – ди Урал Закиров.

Институт командасына Урал Закиров инженер-физик буларак керә. Бу вакытка ул Рига Югары инженерлык-авиация училищесын тәмамлап, Кырымда хезмәт итеп алган була һәм СССР Оборона министрлыгы күрсәтмәсе белән 4 нче фәнни-тикшеренү институтына җибәрелә. Яшь белгечкә исәпләү эшен һәм проект документациясен әзерләүне, ә соңрак автомат станцияләр һәм космик кораблар өчен җиһазлар сайлап алуны, аларны урнаштыру эшен контрольдә тотуны ышанып тапшыралар. ПС-1 аппаратын уңышлы очырганнан соң, институт Ай, Марс, Венерага җибәреләчәк ясалма иярченнәрнең, шулай ук пилот белән идарә ителә торган космик корабларның очышын әзерләү эшенә җәлеп ителә. Бортында Лайка кушаматлы эт утырган икенче ПС-2 иярчене орбита тирәли җибәрелә. Ләкин җиңүләр килгәнче, бик күп уңышлы һәм уңышсыз сынау-омтылышлар ясала.

ОЧЫШТАГЫ ЭКСПЕРИМЕНТЛАР

Очышлар белән турыдан-туры институттан идарә итәләр. Һәр очыш чып-чын сынау була. Көтелмәгән хәлләр теләсә кайсы этапта килеп чыга ала. Проблемаларны кайчак очыш вакытында хәл итәргә туры килә.

1950 нче еллар азагында Айга беренче станцияләр юл ала. Урал Закиров иң әһәмиятлеләрдән берсе – Җирнең табигый иярчене орбитасына «Луна-1» автомат станциясен җибәрүдә катнаша. Уңышлы старттан соң проектның төп баллистиклары Георгий Нариманов, Анатолий Брыков һәм Павел Эльясберг аппаратның Айга таба хәрәкәте турында җитәкчелеккә телефоннан бертуктаусыз хәбәр итеп тора. Очышны

1 Җирнең беренче ясалма иярчене.

2 «Луна-9» станциясе.



3

«Восток-1» корабы моделе.

4

«Луна-9» автомат станциясенең очыш нечкәлекләре бөтен кешене кызыксындыра. Мәскәүнең Краснопресненский районы 138 нче мәктәбе укучылары гыйльми консультант Е.Шишкина сөйләвен тыңлый.

инженер-полковник Георгий Тюлин күзәтеп тора. Кайсыдыр бер мизгелдә Тюлин Бөекбританиядәге Джодрелл-Бэнк обсерваториясе җитәкчелеге белән элемтәгә керергә һәм аларның телескоплары ярдәмендә «Спутник»ның траекториясен үлчәү эшенә кушылуларын сорарга куша – ул чакта бездә күзәтү җайланмалары җитешми. Элемтәче миссиясен Урал Закиров үти. Телескоп эшкә җигелә.

Тиздән якташыбыз Сергей Королёв җитәкләгән 1 нче Тәҗрибә-конструкторлык бюросының 9 нчы бүлегенә эшкә күчә. Күренекле инженер Михаил Тихонравов җитәкләгән бүлекнең төп бурычы – киләчәктә Юрий Гагарин күккә күтәреләчәк «Восток» пилотлы очу аппаратын проектлау була. Урал Закиров Белка һәм Стрелка утыртылган «Спутник-5» һәм бортында Чернушка кушаматлы эт һәм Иван Иванович манекены булган «Восток» корабын җибәрүне күзәтә.

Соңрак Гагарин очачак «Восток» корабын төзү белән проектант һәм киләчәктә гади гражданнардан беренче космонавт булачак Константин Феоктистов җитәкчелек итә. Эшне кире кайтарыла торган капсуланың оптималь формасын сайлау мәсьәләсе тоткарлый. Конус, кире конус, зонт формасы һәм башка вариантлар карала. Төп чишелешне дә Феоктистов үзе таба: Җиргә

төшү шартларында иң яхшы тотрыклылык үзлегенә шар формасындагы җисем ия булачак. Тик шар атмосферада әйләнә-бөтерелә башласа, парашют ачылырмы икән, дигән сорау да туа.

– Төшке аш вакытында без бүлектә гадәттә пинг-понг уйный идек. Һәм шул чакта кемнеңдер башына шарны прототип сыйфатында кулланып булуы турындагы уй килде. Эчендәге өстәмә авырлыкны имитацияләү өчен, шарга кечкенә генә пластилин кисәген ябыштырып, икенче катның баскыч арасыннан аска ташлый башладылар. Шар гел шул ябыштырылган ягы белән төште. Шарның тотрыклылыгы әнә шулай эксперименталь рәвештә расланды, – дип искә ала Урал Закиров.

МӘҢГЕЛЕК АЙ ЯКТЫСЫ

Беренче космонавтларның уңышлы очышларыннан соң, әкренләп Ай экспедициясен әзерләү проекты активлаша башлый. Әлеге проектны, СССР Фәннәр академиясе президенты Мстислав Келдыш ярдәменә таянып, Королёв алга этәрә. 1966 елда бик зур адым ясала – «Луна-9» станциясе беренче тапкыр Айга йомшак кына төшеп утыра һәм тугыз элемтә сеансы үткәрә. Шул чакта ул Җир тарихында тәүге мәртәбә Ай өслегенең панорамалы өч сурәтен төшереп җибәрә. Галимнәр Ай туфрагының үзлекләре, планетадагы һәм очышның бөтен траекториясендәге космик нурланыш турында мәгълүмат ала, бу исә пилот белән идарә ителә торган корабта Айга очыш программасын эшләүчеләр өчен бик кыйммәтле материал була.

1960 нчы елларның икенче яртысында СССРның космоска очышлар тармагы планетаара пилотсыз автомат станцияләр җибәрү технологиясен үзләштерә. Аларны галәмгә чыгару өчен, беренче иярченнәрне күккә күтәргән шул ук ракеталар кулланыла, тик алар камилләштерелгән була. Әмма Айга төшеп утыруны күздә тоткан очышлар күпкә куәтлерәк ракета-йөртүче таләп итә. Шулай итеп «Протон» төзелә.

Ул вакытта Урал Закиров Байконур космодромында Ай аппаратын сынау белән шөгыльләнә, космик проектларның легендар катнашучылары, шул исәптән Юрий Гагарин белән очраша.

«Протон»ның премьерасын якташыбыз болай дип искә төшерә: ангардан двигательле галәмәт зур нәрсә чыгардылар. Алгы ягы өй хәтле диярлек. «Протон» бик ышанычлы күренә, әмма аның чыннан да уңышлы дип бәяләрлек старты күпкә соңрак була әле.

1968 елда Айга җан иясе утырган «Зонд-5» корабын очыртып җибәрергә әзерләнәләр. Аны технологик яктан әзерләүдә Урал Закиров та катнаша, бортка фотоаппаратураны да урнаштырырга булыша. Пассажир сыйфатында аппаратка ташбакалар утырталар. Очыртып җибәрү процессы белән идарә бункердан башкарыла. «Зонд»ның операторы сыйфатында Урал Закиров «Протон» операторы янәшәсендә утыра. Чират җиткәч, ул датчикларны тикшерә, барысының да нормада икәнлеген күргәч, «Очарга ярый!» ди. Шул вакытта якында гына ракета дөбер-шатыр гөрелди башлый... «Зонд-5», бик үк мавыгарасыз булмаса да, үз миссиясен үти – Айны очып әйләнеп чыга һәм Җирне сурәткә төшерә. Дөрес, йолдызлы тапшыргыч эштән чыгу сәбәпле, аппарат Казахстан урынына Һинд океанына төшеп утыра. Ә шулай да ташбакалар исән кала. Урал Нури улына аппараттан төшерелгән фотолар белән кассета бүләк итәләр. Ул әле «Зонд»ның тычка кисәген дә истәлеккә каерып ала...

Ни кызганыч, СССРның Айга очу ярышында беренчелек турындагы нияте тормышка ашмый. Нил Армстронг Айга төшкәч, табигый иярчингә очышларны күздә тоткан совет программасы туктатыла.

P. S. Быел «Роскосмос» дәүләт корпорациясенең гайре авыр ракета-йөртүче ярдәмендә Айга очышлар программасы белән шөгыльләнүне дәвам итүе билгеле булды.

5

Айны әйләнеп чыгу өчен бортында җан ияле «Зонд-5» корабы.

БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН:

Урал Закиров 1933 елның 22 октябрендә Свердловскида туа, балачагы Татарстанда үтә. Хәрби-һава көчләренең Ворошилов исемендәге Югары инженерлык-авиация училищесын (Рига, 1957 ел), Мәскәү дәүләт университетын (1966 ел) тәмамлый. Хәрби-Диңгез флотының Хәрби-һава көчләрендә хезмәт итә (1957–1959 еллар), хәрби фәнни-тикшеренү институтында космос бүлеге гыйльми хезмәткәре (1959–1960 еллар), Сергей Королёвның конструкторлык бюросында әйдәп баручы инженер (1965–1971 еллар) булып эшли. СССР Фәннәр академиясенең Гамәли математика институтында, Казан авиация институтында, Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техника институтында, РФА Казан фәнни үзәгенең Механика һәм машина төзелеше институтында фәнни тикшеренүләр белән шөгыльләнә. Галимнең эшләре проект баллистикасы, гравитация кыры потенциалы һәм энергиясе проблемаларына, ул үзе тәкъдим иткән атом-төш синтезы һәм аннигиляция энергиясе ярдәмендә тормышка ашырыла торган реактив хәрәкәт концепциясенә багышланган. Тикшеренүләр киләчәктәге планетаара һәм йолдызара космик очышларның фәнни нигезләре темасына да кагыла.

PRESSA

ЭССЕ ҖӘЙНЕҢ КАЙНАР ИКМӘГЕ

Гадәттән тыш корылык, эссе һава… Болар барысы да Татарстан игенчеләре өчен яздан башлап урак өстенә кадәр дәвам иткән көчле сынау булды. Шуңа да экстремаль шартларда җыеп алынган 2,4 миллион тонна ашлык бик кадерле.

Татарстанда узган елны җыеп алынган биш миллион ярым тонна уңыш фонында бүгенге 2,4 миллион тонна – бик тыйнак нәтиҗә. Әмма һава торышы ягыннан уңай 2020 елны быелгы экстремаль җәй белән чагыштыру дөрес булмастыр.

ЭССЕ ҖӘЙ ФОНЫНДА САЛКЫН АКЫЛ

Быел авыл хуҗалыгы тармагы кичергән корылык унбер ел элек басу-кырларга ябырылган афәтне хәтерләтте. Ул чакта, 2010 елда, шундый ук диярлек шартларда, республикабыз аграрийлары бары тик 700 мең тонна ашлык үстерә алды. Быелгы уңыш дүрт мәртәбәгә

ЭССЕ ҖӘЙ ХРОНИКАСЫ

Майның икенче яртысы.
ТР Хөкүмәте йортында узган киңәшмәдә ТР Премьер-министр урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җаббаров болай диде: гадәттән тыш эсселек (йөзьеллык температура рекорды) туфракны җитди корытты һәм сабан ашлыгы чәчелгән кырларда чүп үләннәренең һәм корткычларның бик тиз артуына китерде. Уҗымнар белән әлегә хәлләр яхшырак, җитештерү технологияләре сакланган урыннарда проблемалар бөтенләй юк диярлек. Әмма хәзер һәм алга таба ныклы эш таләп ителә: уҗым культураларының потенциалын саклап калу өчен, тамырдан һәм яфрактан тукландыруны уздыру бик мөһим, дип кисәтте министр.
Терлекчелек секторында вазгыять шулай ук җиңел түгел. Республика көн саен биш тонналап сөтне кимрәк ала: сыерлар эсселектән стресс кичерә. Су тоткарлыкларсыз китерелә, сыер абзарларындагы микроклимат булдыра алганча оптималь – болар һава торышы аномалиясе китерә торган уңайсызлыкларны йомшарту мөмкинлекләре.
Әлегә өмет өзелми: менә-менә яңгырлар китәр, һәм кырлардагы, фермалардагы вазгыять яхшыга үзгәрер кебек.

ИЮНЬ.

Яңгырлар юк, кояш һәм эсселек авыл хезмәтчәннәрен ныклыкка сынавын дәвам итә. 30 июньдә Гадәттән тыш хәлләр буенча республика комиссиясе утырышында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов вазгыятьнең җитдилеген аңлата: «Республикада һава торышы, продуктив яңгырларның булмавы авыл хуҗалыгы культуралары уңышын формалаштыру һәм аны алу мөмкинлеген куркыныч астына куя. Килеп туган вазгыятьне тикшерергә һәм эссе һава торышының тискәре йогынтысын җиңү һәм республикада азык-төлек иминлеген саклау буенча уртак чаралар эшләргә кирәк».
ТР Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне монито-

диярлек күбрәк. Бу әгәр игенчелектә инновацияле технологияләр кулланылса, уңайсыз шартларда да лаеклы нәтиҗәгә ирешеп булганны раслый.

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында мондый технологияләр арасында, атап әйткәндә, дым җыю һәм дым саклау технологияләрен мисалга китерәләр. Көзен туфракны тирәнтен эшкәртү, туфрак өслегендә органик калдыкларны туплау юлы белән игенчелекне биологизацияләү, эремә комплекслары, ниһаять, язгы чорда туфракны эшкәртү санын киметү (бу очракта бер йөрештә бишәр операция башкарырга сәләтле чәчү комплекслары ярдәмгә килә) – корылыкка да карамастан, яхшы уңыш алуга ирешкән хуҗалыклар тарафыннан кулланылган ысулларның берничәсе генә.

Кайбер урыннарда онытылганнарны куллану да ярап куйды. Мәсәлән, урман саклау полосалары. Алар туфракны эрозиядән саклый, чәчүлләрне коры җилләрдән якларга сәләтле һәм һәр кырның үз микроклиматын булдыра. Корылыкка каршы торуның тагын бер ысулы – эсселекне һәм корылыкны җиңел кичерә торган культуралар игү. Сентябрь киңәшмәләренең берсендә ТР Премьер-министр урынбасары – авыл хуҗалыгы министры Марат Җаббаров кукурузны

бөртеккә җыю нәтиҗәләре турында чыгыш ясап болай диде (ул вакытка 13,5 мең гектардан 43,2 мең тонна алынган иде): «Технологик таләпләрне саклаган очракта кукуруз хәтта корылык шартларында да башаклылардан 2-3 мәртәбә күбрәк уңыш бирергә сәләтле». Алай булгач, киләсе елларда «кырлар патшабикәсе» чәчүлекләрен арттыруның файдасы булмасмы?

БӘРӘҢГЕ, ШИКӘР, ЯШЕЛЧӘЛӘРГӘ КЫТЛЫК БУЛМАЯЧАК

Корылык елында аграрийлар үстергән һәм җыеп алган уңыш җитәрме соң? Август азагында, бөртекләрнең уңышы җыелып беткәндә, кайбер позицияләр буенча беренче фаразлар яңгырады. Аерым алганда, Марат Җаббаров болай дип хәбәр итте: миллион тонна шикәр чөгендерен җыеп алу планлаштырыла (шикәр базары тенденцияләрен исәпкә алып, чәчү җирләре ике мең гектарга арттырылган), шулардан 160 мең тонналап шикәр комы җитештереләчәк, бу республика ихтыяҗын 130 процентка капларга мөмкинлек бирәчәк. Бәрәңге дә җитәчәк. 10 сентябрьгә 800 гектарда (мәйданнарның 21 проценты) бәрәңге җыеп алынган, уртача уңдырышлылык гектарыннан 155 центнердан артык.

ринглау идарәсе башлыгы Сергей Захаров хәбәр итә: узган айда вазгыятьнең яхшы якка үзгәреше күзәтелмәде – «июнь температура һәм явым-төшемнәр күзлегеннән караганда аномаль булды». Барысы да соңгы өч дистә ел эчендә без өч мәртәбә узган сценарий буенча бара – корылыклы 1989 нчы, 1998 нче һәм 2010 нчы еллар. «Бүген явым-төшемнәр фронталь характерда түгел, локаль рәвештә бара, – дип төгәллек кертте Сергей Захаров. – Туфракта дым запасы бик аз – 100 мм дан кимрәк. Дымның җитмәве уңышның формалашуына тискәре йогынты ясый». Эсселек һәм яңгырның ике-өч районда, хәтта республикадагы районнарның яртысында гына түгел, күпчелегендә булмавы бигрәк тә борчуга сала. Гидрометеорология идарәсе шуны раслый: куркыныч агрометеорология күренешләре 38 районда күзәтелә. Коры җилләр 34 муниципаль районда теркәлгән. Туфрактагы корылык– 18 районда. Атмосферадагы корылык – Мөслим һәм Сарман районнарында.
38 районда муниципаль дәрәҗәдә гадәттән тыш режим кертелә. Гидрометеорология идарәсенең куркыныч агрометеорология күренешләрен рәсми рәвештә теркәве үз чәчүлекләрен иминиятләштергән хуҗалыклар өчен иминият түләвен алырга нигез булып тора. Хәзер иң мөһиме – үсемлекләр үсешенә әлеге куркыныч күренешләрнең йогынтысын теркәү өчен иминият компаниясенә үз вакытында мөрәҗәгать итеп өлгерү. Форс-мажор вазгыять авыл хуҗалыгы берләшмәләренә инвестицияле һәм кыска сроклы кредитларны, шулай ук башка йөкләмәләрне озайтырга мөмкинлек бирә.

ИЮЛЬ.

Туфракның бер метр тирәнлектәге катламында дым белән тәэмин ителгәнлеге буенча вазгыять канәгатьләнерлек түгел. Кайбер районнарда туфракның сөрү катламында продуктив дым 10 мм дан кимрәк. Гидрометеоүзәк шул арада тагын өч төбәк – Алексеевск, Буа, Мамадыш муниципаль

районнарында куркыныч күренеш (коры җил) күзәтелүен раслый. Эсселек һәм корылык күпьеллык графикларны үзгәртергә мәҗбүр итә. Календарьда әле 10 июль генә, әмма кайбер хуҗалыклар инде уҗымны җыярга керешә. Беренче 5,3 мең гектардан иген суктырыла, уңыш гектарыннан 20,2 центнер чыга. Якын көннәрдә районнарның барысы да уҗым уңышын җыярга керешәчәк. Кичегергә ярамый: мондый һава торышы шартларында бөртек һәр көнне гадәттәге 1–1,5% урынына 3%ка кадәр дымын югалта. «Бөртеклеләрнең тулай җыемы күп көтелми, ләкин урып-җыю җиңел булмаячак, – ди Марат Җаббаров. – Тәбәнәк, кыска саламлы кырлар күп. Агымдагы елда бөртек вак һәм ач булып формалаша».

Терлек азыгын әзерләү дә катлаулы. 10 июльгә 274 мең тонна печән һәм 1 млн 240 мең тоннадан артык сенаж әзерләнә, бу 1 шартлы терлек башына 9,4 ц азык берәмлеге дигән сүз. Чагыштыру өчен: узган ел бу вакытка 15,5 ц азык берәмлеге әзерләнгән була. Вазгыятьне үзгәртү өчен ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы корылыктан зыян күрмәгән күрше төбәкләрдә печән, сенаж һәм ашлык табуны һәм сатып алуны оештыра. Республика авыл җирлекләре актив рәвештә терлек азыгы әзерли. Муниципаль районнарда азык әзерләү буенча механикалаштырылган отрядлар оештырыла.

АВГУСТ.

Ай ахырына республикада бөртеклеләрне урып-җыю тәгалләнә диярлек була. Уңайсыз һава шартларына карамастан, 2,4 млн тонна ашлык җыеп алына, уңдырышлылык – гектарыннан 15,4 центнер. Әле бөртекле кукурузны, көнбагыш, шикәр чөгендере, бәрәңге һәм яшелчә җыясы бар. Ким дигәндә бер миллион тонна чөгендер тамыразыгын җыеп алу көтелә. Урып-җыю эшләре белән бергә 2022 ел уңышына нигез салу – уҗым чәчү һәм туфракны эшкәртү буенча төп эшләр алып барыла. Уҗым басуы барлык

Гомумән алганда, халыкны бәрәңге белән тәэмин итүдә проблемалар күзәтелми, дип ышандырдылар министрлыкта. Башка яшелчәләр, суган да җитәрлек күләмдә үстерелгән.

Терлек азыгы белән вазгыять катлаулырак. 11 сентябрьгә ихтыяҗның 65 процентын капларлык азык әзерләнгән, ләкин авыл хуҗалыгы предприятиеләре силоска кукуруз салуны дәвам итә. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларда, узган елдан калган азыкны исәпкә алып, 917 мең тонна тупас һәм сусыл азык – ихтыяҗның 97 проценты инде хәстәрләнгән.Барлыгы тагын җиде мең баш терлек өчен азык әзерләргә кирәк.

Хәер, элегрәк аграр ведомствода тиешле күләмнәргә ирешүгә юнәлдерелгән чаралар билгеләнгән инде. Аерым алганда, бөртеккә дип үстерелгән кукурузның бер өлешен терлек азыгына салырга карар кылганнар. Тагын әле 11 сентябрьгә төрле каналлар буенча хуҗалыкларга 270 мең тонна бөртек фуражы бүлеп бирелгән (ихтыяҗның 87 проценты). Шәхси хуҗалыкларда савым сыерларын тотуга субсидияләр бирү каралган.

Бөртеклеләр уңышына килгәндә, ул барыбер безнең ихтыяҗдан түбәнрәк – гадәттә республикага, терлек азыгына бара торган ашлыкны исәпкә алганда, 3,3 миллион тонна кирәк. Җитеп бетмәгәнен кырыйдан сатып алачакбыз. Россиядә азык-төлек бодаена кытлык булмаячак.

АНОМАЛЬ ТЕМПЕРАТУРАЛАРНЫҢ АКЧАДА ЧАГЫЛЫШЫ

Аграрийларның барлык тырышлыкларына карамастан, корылык барыбер шактый зыян китерде. Күптән түгел РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко рәислегендә узган видеокиңәшмәдә чыгыш ясап, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов болай диде: «Уңышны саклап калу өчен, без барысын да эшләдек. Әгәр корылыклы 2010 елда бары тик 700 мең тонна ашлык җыя алсак, быел кукуруз белән бергә 2,5 млн тонна булыр, дип көтәбез. Ләкин бу җитәрлек түгел». Аның сүзләренә караганда, гадәттән тыш эсселек эре хуҗалыкларга да, кечеләренә дә сизелерлек зыян китергән. Моннан тыш, шәхси хуҗалыклар да җитди авырлыкларга дучар булган. Татарстан Президенты Дмитрий Чернышенкодан әлеге теманы хөкүмәт дәрәҗәсендә күтәрүен һәм корылыктан зыян күргән төбәкләргә ярдәм күрсәтүне үтенде.

Республика аграрийларының югалтулары 28 миллиард сумлык дип бәяләнә – һава торышының начар булуы аркасында нәкъ менә шул суммалык продукция алынып бетмәгән. Чөгендер үстерүчеләр генә дә биш еллык уртача күрсәткеч белән чагыштырганда 1,3 миллион тоннага якын тамыразыктан коры калган, бу җитди финанс югалтуларына китергән.

Һава торышы китергән күңелсезлекләргә бәйле авыр вазгыятьтә гадәттә чәчүлекләре иминиятләштерелгән хуҗалыклар ота. Бу хакыйкатьне әкренләп аңлый башлаганнар инде. Быел республикада 278 мең гектардагы чәчүлек иминиятләштерелгән. Бу узган ел белән чагыштырганда ике мәртәбәгә диярлек күбрәк.

бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар чәчеләсе кырларның 30% ка якынын алып тора. Шәхси хуҗалыкларда, былтырдан калганнарны исәпкә алганда, 872 мең тонна тупас һәм сусыл азык әзерләнгән, бу ихтыяҗның 92%ын тәшкил итә. Тагын 21 мең баш терлеккә азык әзерләргә яисә сатып алырга кирәк. Төрле каналлар (пай җирләрен арендалаганга түләү, сатып алу) буенча 240 мең тонна бөртек-фураж (ихтыяҗның 77%ы) бүлеп бирелгән.

СЕНТЯБРЬ.

Татарстан Президенты видеоэлемтә буенча РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко рәиселегендәге киңәшмәдә катнаша: «Соңгы мәртәбә мондый корылык 2010 елда булды, быел вазгыять кабатланды, – дип хәбәр итә Рөстәм Миңнеханов. – Уңышны саклап калу өчен, без барысын да эшләдек. Әгәр корылыклы 2010 елда без бары тик 700 мең тонна ашлык җыя алсак, быел кукуруз белән бергә 2,5 млн тонна булыр, дип көтәбез. Ләкин бу җитәрлек түгел». Аның сүзләренә караганда, гадәттән тыш эсселек эре хуҗалыкларга да, кечеләренә дә сизелерлек зыян китергән. Моннан тыш, шәхси хуҗалыклар да җитди авырлыкларга дучар булган. Татарстан Президенты Дмитрий Чернышенкодан әлеге теманы хөкүмәт дәрәҗәсендә күтәрүен һәм корылыктан зыян күргән төбәкләргә ярдәм күрсәтүне үтенә.

Республикада традицион көзге авыл хуҗалыгы ярминкәләре эшли башлады. «Без быел авыл хезмәтчәннәренең билгеле проблемалары булуын аңлыйбыз, чөнки җәй коры килде. Ләкин яшелчәләрне һәм бәрәңгене без җитәрек күләмдә кайтартабыз. Безнең бөтен шәһәрләрдә уңайлы сату мәйданчыклары булырга тиеш. Бу эшне оештырырга кирәк, – дип мөрәҗәгать итте Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә катнашучыларга.– Бәяләрне, ә иң мөһиме, продукциянең сыйфатын күзәтеп торыгыз».

«ТАТАГРОЛИЗИНГ» АҖ «АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ТЕХНИКАСЫН ИРТӘ БРОНЬЛАУ» ПРОГРАММАСЫН ЭШЛӘТЕП ҖИБӘРӘ

Сезонга техникалы булу өчен, аны бүген үк сатып алыгыз!

ШАРТЛАРЫ:

- Төп бурыч буенча түләүне 2022 елның 1 сентябренә кадәр кичектерү
- Беренчел кертем – 20%
- Лизинг срогы – 5 елга кадәр
- Акциянең гамәлдәге срогы – 2021 елның 31 декабренә кадәр

«Татагролизинг» АҖ яңа техника модельләренең, шулай ук яхшы хәлдәге тотылган техниканың киң рәтен тәкъдим итә.

ЧӘЧҮ КАМПАНИЯСЕНӘ ӘЗЕРЛӘНҮ МӨМКИНЛЕГЕН БҮГЕН ҮК КУЛДАН ЫЧКЫНДЫРМАГЫЗ!

АКЦИОНЕРНОЕ ОБЩЕСТВО
ТАТАГРОЛИЗИНГ

Түбәндәге телефоннар буенча заявка бирергә һәм тулырак мәгълүматны белергә була:
+ 7 (927) 487-17-25
+ 7 (987) 291-97-93

Фотолар «Татагролизинг» АҖнән алынды. Реклама.

«МИРОВЕТ» КОМПАНИЯСЕННӘН КИЛӘЧӘК ПРОЕКТЫ

Россия Федерациясенең яңа азык-төлек иминлеге доктринасына ярашлы рәвештә, россиялеләрнең ит һәм ит продуктлары белән үз-үзләрен тәэмин итү дәрәҗәсе 85% тан да ким булмаска тиеш. Азык-төлек өлкәсендәге куркынычсызлык нигезендә авыл хуҗалыгының фәнни базасын киңәйтү, үсемлекчелек һәм терлекчелектәге селекция ята.

Ит терлекчелеген үстерүнең тиз үсештәге һәм табышлы юнәлешләреннән берсе – кроссбридинг технологияләре. Гади тел белән әйткәндә, генетик яктан ярашмаган сорт, линия һәм токым вәкилләрен кушу.

Россиядә ит терлекчелеген үстерү перспективалары күбесенчә ак-зәңгәр Бельгия токымлы мөгезле эре терлекнең генетик материалын куллану белән бәйле. Илебездә әлеге токым орлыгы белән эксклюзив рәвештә тәэмин итеп торган ширкәт – «МИРОВЕТ» ҖЧҖ. Бүген ул Татарстан Республикасында нәселле продукция җитештерү һәм аны китереп бирә торган эре төбәк оешмасы белән тыгыз хезмәттәшлек итә.

Төрле токым кушылган хайваннарның төп өстенлеге – асрау һәм ашату шартларына талымсызлык, авыруларга чыдамлык һәм, иң мөһиме, җитештерелә торган итнең югары сыйфатлылыгы. Бу терлекләрнең итләре майлы түгел, диетик, тәмле һәм кеше сәламәтлеге өчен файдалы.

Моннан тыш, катнаш токымлы яшь ярымлык тана һәм үгезләрнең тере авырлыгы 680–720 кг га җитә һәм шул ук яшьтәге гадәти терлекнекеннән 100–200 кг га артып китә. Бу исә авыл хуҗалыгы җитештерүчесенә терлек азыгының югары конверсиясе хисабына гадәти рационда 20–50 мең сум күләмендә өстәмә табыш китерә. Әлеге токым орлыкларын еш кына сөт сыерлары көтүендә берничә тапкыр гади орлык белән уңышсыз аталандыру очрагында кулланалар.

«МИРОВЕТ» компаниясе шулай ук терлекчелек хуҗалыкларын төрле чирләрдән дәвалауның инновацияле системасын, сыерларның баш санын арттыруны стимуллаштыру һәм репродуктив сыйфатларын торгызу алымнарын, антибиотиклар куллануны күздә тотмаган, үз илебездә җитештерелгән нәтиҗәле дәвалау-профилактика препаратларын тәкъдим итә.

– Кайбер кулланучылар ак-зәңгәр Бельгия токымы итенең табигыйлегенә шикләнә, гормоннар һәм стероидлар ярдәмендә генә җитештерүчәнлекнең шаккатыргыч нәтиҗәләренә ирешергә мөмкин, дип ялгыша, – ди «МИРОВЕТ» ширкәтенең Татарстан һәм Башкортостан Республикаларындагы вәкиле Рәсүл Саттаров. – Белешмә өчен: ит сәнәгатендә гормоннар куллану Европада 1996 елда ук тыелган. Ул чакта мондый мускулатура каян соң? Бар сер йөзьеллык селекциядә яшеренгән. Генетик сайлап алу нәтиҗәсе бүгенге кебек терлек барлыкка килүгә мөмкинлек биргәнче, бинаһая күп вакыт уза.

«МИРОВЕТ» ҖЧҖ белгечләре фикеренчә, җитештерүнең нәтиҗәлелеге һәм продукция сыйфаты терлек үстергәндә кулланыла торган азык һәм су сыйфатына гына түгел, малтуарны дәвалаганда препаратларны дөрес һәм профессиональ дәрәҗәдә файдалануга да бәйле. Бүген компания кейсында тиңе булмаган шундый берничә препарат һәм вакцина бар. Әйтик, Туканолин, Ваколин, Ниацид-К, Олин кебекләрнең тәэсир итү дәрәҗәсе бик югары. Аларның нәтиҗәлелеге фәнни тикшеренүләрдә һәм тормышта күп тапкырлар исбатланган. Компания тәэмин иткән орлык материалына һәм дәвалау препаратларына карата җитештерүче терлекчеләрдән мактау сүзләре ишетү рәхмәт белдерүнең иң яхшы рәвеше ул, дип саный Рәсүл Саттаров:

– «МИРОВЕТ» ҖЧҖ белән хезмәттәшлек итә башлаганнардан күбесенең соңыннан да партнерларыбыз булып калуы бик күңелле. Бүген без гамәлгә ашыра торган проект авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын җайга салуны күздә тоткан дәүләт программасына туры килә, россиялеләрнең сыйфатлы һәм экологик яктан чиста азык-төлек продуктларына ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерүгә һәм кешеләрнең тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән. Бу киләчәк проекты түгелмени?

P.S. «МИРОВЕТ» ҖЧҖ кроссбридинг технологиясе ярдәмендә чыгарылган 2 атналык, 6 айлык, 1,5 яшьлек үгез һәм таналарны базар бәясеннән югарырак хакка сатып алырга әзер.

Компаниянең сайты: bbb.moskow
E-mail: bbg-bbb@bk.ru
Адресы: 141201, Мәскәү өлкәсе, Пушкино шәһәре, Соколовская ур., 23 нче корылма, 1 нче бина.
Үсеш директоры – Шайбель Алексей Яковлевич, тел.: 8-965-136-13-36
«МИРОВЕТ» ҖЧҖнең ТР һәм БРдагы вәкиле – Рәсүл Саттаров, тел.: 8-937-488-80-50

Фотолар «Мировет» компаниясеннән алынды. Реклама.

Мәңгелек кыйммәтләр

Мәңгелек кыйммәтләр / Акыллы гамәлләр / Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Удмурт татарлары «Касыймовлар җыенын» **НИЧЕК** оештырган

Семён Игнатьев татарлар өчен **НӘРСӘ** эшләгән

Ярманы **КАЙСЫ** авылда ярдыралар

Безнең киштәдә **НИЛӘР** бар

ТАТАРДӨНЬЯСЫ

КИСТЕМГӘ, ТӘБИКМӘК БЕЛӘН СЫЙЛАНЫРГА

Фото: Олеся Бондаревская, www.balezino.udmurt.ru

Автор:
Олеся Бондаревская

Удмуртиянең Балезино районы татарларына, башка милләттәшләре белән күрешер өчен, дистәләрчә, кайвакыт исә йөзләрчә чакрым ара үтәргә кирәк. Бер яктан караганда, бу күңелне төшерә. Икенче яктан караганда исә – сөенергә сәбәп булып тора. Ни өчен дисезме?

Авылда «Касыймовлар җыены» фестивале шушы тарихи реконструкция белән ачыла. Кистемнең барлыкка килү тарихын кунаклар хәтерендә шул рәвешле яңарткач, артистлар күңел ачу өлешенә күчә. Кистемнән һәм күрше авыллардан килгән коллективлар сәхнәгә бер-бер артлы чыга тора. Биредә катнашыр өчен, ансамбльләр могҗиза тудыра: Биктеш авылында нибары 9 кеше яши, ә чыгыш ясарга 11 кеше килә...

Кистемдә «Касыймовлар җыены» тәүге тапкыр 2017 елда грант һәм иганәчеләр акчасына оештырыла. 2018 елда күрше Падера авылында үткәрелә. 800 кунак җыела! 2019 елда исә Биктеш авылының 200 еллыгын бәйрәм итәләр. 2020 елда пандемия бөтен планны боза. Санитария-эпидемиология вазгыятенең туганнар белән очраштырырлык дәрәҗәгә җитеп җайлануын Кистем халкы түземсезләнеп көтә. Фестивальнең берничә йөз кунагының бөтенесе диярлек – Касыймовлар.

ГАСЫР ОЗЫНЛЫГЫНДАГЫ СӘЯХӘТ

– Касыймовларның бабалары, башка ырулар белән бергә, Арча биләренә караган. XV гасырда әлеге нәсел Нократ (Вятка) елгасы ярындагы Нократ (русчасы – Карино) бистәсенә нигез салган, ул билек үзәгенә әйләнгән. Касыйм би нәселе шуннан бирегә, Балезино районы территориясенә күченгән. Касыймовлар элгәрләренең килеп чыгышы хакында төрле фаразлар бар. Нократ биләренең борынгы бабалары Алтын Урданың идарәче катламнарыннан берсенең вәкилләре, дип санала. Әмма минемчә, алар Кырымнан килгән, – ди Илмир Касыймов.

1 Авылда «Касыймовлар җыены» фестивале шушы тарихи реконструкция белән ачыла. Кистемнең барлыкка килү тарихын кунаклар хәтерендә шул рәвешле яңарткач, артистлар күңел ачу өлешенә күчә.

Сәхнәдә – кырыс, мәгърур кыяфәтле ир-ат. Алтын ука белән чигелгән камзул, кырыена җәнлек мехы тотылган бүрек кигән. Ул бер яшь егеткә бик нәфис бизәлгән кечкенә тартма бүләк итә.

– Байҗан, син минем бердәнбер варисым. Менә патшаның бу җирләргә безнең хокукыбызны раслый торган фәрманы. Кайчан да булса Касыймовлар нәселе язмышы синең кулга күчәчәк һәм синең варисларың бу җирләрдә үз авылларына нигез салачак.

Илмир – Кистем урта мәктәбе педагогы, Удмуртиянең төньяк районнары мөхтәсибе, туган якны өйрәнүче һәвәскәр. Без аның истәлекле урыннар буйлап экскурсия үткәрүен үтендек.

Туристларны каршы алган кунак йортында Илмир Касыймовларның генеалогик картасын күрсәтә, Кистем халкының яртысыннан артыгы шул нәселгә барып тоташа. Уналты буынны ачыклаган бай шәҗәрәдә беренче булып Гази Мансур тора. Ул XV гасырда яшәгән һәм күп сәяхәт иткән. Гази Мансур – Касыйм нәселе (Чүпче елгасы ярындагы берничә татар ыруыннан берсенең) элгәре.

– Минем фаразлавымча, бу – Кырым кыпчаклары варислары нәселе. Нәкъ менә Кырымда мин Гаяз Мансур бинең каберен таптым. Кырымнан күченү процессы Чүпчедә яшәгән башка ыру – Карабәкләр шәҗәрәсендә тасвирлана. Алар Карачай-Чиркәс аша күченгән. Һәм анда чыннан да Карабәк үткеле бар. Кырымда исә Карабәк җәйләвен таптым. Ыру аннары хәзерге Оренбург өлкәсе территориясе, башкорт далалары, аннан соң Удмуртия җирләре буйлап күченеп йөргән – һәм үзеннән соң географик атамалар калдырган. Удмуртиядә Камбарка авылы бар, Камбар исә – Карабәкнең атасының исеме, – дип сөйли Илмир. Ул үзенең ДНКсын тикшертү дә шулай ук кырымтатарлар белән кардәшлеген күрсәтәчәк, дип саный.

КҮЧТӘНӘЧКӘ – ҖЫР

– Бу тәбикмәк (табада пешкән икмәк) дип атала, – ди Люция Касыймова, мичтән тәмле ризыкны тартып чыгара-чыгара. Люция аларны эретелгән атланмайга манып ала. Безнең кунакчыл хуҗабикәләребез әлеге майлауны рецептның бердәнбер сере, дип ышандырмакчы була, тик тәбикмәкнең искиткеч тәме тагын нинди дер яшерен хикмәтләр булуында шик калдырмый.

Люция Кистем мәдәният йортында методист булып эшли, һәм аның коллективы белән бергә туристларны каршылауда катнаша (ковидка кадәрге чорда Кистемгә елына 500–800 кеше килә торган була. Хәзергә исә районның бюджет оешмаларында гаммәви чаралар үткәрү рөхсәт ителми). Ул безне салмалы аш – Кистемдә токмачлы ашны шулай атыйлар – һәм биредә генә җырлана торган җыр белән сыйлый:

Иретәнеторыдымыиретәләдип
/ Иртән тордым иртәләр дип,
Иретәнеаязаныәетәләрдипешул
/ Иртән азан әйтәләр дип шул,
Аязаныәетәләр, мине җыелыемын
/Азан әйтәләр, мин җылыймын
Баяшымычитекәләкитәдипешул
/ Башым читкә китә дип шул.
Әнекиеаяшыңыпеешепеҗитекәче
/ Әнкәй, ашың пешеп җиткәнче,
Баялаялаярыңыҗыелырышул
/ Балаларың җыелыр шул.
Барысыебуюлыпы мине булымаягачы
/ Барысы булып мин булмагач,
Куюзеңединеяшеңкыелырышул
/ Күзеңдин яшең коелыр шул.

Бу җан әрнеткеч җырны Кистемдә рекрутларны озатканда җырлаганнар. Аны тулысынча тыңлау бик озакка сузылыр иде – табында утырганда җырланган җырга һәркем үз гаиләсендә башкарылган куплетны өсти барган. Татарча текстта артык сузыклар бар. Илмир фаразлавынча, бу аның юлда да җырлануында. Печәнгә барганда да, станциягә барганда да җырлаганнар, кайвакыт тәгәрмәчләр ташка барып бәрелгән...

Табында җырлау традициясе Кистемдә әле 1990 нчы елларда да сакланган. Хәзер аларны Кистем үзәк авыл Мәдәният йорты үзешчәннәре генә башкара. Ансамбль

2
Безнең кунакчыл хуҗабикәләребез әлеге майлауны рецептның бердәнбер сере, дип ышандырмакчы була, тик тәбикмәкнең искиткеч тәме тагын нинди дер яшерен хикмәтләр булуында шик калдырмый.

3
Илмир – Кистем урта мәктәбе педагогы, Удмуртиянең төньяк районнары мөхтәсибе, туган якны өйрәнүче һәвәскәр.

репертуарында чын раритет та бар. Аның сүзләре Касыймовларның борынгы бабалары күченеп йөргән вакытлардан ук калган:

«Утырдым көймәләр түренә/Карадым ла ич суларның йөзенә/Суларның йөзендә һич кара юк/Алла язганын эшләми чара юк».

ТЕЛИ БЕЛЕП ТЕЛӘСӘҢ...

Язмыш хәерхаһлыгына ирешү өчен нишләргә кирәклеге хакында җирле риваять тә бар биредә. Ул мәчет төзелеше белән бәйле. 1903 елның җәе Кистемдә бик эссе, җилле була. Янгын чыгып, 130 дан артык йортны һәм агач мәчетне көлгә калдыра. Бу көннәрдә Кистем сәүдәгәре Госман Касыймов хаждан өенә кайтып бара торган була. Юлда танышы очрап, аңа авылдагы янгын турында сөйли. «Йә Рәхимле Аллаһ, әгәр минем йортым һәм гаиләм янгыннан сакланып калса, вәгъдә итәм: булган бөтен акчама яңа мәчет салачакмын!» – дип ялварып дога кыла Госман. Көчле җил утны нәкъ аның йорты һәм кибете ягына таба куа, тик ут каба дигәндә генә, җилнең юнәлеше үзгәрә дә, ялкын икенче якка китә. Госман әйткән сүзендә тора һәм мәчет төзетә. «Ә миңа һәм балаларыбызга нәрсә калдырасың?» – дип сорый үзеннән күпкә яшьрәк хатыны. «Аллаһ Тәгалә шәфәгатен һәм халык рәхмәтен», – ди Госман. Кистем бай авыл була, 1920–1930 нчы еллардагы кулакка чыгарып сөрүләр һәм репрессияләр күп гаиләгә афәт китерә. Әмма Госманның уттан сакланып калган өендә яшәгән балалары Аллаһ рәхмәте белән зыян күрми. Аның акчасына төзелгән мәчет бигрәк тә үзенчәлекле. Бу – 1829 елда император Александр I раслаган «Үрнәк проект» буенча салынган Россиядә бердәнбер сакланып калган мәчет. Янган мәчет тә, аннан алдагысы да шундый ук проект буенча төзелгән булган. Сигез почмаклы формадагы агач бина уңайсыз булып чыккан, һәм аннан соң мәчетләрне башка проектлар буенча салганнар. Ә менә Госман мәчете инде бер гасырдан артык халыкка хезмәт итә. Шул дәвердә аны бер тапкыр кына япканнар. Күптән түгел аның тузган манарасын сүтәргә туры килгән. Аны түбәгә беркетеп торган 1 метрлы кадаклар мәчеттә саклана – бина тарихына мөнәсәбәтле предметлардан Илмир музей экспозициясе кебек нәрсә оештырган. Хәзер бинада ремонт бара, намаз залын җылыта торган мичләр яңадан чыгарыла. Янәшәсендә мәхәллә халкы акчасына салынган яңа таш мәчет тора. Иске мәчеттә ремонт тәмамлангач, анда ирләр гает намазларын укыячак, яңасында хатын-кызлар гыйбадәт кылачак. Калган вакытта иске мәчет музей кебек эшләячәк. Гает бәйрәмнәрендә Кистемдәге ике мәчеттә 150 дән артык кеше намаз укый.



4
Бу – 1829 елда император Александр I раслаган «Үрнәк проект» буенча салынган Россиядә бердәнбер сакланып калган мәчет.

5
Янәшәсендә мәхәллә халкы акчасына салынган яңа таш мәчет тора.

6
Мәчеттә шәмаилләр коллекциясе саклана.

Кистем – Удмуртия Республикасының Балезино районында Чүпче елгасына коя торган Кистем елгасы ярындагы авыл. Анда барлыгы 850 ләп кеше яши, нигездә – чүпче татарлары.

7 8
Илмир Касыймов мөмкинлек булган бөтен җирдә музей оештырадыр кебек тоела. Мәктәптә, мәсәлән, этнографиягә һәм төбәкне өйрәнүгә багышланган ике музей залы урнашкан. Этнография залында Кистем көнкүрешенә кагылышлы предметлар тупланган. Кайберләренә инде гасырдан артык икән.

БЕЗНЕ БЕРЛӘШТЕРГӘН КОМЕТА

Илмир Касыймов мөмкинлек булган бөтен җирдә музей оештырадыр кебек тоела. Мәктәптә, мәсәлән, этнографиягә һәм төбәкне өйрәнүгә багышланган ике музей залы урнашкан. Этнография залында Кистем көнкүрешенә кагылышлы предметлар тупланган. Кайберләренә инде гасырдан артык икән.

– Мин татар тарихи киемен реконструкцияләү белән мавыгып киттем. Авылдашларым XX гасыр башына караган берничә кием китерде, үземдә дә кайбер әйберләр бар иде. Мин боларның барысын да тәфсилләп өйрәнергә һәм шундый ук киемнәр тегәргә ниятлим. Татар, удмурт милли киемнәрен өйрәнәм. Тегү машинасында төрле җөйләр ясарга өйрәндем, фасон, кием кисү нечкәлекләренә төшендем, – ди Илмир. – Миңа әле хәситә белән эшләү дә бик ошый. Кием кебек үк, бу да шифр, аның буенча моннан бер гасыр элек һәм аннан да элгәрерәк яшәгән хатын-кызның яшен, социаль катламын, статусын белеп була.

Төбәкне өйрәнү музее витриналарында исә авылның һәм анда яшәүчеләрнең бик күп тарихи фотолары, шулай ук аларның тарихы урын алган. 1930–1970 нче елларда Ибраһим Әхмәрев (аның этисе Касыймов фамилиясен Әхмәревкә алыштырган) мәктәптә төгәл фәннәр укыткан. Ул йолдызларны бик яраткан һәм күк картасын яхшы белгән. Бервакыт Әхмәрев, кичен клубта лекция укыганнан соң өенә кайтканда, гадәттәгечә күк йөзе белән хозурланырга булган һәм анда элек күзәтелмәгән койрыклы йолдызны күреп алган. Икенче көнне дәресләрдән соң район үзәге Балезинога йөгергән һәм Пулково обсерваториясенә телеграмма җибәргән. Анда ак төннәр булганга, кометаны тапмаганнар. Координаталарын җибәрүне сораганнар. Әхмәрев, почмакларны үзенең биш бармагы ярдәмендә үлчәп, аларны исәпләп чыгарган. Координаталарны Тын океан обсерваториясенә җибәргәннәр. Аның кометаның урынын бер градуска кадәр төгәллек белән исәпләп чыгаруы ачыкланган. Шул ук вакытта Удмуртиянең Воткинск бистәсендәге метеостанция җитәкчесе Семён Юрловтан һәм бераз соңрак норвегияле галим Олаф Хассельдән дә шундый ук телеграмма алганнар. Кометаны алар исеме белән атаганнар. Беләсегез килсә, һәвәскәрләр нибары җиде комета ачкан, шуларның өчесе генә – визуаль рәвештә. Әхмәрев-Юрлов-Хассель кометасы 7 мең елга бер тапкыр бер әйләнеш ясый һәм хәзер Кояш системасыннан читтә урнашкан.

Кистемнән байтак атаклы кеше чыккан. Мәсәлән, Казанда бертуган Касыймовлар урамы бар, алар – Ибраһим Әхмәревнең туганнан туганнары. Казан һәм Кистемнең уртак нәрсәләре шактый, әмма аерымлыклары да бар.

КҮРШЕЛӘР ХӘТЕРЕ

– Без татар теленең нократ диалектында, аның борынгы версиясендә сөйләшәбез. Авазларны әйтүдә үзенчәлекләр бар. Мәсәлән, «и» авазлары «э»ләшә. Лексик үзенчәлекләр дә шактый. Безгә төрек теле бик якын. Татарстандагы татар теле исә гасырлар буе гел үзгәргән. Без аны әдәби тел дип атыйбыз һәм күпчелек аны яхшылап белми, – ди Кистем урта мәктәбе директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары Зөһрә Касыймова.

Хәзер мәктәптә 80 бала укый, аларның 61 проценты татар булганга, ул милли санала. Биредә шулай ук удмурт, рус, чегән балалары да укый.

9

Ата-аналары ризалык бирсә, алар да, татар балалары кебек, 9 сыйныфка кадәр татар телен һәм әдәбиятын, 11 сыйныфка кадәр татар әдәбиятын өйрәнә ала. Тел өйрәнү стимулларыннан берсе – иҗат. Шунлыктан мәктәптә ел саен «Илһам» нәфис сүз осталары конкурсы, Татар театры көне һәм Татар теле көне уздырыла. Илмир Касыймов үткәрә торган төбәкне өйрәнү дәресләрендә укучылар тикшеренергә, аралашырга, үзләре яшәгән урын һәм янәшәләрендәге кешеләр белән танышырга өйрәнә. Мәсәлән, былтыр тикшеренү эшләре 1930 нчы еллардагы репрессияләргә багышланган булган.

Күп очракта педагоглары тырышлыгы нәтиҗәсендә Кистем укучылары тел буенча төбәк һәм халыкара конкурсларда даими җиңә.

– Баланың кызыксынуын һәм игътибарын яулау өчен зур хезмәт куярга туры килә. Без һәрвакыт нинди дә булса яңалык уйлап табарга тырышабыз. Былтыр Туган тел көнен квест рәвешендә үткәрдек. Хәзер яңа проект әзерлибез: мәктәптә кабул ителгән «Тәрбия» программасы буенча тел өйрәнүгә ата-аналарны җәлеп итәргә ниятлибез. Әлегә бу идеяләр генә, әмма без конкурс форматыннан файдаланырга һәм ел ахырында иң актив гаиләләрне бүләкләргә җыенабыз, – ди Зөһрә Касыймова. – Без традицион этномәдәни берәмлек. Әмма без балаларыбызның алдынгы, заманча, техник җиһазландырылган шәһәр мәктәпләрендәге кебек мөмкинлекләре булуын бик телибез. Әлегә кайбер параметрлар буенча без алар белән тиңләшә алмыйбыз. Без Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы грантына даими рәвештә гаризалар бирәбез һәм кайчан да булса аны отарга өметләнәбез. Моннан тыш, без Татарстандагы «Адымнар» кебек белем бирү оешмалары тәҗрибәсен уртаклашуны планлаштырабыз.

Кистемдә тормыш кайнап тора. Бер гасыр элек ачылган клубта номерлар уйлап табыла, татар драматурглары пьесалары буенча спектакльләр куела, аларда өлкәннәр белән бергә үсмерләр һәм балалар да катнаша. Авыл мәгарифе тарихы моннан 300 ел элек башланган – Кистемгә махсус уку-язуга өйрәтү өчен мулла килгән. Бүгенге мәктәптә исә укытучылар һәм укучылар бергәләп заманча дөньяны өйрәнә һәм анда мәдәни мираска да урын таба. Күптән инде бер гасырлык юбилеен билгеләп үткән мәчет үзенең тышкы кыяфәтен һәм рухи эчтәлеген саклап калган. Бик тиздән ул кабат үзенең ишекләрен ачачак. Кистем традицияләре мәгърур агачлар үскән бакчаны хәтерләтә. Шул агачлар ышыгында әлеге бакчаны яратучы кешеләр яши. Т

9 Авыл әбиләре әйтүенчә, XIX–XX гасыр күлмәкләрендәге идәнгә параллель өстәмә балитәкләр әлеге итәкнең теләсә нинди фигуралы кешедә дә бертигез күренүе өчен кирәк булган. Әгәр балитәк артта икән, димәк, күлмәк – яшь кызларныкы, алда икән – өлкән яшьтәге хатын-кызныкы.

СҮЗ УҢАЕННАН:

Кистемдә кунак чакырганда һәрвакыт тәбикмәк пешерәләр, чөнки бу әбибабайларның яраткан сые. Әгәр өстәлдә тәбикмәк күренми икән, хуҗабикәгә бу турыда шыпырт кына искәртәләр. Ә тәбикмәкне чыннан да еш кына табынга куярга оныталар икән, чөнки кунаклар килгәнче аны җылы мич башында каплап тоталар.

Касыймов фамилиясе XVI гасырда пәйда булган һәм шул вакыттан бирле буыннан буынга тапшырыла.

Кистемгә генә хас тагын бер затлы нигъмәт – табада кыздырылмый, ә мичтә пешерелә торган кош теле. Биредә казны да бөтен килеш какламыйлар, түшкәне бүлгәләп, банкада тозлыйлар да, язын әлеге кисәкләрне телемнәргә турап, чормага элеп киптерәләр.

PRESSA

Нияз Әхмәдуллин – «Татарстан» журналы баш мөхәррире урынбасары. Күптән түгел генә YouTube каналында аның күренекле татарстанлыларның тормышына кагылышлы билгесез фактларны яктыртуга багышланган авторлык программасы пәйда булды. Әлеге тарихлар хәтта «Миллиард татар» сайтын да кызыксындырды. Бүген Нияз Әхмәдуллинның «миллиард татары» «Татарстан» журналында урын ала.

НИЯЗ ӘХМӘДУЛЛИННЫҢ МИЛЛИАРД ТАТАРЫ

Автор:
Нияз Әхмәдуллин

СЕМЁН ИГНАТЬЕВ. СОҢГЫ МИНИСТР, БЕРЕНЧЕ СЕКРЕТАРЬ...

СССР дәүләт иминлеге министры – Семён Денисович Игнатьев карьерасының иң югары баскычы. Партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре – аның хезмәт дәфтәрендәге соңгы вазыйфа. 1957 елда Игнатьев җитәкли башлаган Татарстанда аны ихластан хөрмәт иткәннәр һәм яратканнар. Ул Татарстандагы татарларның күпчелегеннән турылыклырак «татар» булып чыккан.

«ЭШЛӘПӘДӘ» ИКӘН ЭШ

Семён Игнатьев хакында төрле имеш-мимеш йөргән. Кайсы сүзне дошманнары тараткан, кайберләре исә чынлап та хак булган. Мәсәлән, үзе әйтүенчә, 1953 елның язында, эшеннән алынгач, ул пистолетын мендәр астына тыгып йоклаган. Көн дә үзен кулга алуларын көткән һәм, Лубянкадагы хәлләрне яхшы белгәнгә, тере килеш бирелмәскә ниятләгән.

Татарстанда исә партия түрәләре мондый хәлгә шаһит булган. Республикага өлкә комитеты беренче секретаре итеп билгеләнгәч үк диярлек, Игнатьев кибеткә кергән. Макарон үлчәп бирүләрен үтенгән. Кибетче исә: «Макаронын үлчәрмен үзе, тик аны төреп бирергә кәгазь юк шул», – дигән. «Кая салыйм соң мин аны?» – дип аптырашта калган Игнатьев. «Эшләпәгезгә салсак кына инде», – дип тәкъдим иткән кибетче. Берничә сәгатьтән соң макарон тутырылган эшләпә республика хөкүмәте хезмәткәрләре каршында кукраеп утырган. Шушы хәлдән соң, кибетләрдә төрү кәгазе бик тиз пәйда булган, диләр.

ИХТЫЯРСЫЗДАН ЧЕКИСТ

Семён Игнатьев Сталинның соңгы дәүләт иминлеге министры булган (әлеге вазыйфаны 1951 елдан 1953 елга кадәр биләгән). Һәм, җитәкче урында эшләсә дә, гомерен дә саклап калган, дәүләт карьерасын да дәвам иткән бик аз чекистлардан берсе ул. ҮК утырышында Хрущёв, Игнатьевның холкы бик йомшак булу аңа ДИМ җитәкчесе вазыйфасыннан баш тартырга комачаулаган, дип белдергән. Никита Сергеевич, әлбәттә инде, эшнең нәрсәдә икәнен бик яхшы

Никита Хрущёв һәм Семён Игнатьев.

белгән – Игнатьев Сталин тәкъдименә берничек тә ризалашмый кала алмаган. Әмма министр булган чагында әллә ни зыян китерергә өлгермәгән.

МАЛЕНКОВ ХИМАЯСЕНДӘ

Семённың балачагы һәм яшьлеге Үзбәкстанда үткән. Шунлыктан аңа үсмер чагыннан ук башка дин һәм мәдәният кешеләре белән уртак тел табарга өйрәнергә туры килгән. Игнатьев үзбәкчә камил сөйләшкән. Җирле халык үзен моның өчен хөрмәт иткән. Актив үсмер инде унбиш яшендә үк Бохара тимер юлы депосы комсоргы булган.

Аннары сәләтле егетне Бохара гаскәрләр төркеме сәяси бүлегенә алалар. Бу – аның карьерасының беренче мөһим этабы, чөнки, ихтимал, нәкъ менә шунда ул Төркестан гаскәрләр төркеменең яшь комиссары Георгий Маленков белән танышкандыр. Соңрак Маленков Сталинның яраннары даирәсенә керә һәм, югарырак дәрәҗәгә ирешкән саен, Игнатьевны да үзе белән бергә үстерә бара.

ЯШЬЛӘРГӘ ЮЛ АЧЫК...

1931 елда Игнатьев Үзбәкстан компартиясе ҮК юлламасы буенча Сталин исемендәге Сәнәгать академиясенә укырга керә, аны «самолёт төзүче инженер» белгечлеге буенча тәмамлый. Әмма белгечлеге буенча бер көн дә эшләми. Төркестанда танышкан Георгий Маленков, ул чакта инде партия ҮК җитәкче органнары бүлеге мөдире урынбасары, аның язмышын үзгәртә. Игнатьев, югары уку йортын тәмамлауга, Коммунистлар партиясе Үзәк комитетының сәнәгать бүлегенә эшкә чакырыла. Ул чакта аңа утыз гына тулып узган була.

Әлеге вакытта илдә репрессияләр башлана. Кулга алулардан соң кайбер учреждениеләр бөтенләй диярлек бушап кала. Яшьләр өчен «мөмкинлекләр тәрәзәсе» ачыла. Һәм Маленков канаты астындагы Игнатьев партия һәм җитәкчелек эшендә тиз арада зур тәҗрибә туплый. 1937 елда Бурят-Монгол партия өлкә комитеты беренче секретаре итеп билгеләнә (аның әлгәре Михей Ербанов кулга алына һәм 1938 елда атып үтерелә). 1943–1946 елларда партиянең Башкортостан өлкә комитеты беренче секретаре була.

Башкортостаннан соң, 1946 елда, кабат Мәскәүгә эшкә алына – партия ҮК кадрларын тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасары итеп куела. Әмма инде бер елдан соң ук, 1947 елда, аңа башкаладан китәргә туры килә. Игнатьевның химаячесе Георгий Маленков Сталин җәберенә дучар була. Игнатьевны да ил буенча куалый башлыйлар: Белоруссия компартиясе ҮК икенче секретаре, Үзәк комитетның Үзбәкстандагы вәкиле. Яңгыравыклы, әмма уртакул вазыйфалар. Эшләр 1950 елда – Маленков кабат Сталин яраннары даирәсенә әйләнеп кайткач кына җайлана: ул Игнатьевны Мәскәүгә кайтарта һәм Коммунистлар партиясе Үзәк комитетының партия, комсомол һәм профсоюз оешмалары бүлеге мөдире итеп куйдыруга булыша.

«ИГНАТЬЕВЧЫЛЫК»

Мәскәүдә исә ул елларда тыныч булмый. Сталин даирәсендәге ышерен көрәш үзенең кульминациясенә якынлаша. 1951 елның июль башында Берия дәүләт иминлеге министры Виктор Абакумовны эшеннән алдыртуга һәм төрмәгә яптыруга ирешә. Абакумов – Бериянең элекке химаячесе, тик соңрак ул аның куркыныч көндәшенә әйләнә.

Берия белән Маленков Абакумов урынына үзләре идарә итәрлек кешене куярга исәплиләр. Генерал-чекистлар арасында да теләүчеләр була. Әмма алар барысы да ялгыша. Юлбашчы үзенчә эшли: көтмәгәндә, бернинди хәрби чины һәм дәрәҗәсе булмаган Семён Игнатьев кандидатурасына туктала.

Сталин Игнатьевка әллә никадәр файдасыз-мәгънәсез боерыч куя: Абакумов һәм аның Дәүләт иминлеге министрлыгындагы эшнәләре эшен тикшерү; корткыч табибларны ачыклау һәм алар өстеннән суд процессын әзерләү; Лаврентий Бериягә җитди күңелсезлек белән янаган «мингреллар эше». Сталин кушуы буенча нәкъ менә Игнатьев күп еллар буе юлбашчы сакчылары җитәкчесе булган генерал Николай Власикны кулга ала. Бераз соңрак Сталинга каршы сүз әйтергә җөрьәт иткән Югославия лидеры Иосип Броз Титоны юк итү планын эшләү дә Игнатьевка йөкләнә...

Табиблар эшенә килгәндә, ул Сталинның иң авыр һәм мәшәкатьле күрсәтмәсе булып чыга. Эш 1952 ел дәвамында хәстәрләнә. Баштарак Игнатьев «корткыч табиблар» оешкан төркеме булуга берничек тә дәлилләр таба алмый. Сталин, аны кабинетына чакыртып: «Әгәр табиблар арасында террорчыларны, Америка агентларын тапмыйсыз икән, үзегез

дә Абакумов янында булачаксыз», – дип җикеренә һәм яный.

Моның ахыры ничек тәгәлләнгән булыр иде – билгесез, чөнки табиблар өстеннән суд процессы язга планлаштырыла, тик 1953 елның 5 мартында Сталин җан тәслим кыла. Шул ук көнне ҮК Президиумының тар составы үзенең соңрак уртак Пленум дип аталган утырышында Игнатьевны дәүләт иминлеге министры вазыйфасыннан азат итә, ҮК Президиумы әгъзалары сафыннан чыгара, ҮК секретаре итеп билгели. Дәүләт иминлеге министрлыгын Эчке эшләр министрлыгына кушалар, берләштерелгән идарәне Лаврентий Берия үзе җитәкли. Бер айдан, 1953 елның апрелендә, табиблар эше туктатыла.

Ә 1953 елның 5 апрелендә Игнатьевны ҮК секретаре вазыйфасыннан азат итәләр һәм ҮК әгъзалыгыннан чыгаралар. Газеталарда редакция мәкаләсе дөнья күрә, анда табибларга каршы ялган җинаять эшендә гаеплеләр арасында аның фамилиясе дә була. Экс-министр Игнатьев дәлилләрне законсыз җыюда, физик йогынты ясау ысулларын куллануда гаепләнә. Хәтта «игнатьевчылык» термины да пәйда була. Маленков ярдәменнән мәхрүм ителгән менә шул авыр чакта бөтен вазыйфалары тартып алынган Игнатьевка мендәр астына пистолет куеп йокларга туры килә дә инде. Лубянка подвалларында элекке чекистлар белән ни булганын Абакумов мисалында ул бик яхшы белә.

1953 елның июнендә Берияне кулга алалар, халык дошманы дип игълан итәләр һәм тиз арада атып үтерәләр. Игнатьевны исә 1953 елның июлендә партия Үзәк комитетына кире кайтаралар, әмма абруена инде шактый зыян килгән була. Аны кабат милли республикага – кабат партиянең Башкортостан өлкә комитетының беренче секретаре итеп җибәрәләр. Бу юлы Игнатьев анда өч ел ярым, Казанга җибәрелгәнче эшли.

БАШ «ТАТАР»

1957 елның 6 июнендә Семён Денисович Игнатьев партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре итеп сайлана. Казанда беренче эш көнендә үк Игнатьев барлык кабинетларны карап чыга, аннары киңәшмә җыя. Төп проблемаларны тикшерәләр. Очрашу азагында Игнатьев бөтенләй көтмәгәндә өлкә комитетындагы бардак турында сүз башлый. «Хуҗалык объектларын карап чыктым, – ди ул. – Бөтен җирдә быкырдык һәм тәртипсезлек. Кабинетларда тузан һәм чүп-чар, тәрәзәләр юылмаган, келәмнәр ертык, тәрәзә төпләрендә һәм өстәлләрдә кәгазь, китап һәм журналлар өелеп ята. Бәдрәфкә керерлек түгел. Гараж иске чүп-чар складына охшаган. Сез бу кадәр тәртипсезлектә ничек эшли аласыз? Партия оешмасы штабы чисталык һәм тәртип үрнәге булырга тиеш түгелмени?!»

Яңа коллегаларын шул рәвешле кыздырып алгач, Игнатьев инде җиң сызганып бөтен республика хуҗалыгын торгызуга керешә.

Тынычлык тарафдарларының Бөтендөнья конгрессы Даими комитетының атом-төш коралын тыю турындагы Стокгольм чакыруына имзалар җыю. Казан ш. 1950 ел.

Аның аппараттагы дәрәҗәсе һәм Үзәк комитеттагы, шулай ук СССР хөкүмәтендәге элемтәләре Татарстанда күп нәрсәгә ирешү мөмкинлеген бирә. Нәкъ менә аның тырышлыгы сәбәпле, Казанда совет нефть химиясе флагманнарыннан берсенә әйләнгән «Оргсинтез» заводы төзелә башлый. Нәкъ менә Игнатьев Түбән Камада нефть химиясе комплексы (хәзерге «Түбән Кама Нефтехим») төзелешенең максатка ярашлы булуында Мәскәүне ышандыра ала. Игнатьев Мәскәүдә дәүләт фондына тапшырыла торган ашлык күләмен киметү хакында килешүгә ирешә һәм моның белән республикадагы колхоз-совхозларның хәлен күпкә җиңеләйтә. Нәтиҗә буларак, Татарстанда азык-төлек белән тәэмин ителеш яхшыра. Казанда Ту-22 стратегик бомбардировщикларын, Ми вертолётларын сериялэп җитештерүнең башлануына да республика нәкъ менә Игнатьевка бурычлы. Бу чорда республика җитәкчелегенең нәкъ менә йогынтылы, абруйлы, инициативалы, тынгысыз, җаваплылыкны үз өстенә алудан курыкмаучы Игнатьев кулында булуы Татарстанга искиткеч файда китерә.

Тарихи факт – 1958 елда күренекле сәнгать һәм мәдәният әһелләренә тапшырылачак Габдулла Тукай исемендәге ТАССР Дәүләт премиясен булдыру турында татар җәмәгатьчелеге инициативасын нәкъ менә ул хуплый. Әмма, мөгаен, сәяси яктан Игнатьев өчен иң катлаулысы – аның татар телен, татар мәдәниятен саклау проблемалары белән ныгытып шөгыльләнергә карар кылуы булгандыр.

1920-1930 нчы еллардагы репрессияләрдән, тарих фәнен, иҗатны һәм әдәбиятны катгый чикләгән сәясәттән зур зыян күргән татар интеллигенциясе, Сталин вафатыннан соң батыраеп китеп, чынбарлыктагы проблемалар, беренче чиратта – татар теленең үлеп баруы хакында сүз башлый. 1954 елда бер төркем татар

Казан. Финанс-икътисад институты. 1950 ел.

галиме республиканы союздашлык статусына күтәрү зарурлыгы, шул исәптән татар теленең җуелып юкка чыгу куркынычы турында СССР Фәннәр академиясенә мөрәҗәгать юллый. Язучы Нурихан Фәттах бу турыда партия Үзәк комитетына яза, язучы Шәйхи Маннур Хрущёв исеменә үтә тәвәккәл мөрәҗәгать җибәрә. Бөтен җирдә татар теленең юкка чыгу куркынычы темасы күтәрелә. Иҗат берлекләре җыелышларында да эмоциональ чыгышлар яңгырый.

Чыннан да, 1950 нче еллар ахырына республикада татар телен куллану даирәсе искиткеч тарая. Тел мәктәпләрдән, югары уку йортларыннан, фәннән, киң файдалану даирәсеннән төшеп кала бара. Ата-аналар балаларын рус телле сыйныф һәм мәктәпләргә күчерә. Рус сыйныфларында татар балалары өчен татар теле атнасына ике тапкыр гына укытыла, бу телне өйрәнү өчен бик аз була. Татар теле һәм әдәбиятыннан элек өлгергәнлек аттестаты алу өчен мәҗбүри булган имтихан бетерелә. Туган телне өйрәнү өчен нинди мотивация турында сүз алып барып булсын ди хәзер! Нәтиҗәдә ана телен бөтенләй диярлек белмәүче буын үсә. 1950 нче еллар азагында республикада студентлар арасында татарлар нибары 28 процент тәшкил итә, аларның күбесе рус мәктәбен тәмамлаган була.

Эш шундый гайре табигый очракларга барып җитә ки, Татарстан өлкә комитеты татар авыллары һәм районнарында татар телендә лекция укырга сәләтле лекторларны таба алмый башлый. Милләтнең теле периферияга китә, көнкүрештә аралашуга гына кайтып кала, үсүдән туктый, үзенең байлыгын югалта, аны куллану даирәсе елдан-ел кими. Искиткеч бай әдәбият, халыкның тарихы, татар галимнәренең фәнни мирасы әкренләп онытыла һәм яшьләр өчен риваятьләр генә булып кала.

Игнатьев җиң сызганып татар теле проблемаларын хәл итәргә керешә. Ул татар телен шундый аяныч хәлгә китереп җиткерүдә өлкә комитеты җитәкчеләрен гаепли. Семён Денисович татарларга һәм татар мәдәниятенә бик ихтирамлы һәм хәерхаһлы мөнәсәбәттә була. Камил Фасиев язуынча, Игнатьев татар мәдәниятен гел мактый, татарларның Урта Азия, Казахстан һәм Башкортостан халыклары мәдәниятенә прогрессив йогынты ясавын гел искәртеп тора.

Игнатьев кушуы буенча нәкъ менә Фасиев укытучылар, галим-голәма һәм иҗат интеллигенциясе белән берничә киңәшмә оештыра. Игнатьев әлеге очрашуларда катнаша, мәдәният әһелләре белән рәхәтләнеп аралаша, үзенең киң белемле һәм эрудицияле булуы белән күпләрне гаҗәпкә калдыра.

Партия ҮК белән элемтәгә керәләр, вазгыятьне өйрәнер өчен Казанга аның комиссиясе килә. Мәскәү хуплавын алгач һәм барлык сорауларны килештергәч, партиянең Татарстан өлкә комитеты пленумын үткәрәләр.

Тарихка кереп калган бу пленум 1958 елның 21 маенда уздырыла һәм аеруча кайнар, эмоциональ һәм шул ук вакытта эшлекле җыеннардан берсе була. Камил Фасиев саллы, дәлилле чыгыш ясый. Менә аның төп нигезләмәләре: «Миллилекне хөрмәт итмичә, интернационализм була алмый. Үз телен һәм милли мәдәни традицияләрен яхшы белгән кеше башка халыклар теле һәм мәдәниятенең әһәмиятен дә яхшырак аңлый. Без татар мәктәпләрен рус мәктәпләренә каршы куймыйбыз, һәртөрле милли тарлыкны кире кагабыз».

Башка чыгыш ясаучылар арасыннан бигрәк тә халык язучысы Гомәр Бәширов сүзләре хәтергә уелган: «Мин ата-аналарның татар мәктәпләренә үпкәсен бик яхшы аңлыйм. Алар тикмәгә генә үпкәле түгел. Татар мәктәбе аларның өметләрен акламый. Мәгариф органнары түрәләре һәм совет, партия аппаратлары хезмәткәрләре, үзләренең салкын карашы, милли мәктәп ихтыяҗларына битараф мөнәсәбәте белән эшне шул хәлгә китереп җиткерде ки, мәктәпнең халык каршындагы абруе җуелды», – дип белдергән ул.

Партия Үзәк комитеты бүлек мөдире урынбасары Василий Дербинов чыгыш ясый. Ул Фасиевны тулысынча хуплый һәм, алай гына да түгел, телне шундый аянычлы хәлгә китереп җиткерүдә партиянең өлкә, шәһәр һәм район комитетлары гаепле, дип саный. «Бөтенесе милли мәктәпләрнең абруе җуела баруын күреп торган, – ди Дербинов. – Әмма хәлиткеч чаралар күрәсе урынга, җитәкчеләр үз балаларын рус мәктәпләренә күчергән».

Игнатьев үзе исә пленумны: «Иптәшләр, мин Казанга килгәнче үк милли мәктәпләрнең нинди әһәмияткә ия булуын яхшы күзаллый идем. Татарстандагы вазгыять белән танышкач исә, хәлнең бик аяныч булуын аңладым. Без татар мәктәпләре бетү куркынычы алдында торабыз», – дигән сүзләр белән йомгаклаган.

Фикер алышулардан соң пленумның резолюциясен кабул иткәннәр. Татар балалары татарча укырга, бер үк вакытта рус телен дә өйрәнергә тиеш, дип карар кылганнар. Барлык мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында рус һәм татар телләрен камил өйрәнү өчен тигез шартлар тудырылырга тиеш. Шул юнәлештә эшли дә башлаганнар.

Әмма башлаганнар гына шул... Пленумнан соң ел ярым вакыт үткәч, партия Үзәк комитетына Татарстан өлкә комитетының элеккеге беренче секретаре Зиннур Моратов шикаяте кергән. Ул өлкә комитетын милләтчеләрне узындыруда, сәяси сукырлыкта һәм башка гөнаһларда гаепләгән. Моратов шикаятен тикшерә башлаганнар. Әлеге эш белән партиянең баш идеологы, совет консервативлыгы символына әйләнгән Михаил Суслов шөгыльләнгән.

Тикшерү нәтиҗәләре Игнатьев өчен дә, татар теле язмышы өчен дә аянычлы булып чыккан. Үзәк комитет комиссиясе, Татарстан өлкә комитеты карары милли тарлыкка һәм йомылуга алып бара, дип тапкан. Янәсе, Татарстан өлкә комитеты үз балаларын рус мәктәпләренә укырга бирүче ата-аналарны хаксызга гаепләгән; җитәкчеләргә югары уку йортларында һәм рус телле мәктәпләрдә укучы татар балаларына татар теле һәм әдәбиятын өйрәтүне оештыруга кушып дөрес эшләмәгән һ.б.лар.

Игнатьев һәм Дербиновны партия уяулыгын югалтуда гаепләгәннәр. Моратов шикаятен һәм Үзәк комитетның милли мәктәпләр буенча карарларны гамәлдән чыгару тәкъдимен Татарстан өлкә комитеты бюросында тикшерергә туры килгән. Фасиев интернационализмнан читләшүдә гаепләү белән катгый килешмәвен белдергән. Элегрәк сүзгә катнашмаган Батыев исә хәзер, киресенчә, милли проблема артык күпертелде, татар мәктәпләрен көчләп диярлек саклап калу омтылышы булды, дип белдергән. Бюроның башка әгъзалары, шул исәптән Табиев дәшмәгән. Фасиевны бары тик авыл хуҗалыгы буенча секретарь Анатолий Скочилов (ул соңрак партиянең Ульяновск өлкә комитеты беренче секретаре булачак) кына яклап чыккан: «Сез нәрсә, иптәшләр, чигенергә җыенасызмы? – дип ачуланып сораган Скочилов. – Фасиевны бернәрсәдә дә гаепләргә ярамый. Аның докладын без бергәләп тикшердек һәм хупладык, анда бернинди милләтчелек тә юк. Мин рус кешесе, әмма татар балаларының үз туган телләрендә укуын телим, бу аларга рус телен өйрәнергә комачауламый. Минем русча сөйләшә белмәгән татарны күргәнем юк әле», – дигән ул.

Игнатьев, эшнең нәрсәдә икәнен аңлап, сөйләшүгә нокта куйган: «Бәлки әле безне милләтчелектә дә гаепләргә җыенасыздыр? Без бит барлык сорауларны ҮК бүлегендә һәм РСФСР Мәгариф министрлыгында килештердек. Әмма, күрәмсең, ашыкканбыздыр, кайдадыр ялгышканбыздыр. Пленум карарын гамәлдән чыгарырга туры килер», – дигән. Шулай эшләгәннәр дә. 1960 елның гыйнварында Игнатьевның татар эпопеясе шул рәвешле тәмамланган.

Республиканың аннан соңгы җитәкчеләре 1990 нчы еллар башына кадәр татар һәм рус телләрен өйрәнүдә акылга муафыйк балансны һаман таба алмаган. Тиздән Татарстанны җитәкләгән Фикрәт Табиев исә, казанышларыннан тыш, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирүне биш елга туктатуы, татар телен үстерү мәсьәләләренә салкын карашы белән дә тарихка кереп калды.

КАЙДА УЛ УРАМ?

Инде икенче тапкыр хакимият җәберенә юлыккан Семён Денисович Игнатьев Татарстан җитәкчесе вазыйфасында тагын бер елга якын – 1960 елның октябренә кадәр эшләгән әле. Эштән алуның рәсми сәбәбе сәламәтлеге какшау булса да, чын сәбәбе милли мәсьәләгә кагылышлы булу һәркемгә аңлашыла. Европаның нинди дә булса иленә илче булып китүдән баш тартып, Игнатьев 56 яшендә пенсиягә чыккан. 1983 елның ноябрь азагында Мәскәүдә вафат булган.

Ул республика белән әллә ни озак җитәкчелек итмәсә дә, үзеннән соң матур хатирәләр калдырган. Бәлки, шул якты истәлекне саклау өчен, Казанның бер урамына Игнатьев исемен бирергә кирәктер?

Язманың видеоварианты да бар

Автор: Руфия Фазылова

КУЛДАН КУЛГА ЙӨРГӘН ЯРМА ТАШЫ...

«Татарстан» журналы халкыбызның ата-бабадан килгән затлы һөнәрләрен, көнкүрештән төшеп калган шөгыльләрен барлауны дәвам итә. Иген уңышы җыелды. Илле-алтмыш ел элек хатын-кызлар: «Яңа уңыштан бодай бәлеше пешереп ашарга кирәк», – дип сөйләшерләр иде. Хәзер исә безгә бу сүз бөтенләй ят тоела. Тик әле шулай эшләүче кешеләр бар икән. Андый гаиләне Кама Тамагы районы Олы Салтык авылыннан эзләп таптык.

ҺӨНӘРЛЕ ХУР БУЛМАС

КЫЧЫТКАНЛЫ БАЛАЧАК

Зәйтүнә апа Миңнуллина ялгызы яши. Сиксән дүрт яшен тутырган. Авылның тере энциклопедиясе дисәм, арттыру булмас. Шуңа да аның янына еш кына авылның яше-карты җыела. Бу юлы да Зәйтүнә апаны Олы Салтыкның бер төркем хатын-кызы уратып алган иде. Алар өмәгә – ярма ташында бодай тарттырырга җыелды.

Зәйтүнә апа Олы Салтыкта туган, шунда гомер иткән. Ире белән кырык җиде ел яшәгәннәр, дүрт бала үстергәннәр. Ни кызганыч, шул зур гаиләдән бүген ана һәм ике ул гына исән.

– Сугыш башланганда, эти колхозда бригадир булып эшләгән, – дип балачак хатирәләре белән бүлеште Зәйтүнә апа. – Балалар күп, әни авыру булганга, этине башта сугышка алмаганнар, бронь белән калдырганнар. Эти, игеннәр өлгергәч, ач халыкка рөхсәтсез солы бүлеп биргән. Моны район җитәкчеләре ишеткән дә: «Йә сугышка, йә төрмәгә китәсең», – дигәннәр. Шулай итеп, 1942 елда эти, берсеннән-берсе кечкенә биш баласын калдырып, фронтка киткән. Бик авырлык белән көн күргәнбез. Әнинең хәлсез булып караватта ятканы әле дә күз алдымда.

Зәйтүнә апа әнисе үлгән чакны да яхшы хәтерли. Ул вакытта аңа сигез яшь була. Иң кечкенә энеләренә ике яшь тә тулмаган була. Ай буе хәлсез яткан ана кеше, кисәк кенә балаларын янына чакырып ала да:
«Балаларым, килегез, алдыма тезелегез.
Берәм-берәм карап тордым,
Үзәгемне өздегез...
Чыгып чана шуар идем,
Ишегалдым тау булса,
Балаларым ятим булмас,
Аталары сау булса», – дип, ул-кызларының берәм-берәм кулларыннан тота. Аннан күз яшьләрен сөртеп: «Әтиегез тиздән кайтыр, бер дә борчылмагыз. Бер-берегезгә ярдәм итегез, сез бертуганнар», – ди.

Сабыйлар, әллә бу сүзләрнең бәхилләшү икәнен аңлап, әллә әниләренең күз яшьләрен күреп, барысы бергә елап җибәрә. Ә иртәгәсен... ана инде күзләрен ачмый. Балалар бәхетенә, Олы Салтыкта әтиләренең сеңлесе яши, дәү әниләре исән була. Шуңа да аларны балалар йортына озатмыйлар.

Әниләре вафатыннан соң тугыз ай узгач, 1946 елның февралендә балаларның әтиләре Хәбибулла сугыштан кайта. Авыл кешеләре иркен сулап куя. Ул-бу булса, ничә бала ятим каласы бит...

– Әти сугыштан кайткач сөенгәннәребез, – дип дәвам итте Зәйтүнә апа. – Күңелләргә тынычлык иңде. Тик бу шатлык озакка бармады. Әтигә сеңелләре: «Өйлән, ялгызың гына бер оя баланы үстерә алмыйсың», – дип киңәш биргән.

Фото: Илнар Әмҗтбаев

һәм озакламый әти безгә яңа әни алып кайтты. Ул апа үзебезнең авылныкы иде. Хәтерлим, ул көнне оялудан, куркудан, без мич башына менеп качтык. Әти бу хәлгә уңайсызланды. «Балалар, төшегез инде, яңа әни белән танышыгыз», – дип, хәтта елап җибәрде. Мич башында исә без елашабыз... Кичкә генә, өйгә тәмле аш исе таралгач, мич башыннан төштек.

Балалар бәхетенә, үги әни кырыс булмый. Үзенең дә бер ир баласы була. Хәбибуллага килгәч, янә ике малай таба.

– Ул ике энем белән бик тату үстек, – диде Зәйтүнә апа. – Аллага шөкер, икесе дә исән. Берсе Олы Салтыкта яши, бүгенгәчә бик ярдәм итә. Әни балаларны аермады, иң мөһиме шул. Абый хәзер дә әйтә: «Әнигә сүз әйтерлегебез юк, нинди авыр заманнарда безне кеше итте», – ди. Көнгә өч тапкыр кычыткан ашы гына пешереп ашата иде ул. Кычыткан күргәч, хәзер дә шул ачлы-туклы балачагым искә төшә.

Кычыткан дигәннән, Зәйтүнә апалар әлеге үләнне яланкул җыйган. Капчык асып чыгып, урамнарны әйләнеп кайтканнар.

– Тәтә арттан: «Әбрәкәй өстеннән генә җыймагыз», дип кала иде, – ди Зәйтүнә апа.

– Ә ничек кычытканны яланкул тоттыгыз? – дим аптырап.

– Соң, бияләй юк ул вакытта, нишлисең?! Куллар ярылып беткән булгандыр, кычыткан чакканын хәтерләмим. Ә менә аяк ярылып, чебиләгәне яхшы истә. Ул әчетә, сызлый. Аны әни катык белән бәйләп, төреп куя иде. Менә шулай үстек, бәбкәм...

ӘНИ ТӨСЕ

Әнә шулай ярма ташын әйләндерә-әйләндерә, Зәйтүнә апа гомер йомгагын сүтте. Тормыш юлы бормалы, сикәлтәле булса да, әбекәй зарланмады. Язмышка буйсынып, шөкерана кылып яши ул.

– Бер улым гаиләсе белән Чаллыда, берсе Кама Тамагында гомер итә, – ди әбекәй. – Миңа эш эшләтмиләр инде хәзер, еш кайтып булышалар.

Барыбыз да ярма ташында бодай тарттырып карадык. Махсус уелып ясалган түгәрәгенә бодай саласың да түгәрәкне әйләндерәсең. Әллә ни катлаулы эш түгел икән. Кул арасына кергән бала-чага да эшли ала. Тик Зәйтүнә апа безнең белән килешмәде:

– Кешеләр берьюлы бер капчык бодай ярдыра иде. Ул бит көн дә эшли торган эш түгел. Ә ел буена әзерләп куела торган азык.

Әлеге ярма ташы Зәйтүнә апа өчен бик кадерле. Җитмеш биш ел элек алар йортына үги әнисе бирнә буларак алып килгән аны.

– Ул чагында яңа иде әле ул. Кулдан-кулга йөри-йөри шулай таушалды, – ди Зәйтүнә апа.

– Авылда ярма ташы бүтән кешедә юк идеме? – дим.

– Бәлки булгандыр да, тик яшертен генә бодай ярганнардыр. Ә бездә бар икәнлеген бөтен авыл белде, шуңа да безгә киләләр иде.

Бактың исә, ярма ташында бодайны качып кына тарттырганнар. Колхоз бригадирлары килеп, хәтта тәрәзәдән карап йөргән. Янәсе, бодайны каян алганнар.

– Андый чакта тәрәзәләрне каплап куя идек, – ди Зәйтүнә апа. – Һәм бер кеше ишек төбенә каравылга баса. Күбрәк ул эшне миңа тапшыралар иде. Урамда берәр ят тавыш ишетсәң, җәлт кенә өйгә кереп әйтәсең. Өлкәннәр тиз арада ярма ташын яшереп куя.

Соңыннан, кизү торган өчен, бодай ярдырган кеше Зәйтүнәгә бер стакан он калдырып китә торган була. Ул көн инде өйдә бәйрәм! Чүлмәктә ит шулпасында умач пешә.

– Үги әниебез умач ашын бик тәмле пешерә иде, – ди әбекәй.

Исеме ярма ташы булса да, ул агачтан ясалган. Фәкать тешләре таштан булган. Шуңа да ярма ташы дип аталган. Әлеге эш коралы 1970 нче елларда көнкүрештән төшеп калган. Ни өчен дигәндә, зур тегермәннәр кулланылышка кергән. Шулай ук кибет киштәләрендә он күренә башлаган.

Ләкин Олы Салтыкта әле Коръән ашларына күп еллар бодай бәлеше пешерү гадәте сакланган.

– Безнең энкәй елга бер булса да бодай бәлеше пешерә иде, – диде авылның Мәдәният йорты җитәкчесе Мәйсәрә Гомәрова. – Махсус бер стакан булса да бодай ярдырып ала иде.

Безгә дә әнә шундый бәлештән авыз итү насыйп булды. Мәйсәрә апага, туганнарына рәхмәт яусын! Ит салып пешерелгән бодай бәлеше үзенә бер төрле тәмле була икән. Сез дә пешереп карагыз әле. Ярма ташыгыз булмаса, ярдырылган бодай кибетләрдә сатыла...

ТАТАР ПАТРИОТЫ – ҺАДИ АТЛАСИ

Автор: Илдус Заһидуллин

Беренче рус инкыйлабы йогынтысында сәяси мәйданга чыккан яңа буын татар әйдаманнары, шәхси үрнәк һәм басма сүз белән халыкның иҗтимагый аңына тәэсир итеп, җәмгыятьне яңарыш юлына юнәлтә. Күпчелеге рухани гаиләсендә тәрбияләнгән татар интеллектуал элитасы вәкилләре яңарыш идеологиясе юнәлешләрен билгеле. Бу исемлектә Һади Атласи да бар.

«...МИЛЛӘТЕМ ӨЧЕН КИТӘМ»

Әхмәтһади Мифтахетдин улы Атласи 1875 елның 15 августында Сембер губернасы Буа өязенең (хәзерге Чүпрәле районы) җиде буын бабалары мулла булган Түбән Чөке авылы рухание гаиләсендә дүртенче бала булып дөньяга килә. Беренче мәхәлләдәге әтисенең башлангыч мәктәбен тәмамлагач, Буа шәһәре мәдрәсәсендә дин гыйлемен, гарәп, фарсы һәм төрек телләрен үзләштерә, дөньяви фәннәр белән кызыксына, рус телен өйрәнә. Оренбург губернасы Каргалы бистәсендә оештырылган татар мөгаллимнәрен әзерләүче өч еллык курсларда укый. Яшь кешенең фикер сөрешендә кискен борылыш, милләткә хезмәт итү идеясе шул вакытта, укытучысы Фатих Кәрими белән сөйләшү-аралашу йогынтысында туа. Курсларда ул алман телен һәм әдәбиятын ныклап өйрәнә, Гаяз Исхакый белән таныша.

1898 елда туган ягына кайтып, егет Буа мәдрәсәсендә укыта башлый. Уку планнарын яңача кора, үзе язганча, 1899 елдан җәмәгатьчелек фронтында эшкә кушыла. Дәреслекләргә кытлыкны хәл итү максатында, 1902 елда Казанда «Гыйльме һәйәт» («Астрономия фәне») һәм «Тарихе табигый» («Табигать фәне тарихы») исемле уку әсбаплары әзерләп бастыра.

Ул 1903 елдан Самара губернасы Бөгелмә өязе Әлмәт авылында икенче мулла вазыйфасын башкара. Биредә, каршылыклар һәм кыенлыклар булуга да карамастан, җәдитчә мөгаллимлек эшен киң җәелдереп, зур уңышларга ирешә. Түбән Чыршылы авылы мулласы Габделфәттах кызы Хөсникамалга өйләнгәннән соң, Әлмәттә кызлар мәктәбе дә оештыралар.

Илдәге торгынлык атмосферасы революцион рухлы Һадида зур ризасызлык уята. Ул бу еллардагы рухи халәтен «ут эчендә калган күгәрчен кебек төрле якка чапмак идем» дип сурәтли һәм беренче рус инкыйлабы алып килгән үзгәрешләрне зур күтәренкелек белән каршы ала.

Бу елларда җәдитчеләр һәм кадимчеләр арасында милли мәгарифнең киләчәге турында бәхәсләр куера. Бер үк вакытта хөкүмәт дөньяви милли мәктәпкә үз таләпләрен куя һәм аның өстеннән күзәтүне көчәйтергә тели. Бу максат 1906 елның 31 март «Кагыйдәләрендә» чагылыш таба. Шушы рәсми документ турында Һади Атласи 1906 елда «Яңа низам вә голәмәләребез» исемле брошюра яза. Автор, бер яктан, татар мәктәбенә рус хәрефләрен кертүне хөкүмәтнең милләтне урыслаштыру буенча тәүге зур адымы дип бәяли, икенче яктан, мөселман руханиларына: «Сез ник каршы чыкмыйсыз?» – дип мөрәҗәгать итә. Бу хезмәт, басылып берничә көн узуга, полиция тарафыннан конфискацияләнә. 1909 елда Атласи мәхкәмә җаваплылыгына тартыла, өч айга төрмәгә ябыла, рухани вазыйфасыннан куыла.

Фотолар автордан алынды

Кулга алынган Һади өеннән киткәндә әнкәсенә: «Әнием, елама, мин милләтем өчен китәм...», – дигән сүзләр әйтә. Атласи, үзлегеннән белемен күтәрү белән шөгыльләнеп, 1911–1912 елларда француз телен ныклап өйрәнә. Максаты Сорбонна университетына укырга китү була. Ләкин алдан сөйләшенгән хәйрияче-меценатлар акча бирмәгәч, хыялы тормышка ашмый.

Татар кызларын җәдит мәктәпләренә җәлеп итәр өчен Атласи Әлмәттә кыз балалар укытучы мөгаллимәләр әзерләү курслары ачып җибәрә, үз хисабына бер өйне арендага ала. Казаннан укытучылар чакырып, Бөгелмә өязендә бу өлкәдә зур хезмәт куя.

СОЦИАЛИСТ-РЕВОЛЮЦИОНЕР МУЛЛАНЫҢ СӘЯСИ КАРАШЛАРЫ

Беренче рус инкыйлабы һәм илдәге иҗтимагый-демократик хәрәкәт Атласины олы сәясәткә алып керә. Ул 1906 елның августында Түбән Новгородта үткән 3 нче Бөтенроссия мөселманнары съездында катнаша. Бу съездда «Иттифак әл-мөслимин» партиясенең программасы һәм уставы кабул ителә.

Активлык күрсәтеп, Һади Атласи Самара губернасы крестьяннар карьясе буенча II чакырылыш Дәүләт Думасына сайлана. Бу Думага үткән мөселман депутатларының саны 37 кеше була. Алар тәүге тапкыр Мөселман фракциясен оештыралар. Ләкин озак та үтми, 1907 елның мартында, мөселман либералларының программалары эшче халыкның мәнфәгатьләрен тиешенчә якламый дип, аның составыннан алты кеше (шул исәптән өч мулла) эсерлар яклы Мөселман хезмәт (трудовиклар) фракциясенә аерылып чыга.

Гаяз Исхакый Казаннан аларга ярдәмгә «Таңчылар»дан Фуад Туктаровны җибәрә. Төркем Туктаров җитәкчелегендә «Дума» исемле атналык газета чыгара башлый. Максатлары – мөселманнар арасында социалистик идеяләрне пропагандалау. Газетаның алты саны гына чыгып кала. Николай II 1907 елның 7 июнендә Икенче Думаны, 3,5 ай эшләгәннән соң, куып тарата.

Эсерларның программасы ил гражданнарына сәяси һәм демократик ирек биреп, гомумхалык милке дип игълан ителгән җирне игенчеләргә тигезләп өләшеп, төбәкләргә киң автономия биреп, алар белән бергә федератив тәртипкә нигезләнгән республика корып, социализм төзүне күз уңында тота. Атласи 1906–1918 елларда шушы социалист-революционерлар партиясендә әгъза булып тора, даими полиция күзәтүе астында яши.

Аңарчы ук чит ил матбугаты йогынтысында Атласи Россия мөселманнарын мәдәни яктан берләштерү идеясе белән яна башлый. Ул федератив республикада социализм төзү һәм төрки халыкларның берләшүе, ягъни пантюркизм концепцияләре бер-берсен тулыландыра дип уйлый. Һади пантюркизм идеяләре социализм мәнфәгатьләренә каршы килми, дигән фикергә килә.

Атласи илдәге төрки халыкларның сәяси үзбилгеләнү мәсьәләләренә багышланган I (Мәскәү, 1917 елның 1–11 май) һәм II (Казан, 1917 елның 21 июле–2 августы) Бөтенроссия мөселманнары съездларында катнаша. Соңгысында төрле мәсьәләләр буенча өч тапкыр чыгыш ясый. 1918 елда Уфада җыелган Милләт мәҗлесенә сайлана. «Милли үзбилгеләнү территориаль берәмлек яки милли-мәдәни автономия рәвешендәме?» дигән бәхәстә үзен милли-мәдәни автономия тарафдары итеп таныта.

Совет хакимияте урнашкач, Һади Атласи бердәм төрки-татар дәүләтен федератив башлангыч кысаларында Төркестанда, Башкортостанда, Татарстанда яшәүчеләр хисабына берләштерү мөмкин, дип фикерли. Советлар илендә төрки халыкларны берләштерәчәк уртак союздаш милли республика төзү турында хыяллана.

ЖУРНАЛИСТ ҺАДИ

Атласиның 1900 нче еллардан башланган Европа һәм рус әдәбияты белән кызыксынуы Дәүләт Думасыннан Әлмәткә кайткач, рус телен һәм Россия тарихын ныклап өйрәнә башлау ягына авыша. Гомумән, Һади мулла зур сәясәттән мәгариф өлкәсенә һәм тарихи эзләнүләргә кайта, үзлегеннән белем туплау белән максатчан шөгыльләнә башлый.

«Бәянел-хак», «Йолдыз», «әл-Ислах» (Казан), «Вакыт» (Оренбург) газеталары, «Шура» (Оренбург), «Аң» (Казан), «Мәктәп» (Казан) кебек журналлар белән хезмәттәшлек итә. Автор актуаль мәкаләләрендә укучыларга искиткеч күп, төрле статистик һәм тарихи мәгълүмат җиткерә. Аларда илнең үткәнен яхшы белүче һәм дәүләттә кабул ителгән кануннардан хәбәрдар шәхеснең төпле фикере яңгырый. Мәкаләләренең зур өлеше мәгариф һәм мәктәпне реформалаштыруга, Европа халыклары үрнәгендә белем алырга, яңа профессияләр үзләштерергә, баерга һәм татар милләте мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәргә өндәүгә багышлана. 1909 елдан башлап аның язмаларында тарихи темалар өстенлек ала. Аның борынгы башкортлар, борынгы угырлар, Хәзәр каһанлыгындагы Саркел шәһәре турында фәнни эчтәлекле мәкаләләре Оренбургта «Шура» журналында дөнья күрә.

«МИН ДӘ БУЛМАСАМ, КЕМ ЭШЛӘР?»

Яңарыш хәрәкәте, милли үзаң үсү җәмгыятьтә татар халкының тарихын белүгә зур ихтыяҗ тудыра. 1909-1910 елларда вакытлы матбугатта зыялылар арасында «Без кем: татармы, төрекме?» дигән бәхәс туа. Җавапны милли тарихта табарга була кебек, әмма XX гасыр башында татар җәмгыятендә тарихи хезмәтләр язучы кеше булмый. Һади Атласи,

1
Мөселман фракциясе депутатлары. Кулларында «Дума» газетасы. Сулдан өченче – Һади Атласи. 1907 ел.

2
Һади Атласи һәм Фатих Кәрими. 1909 ел.

үз алдына «Мин дә булмасам, кем эшләр?» дигән сорау куеп, олы хезмәткә – татар тарихын язу эшенә тотына. Шул рәвешле Атласи үзенең интеллектуал потенциалын милли борынгы тарихны язып, милләтнең тарихи хәтерен уяту, милли үзаңын формалаштыруга юнәлтә.

1911 елда дөнья күргән «Себер тарихы» китабына кереш сүздә автор болай дип яза: «Инсанны чын мәгънәсе илә инсан иткән гыйлемнәрнең беренчесе, һич шиксез, һич шөбһәсез, тарих гыйлемедер. Үзенең кем икәнен белмәгән инсан ни чаклы хиссез исә, үз милләтенең тарихын белмәгән инсан да шул нисбәттә хиссездер. Тарих гыйлемен,

инсанда милләт хисе уятучы гыйлемнәрнең бердәнбере булганлыгы сәбәпле, алдынгы милләтләр үз тарихларына фәүкылгадә (гадәттән тыш) әһәмият биргәннәр вә һаман бирмәктәләр. Безнең бабаларыбыз булган төрек-татарлар борынгы заманнарда иң атаклы халыклардан булдыклары сәбәпле, аларның тарихлары да иң парлак (бай, зур) тарихлар җөмләсендәдер». Атласи фикеренчә, дәүләтчелек тарихы булу һәм милли дәүләтчелек өчен көрәш халыкның көчен һәм рух ныклыгын билгеләгән иң мөһим күрсәткеч булып тора. Нәкъ шуңа күрә ул дөнья тарихында мөһим урын тоткан мәшһүр төрки бабаларының кылган эш-гамәлләренә, аларның дәүләтчелек тарихына мөрәҗәгать итә, шуларны күпмедер идеаллаштырып, романтик рух белән бәян итү эшен башкара.

Ул үзенең иҗатында Көнбатыш һәм Көнчыгыш тарих фәне традицияләрен берләштерә, хезмәтләрен рус һәм көнчыгыш, төрки телләрендәге чыганакларга таянып яза. Шул исәптән, 1523 елгы Казан ханы Сәхиб Гәрәй тарафыннан бирелгән тарханлык ярлыгын матбугатка чыгара, «Хәнәкә солтан» исемле тарихи бәетне бастыра, Казанның беренче рәсми исеме Яңа Болгар булуы турында хәбәр кертелгән фарсы телендәге «Татар елъязмасын» таба.

Әйтергә кирәк, бер үк вакытта диярлек борынгы һәм урта гасыр татар тарихын язуга бер төркем милләтпәрвәр интеллектуаллар алына. Шулар арасында уңышка ирешкән иң мәшһүрләре – Хәсәнгата Габәши («Мөфассал тарихе кауме төрки» – «Төрек кавеменең җентекле тарихы», 1909), Гайнетдин Әхмәров («Болгар тарихы», 1909; «Казан тарихы», 1910), Әхмәтзәки Вәлиди («Төрек вә татар тарихы», 1911; «Кыскача төрки-татар тарихы», 1912). Аларның китаплары урта мәдрәсәләргә уку-укыту дәреслекләре буларак әзерләнә, яшь буында тарихи карашлар формалаштыруда мөһим роль уйный.

Һади 1913 елда Казан университеты каршында эшләп килгән Тарих, археология һәм этнография җәмгыятенә әгъза итеп сайлана, аның фәнни аралашу даирәсе киңәя.

Гомумән алганда, Атласиның «Себер тарихы» шул заман гуманитар фәненең үсеш дәрәҗәсен гәүдәләндерә. Автор XVI–XVIII гасыр рун язма һәйкәлләрен өйрәнү нигезендә формалашкан, төрки халыкларның борынгы ватаны Урта Азия (Алтай таулары) дигән концепциягә таяна.

Себер татарларының тарихын киң масштабта күзәтеп, ул аларны татар милләте тарихының аерылгысыз өлеше буларак бәяли. Себер ханлыклары һәм Себерне яулау тарихыннан тыш, автор Чыңгыз ханнан башлап Себер ханнарының эш-гамәлләрен тасвирлый. Күчем ханга махсус туктала, аның Себердә ислам динен таратудагы искиткеч мөһим ролен бил-

гелэп үтэ, ватаны өчен һәлак булган ханны заманга ярашлы үрнәк шәхес образында сурәтли.

Тагын өч елдан Атласиның «Сөенбикә» һәм «Казан ханлыгы» исемле китаплары дөнья күрә. Бу басмалар авторга тарихчы буларак танылу китерә. «Казан ханлыгы» яшь Татар автоном республикасында 1920 нче елларда ике тапкыр кабат басыла. Автор ханбикәнең Казан чоры һәм Касыйм чоры тормышын 1554 елгача тасвирлап, аны татар халкының акыллы дәүләт эшлеклесе сыйфатында бәяли. «Казан ханлыгы» китабы структурасы Олы Мөхәммәдтән башлап идарә иткән ханнар эшчәнлеген яктырту рәвешендә төзелгән. Автор 1552 елда Казан ханлыгының тар-мар ителүен берьяклы гына яктыртып, чынлыкта бу аяныч вакыйганың сәбәпләре күптөрле булса да, гаепне Казан халкы арасында бердәмлек булмауда, дошманга сатылуда, милләт турында кайгыртмауда, ирек-азатлыкны читтән көтеп ятуда күрә. Күренекле рус галиме Василий Бартольд шуңа күрә дә, Атласиның мондый үзенчәлекле карашын күздә тотып, аның үзен «татар патриоты» дип атый.

СОВЕТ ИЛЕНЕҢ «ЫШАНЫЧСЫЗ КЕШЕСЕ»

1917 елны Һади Атласи гаиләсе белән Бөгелмә шәһәренә күченә, биредә өяз земство управасында халык мәгарифе өчен җаваплы белгеч була. Совет хакимиятен таный. Гражданнар сугышы башлангач, шәһәрдә Колчак гаскәре урнашкан вакытта земство управасы рәисе вазыйфасын башкара һәм аклар белән Чиләбегә кадәр чигенә. Германиягә күченү планы тормышка ашмагач, ул, Бакуга китеп, шәһәр советы мәгариф комиссариатының төрки бүлегендә эшли башлый. Кызыл Армия Бакуны алгач, туган ягында революциягә каршы эшчәнлектә гаепләнеп, мәхкәмә җаваплылыгына тартыла. Гаебе расланмыйча төрмәдән чыга һәм Совет хөкүмәте өчен ышанычсыз шәхескә әйләнә.

1921–1929 елларда Бөгелмәдәге икенче баскыч татар мәктәбендә укыта, 1926–1928 елларда ике еллык укытучылар әзерли торган курсларда белем бирә. Харизматик характеры, кайнар энергияле оста ораторлыгы галимнең лекцияләрендә дә чагыла. Әйтик, Каюм Насыйриның 100 еллыгы уңаеннан укыган докладлы тәэсирендә бер төркем халык, шәһәр хакимиятенә барып, Бөгелмә урамнарының берсенә бөек мәгърифәтче исемен бирдерүгә ирешә.

Тарихчы галимне мәктәптә укыту гына канәгатьләндерми, ул гыйльми эшчәнлеген дәвам итә: «Русиянең иске һәм яңа тарихын», «Казан ханлыгы»ның дәвамын яза, Сәгъдинең фарсычадан «Гөлстан» поэмасын татарчага тәрҗемә итә, ләкин берсен дә бастыра алмый. Кызганычка, тарихчы икенче тапкыр кулга алынгач, бу кульязмалар конфискацияләнә, кире кайтарылмый һәм юкка чыга...

Олы сәясәткә Һади Атласи кабат 1927 елда килеп керә: ул татар зыялылары исеменнән Иосиф Сталинга һәм ВКП (б) ның Татарстан өлкә комитетына гарәп имласыннан яңалифкә күчүгә каршы язылган күмәк хатка кул куя. 1929 елда Мирсәет Солтангалиевкә каршы сәяси кампания башлангач, Атласи да гаепләнеп, 10 елга ирегеннән мәхрүм ителә, сөргенгә, Соловки утравына җибәрелә. 1933 елда, сәламәтлеге начараю сәбәпле азат ителеп, Бөгелмәгә кайта. 1934–1935 уку елында Казанда татар мәктәпләренең берсендә немец теле укыта, ахыр чиктә кабат сәяси яктан ышанычсыз дип табыла. Ел ярым эшсез йөргәннән соң, 60 яшьлек Атласи 1936 елда кабат кулга алына, милләтчелектә, чит илләр файдасына разведка эшчәнлегендә һәм совет хакимиятенә каршы баш күтәрүне әзерләүдә гаепләнә. Чекистлар «Атласовчылар төркеме» дигән ялган мәхкәмә «эше» әзерләп, тагын алты дистә мулланы шундый ук гаепләүләр белән хөкем итә.

Һади Атласиның көрәшче рухын совет төрмәсе дә сындыра алмый. Ул 1938 елда төрмәдә үлә. Исеме 1958 елда аклана.

3
Һади Атласи хатыны Хөсникамал һәм кызы Сәлма белән. 1908 ел.

PRESSA



РАБИТ БАТУЛЛАНЫҢ ТОРМЫШ АГЫШЫ

Автор:
Руфия Фазылова

Балачагым сугыш елларына туры килде. Өч яшемдә генә булуга карамастан, сугыш башланган көн урык-сурык булып мәңгегә истә калган.

Без ул вакытта этинең туган төбәге – Зәй районының Шыкмай авылында яшибез. Авылда гармун тавышы, җырлашалар, елашалар. Каршы якта яшәүче Сәүбән абый да сугышка китәргә тиеш. Сәкедә балалары елаша. Сәүбән абый исерек. Эчми, эчмәгәнгә, акылы киткән – сугыша, карыша. Сугышка барасы килми моның. Башта йорт ишегеннән, аннан капкадан көчкә сөйрәп алып чыктылар. Дуслары кулларына сугалар. Мин кечкенә, бу хәлләрнең чын фаҗигасен аңламыйча, куркып, шаклар катып карап торам. Сәүбән абыйны бәйләп, тарантаска утыртып,Чаллыга – пристаньга алып киттеләр. Шуннан кайтмады да инде...

Шул вакытта этине дә сугышка озаттык. Эти сугыштан исән-сау кайтты. Сау дип, ул әсирлектә булган. Аның күргәннәре... Бер ел совет төрмәсендә утырып чыкты, нык кыерсытылды. Безгә тә әлкте – бакчаны кистеләр, эшләреннән сөрделәр. Эти дә, әни дә уналты ел укыту тәҗрибәсе булган мөгаллимнәр иде. Юкка бәйләнүләр... Эти шуннан түзмәде – Пермьгә чыгып ычкынды. Балта остасы да иде ул. Шуннан соң гына безнең гаилә тынычлыкта калды.

Фото: «Татар-информ» МА (Рамил Гали)

Мин икенче сыйныфта укыганда, эти яңадан безнең янга әйләнеп кайтты. Ул чакта әни Зичәбаш авылы мәктәбендә укыта иде. Әтине әсир төшкәне өчен «кичерделәр» – яңадан мәктәпкә эшкә алдылар. Әти мине дә укытты. Без яңадан этинең туган ягына – Зәй төбәгенең Шыкмай авылына әйләнеп кайттык.

Сугыш беткән көн дә күңелдә мәңгелек хатирә булып калган. Без мәктәптә укыйбыз. Авылдан биш чакрым ераклыктагы басуда колхозчылар эшли иде. Халык аны ерак басу дип атап йөртте. Без, барлык мәктәп укучылары, сугыш бетте дигән бик сөенечле хәбәрне җиткерергә колхозчылар янына шул басуга бардык. Эшчеләргә дип казанда борчак пешергәннәр иде. Өлкәннәр безгә шул казанда пешкән борчакны бүлеп бирде. Үзләре сөенечтән елашалар, кочаклашалар. Ә без, балалар, күбрәк борчак ашаганга сөендек. Аның тәме бүген дә авызда тора...

Тәрбия табын янында башлана. Кайбер ата-аналар икеле алган өчен ул-кызларын почмакка бастырып тота. Бу – тәрбия чарасы түгел, ә баланы иркеннән мәхрүм итү дигән сүз.

Безнең малайлар начар билге алып кайтса, әниләре: «Ярар, алары да дәүләт билгесе», – дип әйтә иде. Алар өстендә кылыч тормады. Моның өчен әниләренә рәхмәт әйтергә кирәк. Бу бер. Икенче, балаларга бармак белән дә сукмадык. Бер суккач, тагын сугарга күнегеп китәсең бит. Безнең балаларның буш вакытлары булмады. Шуңа да урам йогынтысына бирелмәделәр.

Балалар тәрбиясе турында «Сак-Сок» бәетендә әллә кайчан әйтелде бит. Бер халыкта да мондый әсәр бүтән юк. Ул безнең иң борынгы музыкаль әсәребез. Ислам дине кабул ителгәнче язылган дип уйлыйм, чөнки анда «Алла» сүзе юк. Ана кеше: «Баламны кайтар», – дип Аллаһка ялынмый.

Бәет матриархат чорында барлыкка килүенә ишарә ясый. Ана – хуҗа, ана каргый, ата – хокуксыз.

Фәлсәфи яктан карасаң, ул бүгенге көндә дә бик актуаль – «Сак-Сок» демографик әсәр дә. Беренчедән, ике туган бер-берсе белән дошманлашырга тиеш түгел: татар белән башкорт... Икенчедән, ана ул-кызын тәрбияләргә хокуклы, ләкин җәза биргәндә хәттин ашмаска тиеш. Чөнки ул фаҗигагә китерә. Бер кечкенә генә бәеттә менә нинди тирән мәсьәләләр күтәрелә.

«Сак-Сок» – шаһ әсәр. Бу ике бала турында кино төшерергә, пьеса язарга, опера, балет куярга кирәк. Башка милләтләрдә шундый әсәр булса, әллә ниләр эшләрләр иде!

Бездә бик шәп тарихчылар бар. Әйтик, Миркасыйм Госманов, Равил Фәхретдинов, Дамир Исхаков, тагын башкалар. Алар чын тарихчы, аларның алдашырга, фантазия кыстырырга хокуклары юк. Ни кызганыч, күп вакыт тарихны уйдырма итеп язалар. Менә андыйларга карата нәфрәтем көчле.

Тарих темасына язучы әдипләр бар. Алар икесе ике әйбер. Мин дә тарих темасына шактый яздым. Сөембикә, Тукай, Нуриев турында... Мисалга «Сөембикә» романын алыйк. Ханбикә улы белән манарадан сикергән дигән бәет бар. Шул ук вакытта тарихи факт та яши – Сөембикә баласы белән әсирлеккә төшә. Ул шунда һәлак була. Хәзер мин ике ут арасында калдым. Халык артыннан барыргамы, әллә тарихи документларга таянырганы? Язучы буларак, кайсы юлдан барсам да, хаклы. Мин икесен бергә куштым. Шул рәвешле укучыга бәләкәй генә белем дә бирдем төсле.

«Сөембикә» романын халык легендасына да, тарихка да таянып яздым. Күрәсең, ул дөрес юл булгандыр. Шуның өчен Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирделәр. Ни гаҗәп, «Сөембикә» романын теттереп сүккән кеше булмады. Гаеп эзләү бездә әйбәт корылган бит. Иң кызыгы – тарихчылар бәйләнмәде. Дөресен генә әйткәндә, тәнкыйтьчеләргә караганда, әсәрләремнең җитешсез якларын күбрәк беләм. Бу ягын күрми калдылар әле, дип тә сөенәм кайвакыт.

Халык ни өчен Сөембикәне манарадан ташлап үтергән? Югыйсә ул бит Сөембикәнең әсир төшкәнен белгән. Яр буена халык аны үзе озата барган! «Сөембикәне азат итегез», – дип Йосыф ничәмә-ничә хат язган. Боларын да беләбез. Үтәмешнең чукындырылуы да билгеле факт. Халык – бу очракта язучы – Сөембикәнең әсирлеккә төшүен теләмәгән. Ул батырлык көткән. Шуңа күрә аны манарадан «ташлаткан».

Тормышта төрлесен күрдек. 90 нчы елларда мин каравылчы, ә Рузия урам себерүче булып эшли башлады. Әле мин анда танышлык белән генә урнаштым. Рузия ул хезмәтендә шактый эшләде. Үзгәртеп корулар булмаса, андый авырлыклар күрмәс идек, чөнки шактый иркен яшәп алдык. Кассада ике «Волга»лык акчабыз гына да янды.

Өйдәге эшләрдән мин азат. Моның өчен хатыным Рузиягә рәхмәтлемен. Кием-салым алу турында да уйлаганым булмады. Ипинең ничә тиен торганын да белмәдем. Рузия белгечлеге буенча икътисадчы. Тормышта да бик төгәл ул. Хатын шундый булырга тиештер. Балаларны анда-монда йөртү дә Рузия өстендә булды. Ә мин гел иҗат эше белән яшәдем.

Бергә кырык елга якын гомер итәбез. Бу дәвер эчендә кеше бер-берсеннән туярга яки ки-

ресенчә якынаерга тиеш. Аллага шөкер, бездә икенчесе.

Дүртәү бергә чәй эчкәндә малайларга: «25 яшькә кадәр икегез дә өйләнмисез, аракы эчмисез, тәмәке тармыйсыз», – дип әйтеп куйдым. Нурбәк туган көнне: «Әти, миңа 25 тулды, өйләнәм», – диде. Өйләнде. Алар үз юлларын таптылар, безнең вазыйфаларыбыз бетте. Балаларым минем йөзгә кызыллык китермәсеннәр, дип куркып яшәдем. Укыганда да, эшләгәндә дә. Инде картлык көнемдә аларның йөзенә кызыллык китермәсәм ярар иде, дип яшим.

Милләтне бетерү өчен мәктәбен бетерергә кирәк. Милләт – әлифбасына, мәгарифенә, диненә, теленә, тарихына баш булырга тиеш. Татар халкы 30 нчы елларга кадәр милләт иде – үз язмышына үзе хуҗа булды. Мәктәпләр байлар хисабына төзелде, мәчетләрне халык төзеде. Хөкүмәт бюджетыннан сукыр тиен дә алмыйча, татар халкы Франция шәһәрләренә, Бәйрутка, Берлинга укучыларын җибәреп укытты. Менә милләт нинди булырга тиеш!

Милләтләр тигез, дип кайчаннан бирле сөйләнәләр. Тик тигезлек юк ул, мескенлек кенә бар. Татарга автономия, ә грузиннарга союздаш республика статусын бирделәр. Ә бюджетын җир белән күк арасы иттеләр. Бу бит инде мескенлек, татарны икенче сортлы дип тану. Ә грузин, азәрбайҗаннар беренче сортлы саналды. Бер мисал – без, театрда яңа эшли башлаган артистлар, җитмеш сумга якын хезмәт хакы ала идек. Ә грузиннарның яшьләренә йөз илле сум бирделәр. Безнең СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлилов өч йөз сум хезмәт хакы алса, тегеләрнең шундый ук дәрәҗәдәге артистына сигез йөз сум түләделәр! Мыскыл димичә, ни диясең?! Грузиянең шәрабыннан башка бернәрсәсе юк, ә без нефтьтә коенабыз. Ә алар барыбер өстен булды!

Безнең интеллигенция алты тел белгән. Без русча белсәк, татарча сөйләшмибез, татарча белсәк, русчабыз – юк. Татар халкы үз хисабына югары мәктәпләр тоткан халык. «Иж-Бубый», «Галия» мәдрәсәләре – болар югары мәктәп бит. Ә без бүгенге көндә башлангыч, урта мәктәпләребезне дә ябабыз.

Илле елдан соң безнең әсәрләрне укучы калмаячак. Оныкны татар балалар бакчысына бирдек. Ник бер бала ана телендә сөйләшсен!

Язучыларның 90 процентының балалары татарча белми. Әтисенең язганнарын укый алмый. Ә оныклар турында сүз дә юк. Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттахның балалары татарча белем-тәрбия алды дип әйтә алам. Карагыз Аяз абыйның балаларын: берсе галим, берсе язучы булып китте. Алар татар сәнгатенә хезмәт итәләр. Шәһәрдә үскән балалар бит.

Җәйне күбрәк Биектау районың Чыршы авылындагы йортыбызда үткәрәбез. Бирeдә күп иҗат әһелләре, журналистлар булды инде. Шуңа күрә күпләр андагы музей турында ишетеп белә. Элеккеге хуҗалардан калган йорт ул. Үзебезгә яңа йорт салып чыккач, иске өйгә әнә шулай яңа сулыш өрдем. Музей минем өчен беренче чиратта ял итү урыны. Еллар дәвамында шактый күп экспонат тупланды. Чыршы авылы кешеләре дә элеккеге көнкүреш кирәк-яраклары алып килеп бирде. Экскурсиягә авыл кешеләре, мәктәп балалары килә.

Пәкеләр, бакалар җыюым да яңалык түгел. Күңелгә ошый бу эш, шуңа җыям. Татар коралга мөкиббән булган. Мәрхүм Нәкый ага Исәнбәт тә пәке җыя иде. 1552 елдан соң татарга тимерчелектә эшләргә ярамаган – корал коймасыннар, дип шүрләгәннәр. Шуңа күрә татарга пәке дә йөртергә ярамаган. Пәкеләрнең төгәл санын әйтә дә алмыйм, күп инде. Алар барысы да бүләк.

Сиксән тулганлыгын сизмим дип әйтмим, сизәм. Аяк-куллар йөри, күз күрә, димәк, яшим! Авыртам, димәк, яшим! Авыртмасаң, яшәмисең булып чыга. Менә әле эшләп утырам бит. Көндәлекләрдән торган өч томлыгым чыгарга тиеш. Шуның беренче томын басмага әзерләп утырам. Бу минем күп еллар дәвамында алып барылган көндәлекләрем, ягъни биографиям. Укучыга кызык булачак җирләрен калдырып, редакциялап, шуны китап итеп бастырып чыгарырга ниятлим.

Заманнан артта калмаска тырышам. Язган әйберләремне компьютерда үзем җыям. Сәламәт яшәү режимы алып барам дип әйтә алмыйм. Гомумән, режим тота белмим. Дөрес, Рузия ашауга нык игътибар бирә. Сәламәтлек өчен файдалы булган ризыклар әзерли. Мине яшәсен ди инде, картайтасы килми!

БЕЛЕШМӘ:

Рабит Батуллин 1938 елның 26 мартында Татарстанның Зәй районы Түбән Олыҗы авылында туа. 1956–1961 елларда Мәскәүдә Щепкин исемендәге театр училищесында укый. Аны тәмамлагач, ике ел Татар дәүләт Академия театрында актер булып эшли, шул ук вакытта режиссерлык эше белән дә шөгыльләнә.

Рабит Батулла әдәбиятның төрле жанрларында иҗат итә. Аны драматург, прозаик, балалар язучысы буларак та беләләр.

1985 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә. Әдәбият өлкәсендә ирешкән уңышлары һәм иҗтимагый эшчәнлеге өчен ул Гаяз Исхакый исемендәге премиягә һәм Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

ЧЫНБАРЛЫК ТУРЫНДА – УЙДЫРМА ДӨНЬЯДА

Автор: Луиза Янсуар

Соңгы елларда мәгълүматны кабул итүнең иң кулай ысулларыннан берсе – подкастлар. Китапларны – укып, фильмнарны карап тормыйча гына, алар турында сөйләгән подкастлар аша ишетеп тә яшәп булганына инандыра безне бүгенге чынбарлык. Ә инде үзеңне үстерү, тәрбияләү, белем алу, технологияләрне үзләштерү, күңел ачу – болары хакында әйтеп торасы да юк. 15–20 яисә 30–60 минут бөкедә уздырган вакыт аралыгында, фатирны җыештырганда яки йөгерергә чыкканда, замана гурулары сиңа барысын да сөйләп бирәчәк.

Фотолар: https://meduza.io/, https://tvrain.ru/, https://libolibo.ru/ платформаларыннан.

ЛОКДАУН ҺӘМ ЯҢА ФОРМАЛАР

Сораштыруларга караганда, иң популяр формат – музыкаль подкастлар, аудиоблоглар, ток-шоу һәм әңгәмә. Шулай ук рейтингларда иң алдынгы урында торган тагын берсе – лекцияләр. Подкастны күбрәк смартфоннан махсус кушымта йөкләтеп алып тыңлыйлар. Андроидларда гадәттә Google Podcasts кушымтасына мөрәҗәгать ителсә, айфонда бу – Apple Podcasts кушымтасы. Уңайлы софт кушымталар белән генә төгәлләнми, шулай ук социаль челтәрләр, һәртөрле сервислар, сайт аша тыңлаучылар да бар. Подкастлар турында гәплəшү өчен аерым каналлар да булдырыла, нигездә, Телеграмда.

Россиядә подкастларның иң югары популярлык ноктасы, әйтүләренә караганда, 2018 елга туры килә. Аларның кульминация ноктасына җитүенә COVID-19 таралуы да, локдаун белән яшәешнең онлайн-режимга күчүе дә сәбәпче. Бу чорда подкастлар арасында нәкъ менә белем, киңәшләр бирү, психологик һәм профессиональ яктан төрле өлкәләргә караган әңгәмәләр күбәеп китә. Бүген подкаст форматында дөнья яңалыкларын да, спорт аналитикасын да, атаклы шәхесләр турында лекцияләр дә, финанслар һәм башка бик күп өлкәләр буенча мәгълүмат алу программаларын да табарга мөмкин. Ә менә подкастлар яулап алмаган өлкәне табуы шактый читен. Хәтта аудиокитаплар белән аудиоспектакльләр дә, подкастлар үсешенә бәйле рәвештә, икенче сулыш алды. Уку, кабул итү, тәэсирләнү дә бүген кыскача кемдер «чәйнәп каптырган» анализга, ягъни икенче берәүнең күзәтү ноктасына бәйле.

ТРЕНДЛАР, ЯКИ НӘРСӘ КӨТӘРГӘ КИРӘК?

2020-2021 еллардагы мәгълүмат буенча, «Яндекс.Музыка» язылучыларының 28%ы, стриминг сервисына кергәч, яңа подкастларга күз йөртеп чыкмый калмый, ә шулар арасында 14%ы подкастларны атнага бер мәртәбә булса да тыңлый. Уртача исәпкә караганда, подкастларга без көнебезнең, азмы-күпме, 2-4 сәгать вакытын сарыф итәбез.

2020 ел рус телле Интернет дөньясында эш итүче подкастчылар өчен чын мәгънәсендә уңыш елы, дип исәпләнә. Шушы бер ел эчендә генә платформалардагы яңартылган подкастлар саны 1 меңнән артып киткән. Алай гына да түгел, подкаст – интим сөйләшү яки мәгълүмат тарату чарасы гына булудан туктап, экспериментлар өлкәсе булып та әверелеп бара. Медиаконцерннар аның аудитория белән кире элемтә булдыру өчен бик уңайлы канал булуын абайлап алды һәм актив куллана башлады. Һәрбер үзен хөрмәт иткән басма яки ГМЧ подкастлар сериясенә нигез салды. Театр, кино индустриясе, музейлар, уку йортлары, спорт юнәлешләре һ.б. – барысының да үз подкаст-каналлары бар.

Подкаст өлкәсенә эре рекламачылар килде. Күпсанлы студияләр һәм зур компанияләр брендлы подкастлар сериясен булдырды. Хәтта банклар да. Бүгенге көндә эре компанияләр һәм стриминг сервислары арасында проектлар, авторлар һәм жанрлар көрәше бара. Ә без ул арада Россиядә инде үзен танытып, абруен ныгытып өлгергән 5 иң популяр подкастка тукталып узыйк.

«ЧТО СЛУЧИЛОСЬ»

ЯКШӘМБЕДӘН КАЛА, ҺӘР КӨННЕ ЧЫГА, АУДИОФОРМАТТА

Подкастлар барлыкка килү белән яңалыкларны тәкъдим итү һәм кабул итү культурасы да үзгәрде. «Медуза»ның (Россиядә чит ил агенты-ГМЧ буларак игълан ителде – авт.) яңалыклар подкасты – шуның ачык мисалы.

Якшәмбедән кала, барлык көннәрдә дә эфирга чыга. Шимбә көннәрдә – махсус чыгарылышлар. Подкастны сайттан яки аерым кушымта аша тыңларга мөмкин. Чит ил агенты буларак игълан ителгәннән соң, «Медуза» «Что случилось» һәм башка подкастларын аерым туплады – аларны хәзер кереп тыңларга бик җиңел.

«Что случилось» подкастларының һәр чыгарылышы бүгенге көндә актуаль булган теге яки бу темага багышлана. Бу – теманы үзәккә куеп сөйләшү генә түгел, ә аңа төрле яклап күз салырга омтылу да. Алып баручылар – журналист Владислав Горин һәм шимбә чыгарылышы авторлары – журналист Андрей Перцев, социолог Константин Гаазе.

Подкастка чакырылган кунаклар гадәттә үз өлкәсенең белгечләре, аларның экспертларча фикере иң катлаулы мәсьәләләрне дә җиңел һәм барлык ракурслардан ваемларга мөмкинлек бирә. Ягъни актуаль мәсьәләләр турында җитди, профессиональ сөйләшү дигән сүз бу. Бүгенге көндә Россиядә әлеге подкаст тиз арада әһәмиятле һәм көнүзәк

темалар турында фикереңне булдырырга ярдәм иткән иң күп тыңлана торган чыганаклардан исәпләнә. Шунысы да игътибарга лаек: «Что случилось»ны яшь буын да, урта буын да актив тыңлый. Ә менә 65+ һәм аннан өлкәнрәкләр – алай ук түгел.

«ДНЕВНИКИ ЛОРЫ ПАЛНЫ»

АТНАГА БЕР МӘРТӘБӘ ЧЫГА, АУДИОФОРМАТТА

АКШта бүгенге көндә иң популяр подкастлар тру-крайм форматында. Бу – документаль-криминаль жанр дигәнне аңлата. Журналистлар Маша Погребняк белән Митя Лебедев әлеге жанрны Россия киңлеге өчен дә сынап карарга булган. Ә инде подкастның атамасына килгәндә, 80–90 нчы еллар буыны өчен яхшы таныш «Твин Пикс» сериалына ишарә – үзенә күрә бер ачкыч та. Нәкъ менә Линчның культ дәрәҗәсендә йөргән сериалы күп нәрсәләргә күзебезне ачты бит. «Совы не то, чем они кажутся» гыйбарәсе дә үзаңыбызга шуннан урнашып калды.

«Безне подкаст-индустриягә SoundStream студиясе генераль продюсеры Кристина Крыжановская чакырды. Ул чакта рус аудиобазарында тру-крайм жанрында берни дә юк иде әле. «Дневники Лоры Палны» атамасын минем хатыным уйлап тапты».

Митя Лебедев

«Без серияле үтерүчеләр һәм маньяклар турында сөйләүне генә максат итеп куймыйбыз, алар белән бәйле тарихларга нигезләнеп, җәмгыятьнең социаль портретын сурәтләргә дә омтылабыз. Җинаятьләр контексты бик әһәмиятле, алар аша ил тарихының төрле этапларында нәрсәнең һәм ни өчен булганын аңларга мөмкин».

Маша Погребняк

Подкаст Россиядәге һәм дөньядагы иң хәтәр маньяклар, үтерүчеләр һәм алар белән бәйле вакыйгаларга багышланган. Авторлар һәм алып баручылар аны шактый кызыклы һәм мавыктыргыч итеп әзерли, тәкъдим иткәндә, һәм форма, һәм эчтәлек ягыннан тулыканлы картина тудыруны максат итеп куя. Бу кызык өчен генә сөйләшеп утыру түгел, ә ныгытып әзерләнгән һәм нарративка тулаем күмелеп башкарылган анализ һәм рефлексия дә. Тыңлаучыларны әнә шул җәлеп итә дә. Әмма йоклар алдыннан тыңламау хәерлерәк.

Подкаст шулай ук социаль челтәрләрдә – «Инстаграм», ВК, «Фейсбук»та да тәкъдим ителеп бара.

«ПСИХОЛОГИЯ НА «ДОЖДЕ»

АТНАГА БЕР МӘРТӘБӘ ЧЫГА, ВИДЕОФОРМАТТА

Дөнья күзгә күренеп үзгәрә, без аның тизлегенә ияләшеп өлгермибез, очына чыга алмастай мәгълүмат дәрьясына батабыз, калкып чыгабыз да яңадан аяк астындагы туфракны югалтабыз. «Заман кешесенең төгәл ориентирлары юк, шуңа да ул психологик яктан бик тә бирешүчән», – ди социологлар.

«Дождь» каналы (Россиядә чит ил агенты-ГМЧ буларак игълан ителде – авт.) бу җәһәттән бик тә файдалы һәм үтемле подкаст тәкъдим итә. Абруйлы һәм үз эшенең остасы булган белгечләрне (психолог, педагог, социологлар) чакырып, биредә һәркем өчен әһәмиятле булган, борчый торган темаларга сөйләшәләр: карьера, шәхси мөнәсәбәтләр, хыянәт, аерылышу, бала тәрбияләү, стресс, эштәге һәм өйдәге низаглар, буыннар арасындагы бәйләнеш, приютлар белән картлар йортлары, үлем, бала туу һ.б.

Подкастның авторы һәм алып баручысы – Александра Яковлева. Ул абруйлы белгечләр-

не чакырып, алар ярдәме белән уникаль платформа булдыра алган. Без якыннарыбыз белән дә сөйләшергә кыенсына торган темаларга монда курыкмыйча һәм ачыктан-ачык сөйләшәләр, киңәшләр бирәләр, проблеманы хәл итү юлларын эзлиләр, кайларга мөрәҗәгать итәргә мөмкин булуын искәртәләр. Подкаст «Инстаграм»да да тәкъдим ителгән, әйтүләренчә, анда директка сораулар, темалар язып җибәрү мөмкинлеге бар.

«ГОЛЫЙ ЗЕМЛЕКОП»
АТНАГА БЕР МӘРТӘБӘ ЧЫГА, АУДИОФОРМАТТА

Чираттагы кызыклы подкастларның берсе – биолог һәм журналист Илья Колмановский проекты. Автор үзе әйткәнчә, бу проектның максаты – «гыйлемнең күңелсез һәм эчпошыргыч түгел, ә мавыктыргыч була алуын исбатлау». Подкаст моны чынлап та исбатлый – катлаулы темаларны да кызыксынып тыңлыйсың, автор һәм алып баручының харизмасы һәм материалны тәкъдим итү манерасы шулай ук үз эшен эшли.

«Йонсыз җирказыр – ул гаҗәеп җанвар. Яман шеш авыруына дучар түгел, беркайчан да диярлек картаймый. Әнә шуңа да мин аның исеме белән подкастны атарга булдым, ә үзен тотем җанварым итеп билгеләдем».

Илья Колмановский

Фәнни ачышлар, атаклы галимнәр – подкастны аларның дәрәҗәле фикерләре белән мөнәсәбәте дә бизи. Шулай ук тыңлаучыларның сорауларына җавап бирү, кире элемтә булдыру да – гаять әһәмиятле.

«ЗАПУСК ЗАВТРА»
АТНАГА БЕР МӘРТӘБӘ ЧЫГА, АУДИОФОРМАТТА

Бүгенге көнне технологияләрдән башка күз алдына китереп булмый гына түгел, ә ул технологияләр артыннан куып җитә алу да – үзе бер фән. Ригада яшәүче Самат Галимов нигез салган «Запуск завтра» подкасты әнә шул турыда – бүгенге көн технологияләрен генә түгел, ә иртәгә нәрсәләр булырга торганын да барлый ул. Хакерлар аңа куркынычсызлык ысуллары турында сөйли, дата-сайентислар – машиналарны өйрәтү һәм йөзләрне тану системалары турында. Ни өчен «Фейсбук», «Инстаграм» һәм вотсап 6 сәгать буена «җимерелеп ятты», ә Телеграм-канал – калды; онлайн-банкинг ул нәрсә, аны ничек кулланырга; Клабхаустагы мәгълүматны ничек «тартып чыгарырга» була; Интернет-фольклор ни өчен кирәк... һ.б.лар.

Ә үзе белән бик гади һәм тыйнак кына итеп болай таныштыра Самат:

«Сәлам! Минем исемем Самат Галимов. Миңа 31 яшь, хатыным, ике кызым, бер улым бар. Техник директор булып эшлим, клиентларым арасында шактый зур компанияләр бар. «Медуза» (Россиядә чит ил агенты-ГМЧ буларак игълан ителде – авт.), Букмейт, RAWG, Pure ның техник директоры булып эшләдем, Артдокфестка ярдәм итәм.

Катлаулы әйберләрне җиңел генә итеп аңлатырга яратам. Психолог белән психотерапевт һөнәрен үзләштерәм, укыйм. Миңа тормышка экзистенциаль якын килү отышлы тоела».

P.S. Әлегә менә шулар. Дәвамы булачак.

КОЯШЛЫ МОРТЫШТАМАК

Автор: Руфия Фазылова

Мортыштамакка юлга кузгалганда, Казанда яңгыр ява иде. Чаллыга җиткәндә көн аязды. Инде Сарманга кергәч, ялтырап кояш чыкты. Без моны яхшыга юрадык – авылда яшәүче халык та кояш кебек нурлы, җылы булырга тиеш...



Фото: Александр Ефремов



МОРТЫШТАМАК

ЧИТЕК КИРӘК!

Мәдәният йортында безне җырлап каршы алды алдылар. Чигүле алъяпкыч, таратып бәйләнгән чигүле яулык, бала итәкле күлмәк – барысы да үзебезчә. Ә тавышлары! Тын да алмыйча, сөйкемле апаларның чыгышларын карап тордык. Мортыштамакның «Чишмә» ансамбле икән, дүрт ел элек оешкан. Тальянда уйнаучылары да үзләрендә.

– Бу кызлардан башка бер генә чара да узмый, – ди Мортыштамак авылы җирлеге башлыгы Илдар Һадиуллин. – Өч ел элек Казанга барып, WorldSkills дөнья чемпионатына килгән чит ил кунакларын каршы алдылар. Сәгать ярым җырлап-биегәч, тегеләр хәлдән таеп егылды, ә безнең кызлар әле тагын бер сәгать биеде.

Дүрт ел эчендә «Чишмә» ансамбле кайларда гына чыгыш ясамаган! Әле Сочига чакырганнар, тик, пандемия сәбәпле, чыгып китми торалар.

– Ә бу милли концерт киемнәрен үзегез тектердегезме? – дим.

– Әйе. Башта үз акчабызны биргән идек, аннан иганәчеләр табылды. Сарман ветераннар советы күлмәк хакын, ә алъяпкыч, яулык өчен авылдашыбыз Марат түләде. Хатыны Әлфия безнең ансамбльдә. Менә хатынны ярату ничек була ул, – диеште апалар.

– Ә ирләрегез болай җырлап-биеп йөргәнгә сүз әйтмиме соң?

– Юк, әйтмиләр. Репетициягә килгәч, рәхәтләнеп ял итәбез. Туйганчы сөйләшәбез, чәй эчәбез. Өйгә яшәреп кайтабыз.

«Чишмә» ансамбленә йөрүче һәр апаның диярлек ниндидер шөгыле бар. Кемдер чигүче, бакчачы, кемдер спорт белән шөгыльләнә, кайсыдыр тальянда уйный. Картлык килде, дип боегып утыра торган хатын-кызлар түгел – күзләре янып тора. «Чакырган бөтен җиргә барабыз», – диләр. Район буенча концерт куеп йөриләр. Үзләре сөйли, җырлый, бии, гармунда уйный, шаян күренешләр куя. Республика күләмендә үткәрелгән төрле конкурсларда җиңү яулыйлар. (Диплом-грамоталар белән өстәл тулган иде.)

– Шифаханәләргә, «Шәфкать» Халыкны социаль яклау үзәгенә барып чыгышлар ясыйбыз, – диде Мортыштамакның сәләтле апалары. Шуңа игътибар иттем: Мәдәният йорты яңа булмаса да, бик нурлы. Мөгаен, шушы апаларның күңел җылысы әлеге таш бинага да җитәдер...

«Чишмә» ансамбленә йөрүче апаларның һәркайсы белән танышып чыктык. Авылның зыялылары икән – кайсы мәктәптә, балалар бак-

1
Мортыштамакта «Чишмә» ансамбле дүрт ел элек оешкан. Тальянда уйнаучылары да үзләрендә.

2
Бирелә биш Ленин ордены иясе генә бар!



3
Сергей Кудрявцев егерме өч ел элек Удмуртиядән гаиләсе белән кучөнеп кайткан.

4
– Бүген минем КФХда сиксән баш тана һәм бер үгез бар, – ди Владимир Кудрявцев.

часында, авыл советында, китапханәдә, банкта, кибеттә эшләгән. Иң яшь ханымга – илле сигез яшь, иң өлкәненә җитмеш бер тулган.

«Чишмә»ләләр бергә сәяхәтләргә дә йөри: «Машина яллыйбыз да чыгып китәбез», – диләр. Шул ук вакытта алар ахирәт турында да онытмыйлар – бергәләшеп дин сабаклары укыйлар.

Ихластан бу шат күңелле, чибәр апаларга сокландым. Лаеклы ялга чыккач ничек яшәргә, дип сорасалар, бу апалар кебек, дияр идем.

Ансамбльнең бердәнбер проблемасы – читекләре юк. (Белгәнебезчә, ул шактый кыйммәт тора.) Могҗиза булып, ансамбльгә читек бүләк итүче табылмасмы, дип хыяллана алар.

ТЫРЫШКАН ТАБАР...

Мортыштамак элек-электән районның атаклы, бай авылы саналган. «Үрнәк» исемле миллионер колхозның даны бик еракларга таралган булган. Бирелә биш Ленин ордены иясе генә бар! Бүген авылда 174 хуҗалык исәпләнә, 446 кеше яши. Быел алты сабый дөньяга килгән, әле тагын туачак икән. Сарманга терәлеп үк торган салада (дүрт чакрым ара) буш йортлар юк диярлек. Тыз-быз йөргән машиналарны күргәч, аптырап та куйдык – гадәттә авыл урамнары буш була. Әлмәт, Җәлилгә йөреп эшләүчеләр күп икән. (Алары да егерме, утыз чакрым ераклыкта гына.) Кыскасы, монда тормыш гөрли.

Читтә генә түгел, авылның үзендә дә эшләүчеләр байтак. Мәсәлән, аталы-уллы фермер Кудрявцевларны районда гына түгел, чит төбәкләрдә дә беләләр. Алар үстергән үгез-бозаулар БДБ илләренә дә озатыла.

Сергей Кудрявцев егерме өч ел элек Удмуртиядән гаиләсе белән күченеп кайткан. Улы Владимирга ул чакта алты ай гына булган.

– Хатынымның туганнары шушы яктан, – диде Сергей.

Авылда үскәнгә, Владимирның татарчасы бер дигән. Хәер, әнисе дә милләте буенча татар икән.

– Кечкенәдән татарча сөйләштем, балалар бакчасына монда йөрдем, – дип елмайды яшь фермер.

Үзләре әйтүенчә, Владимир Кудрявцев республиканың иң яшь фермеры. Өч ел элек, армиядән кайткач, фермер булып теркәлгән.

– Әти унҗиде елдан бирле мөгезле эре терлек асрый, шулай булгач, безнең бу юнәлештә тәҗрибә зур, – ди Владимир. – Бүген минем КФХда сиксән баш тана һәм бер үгез бар. Икеөч ел эчендә берничә техника юнәттек. Узган ел яшь фермерларга бирелә торган конкурста катнашып, биш миллион сум грант оттым. Ул акчага ике трактор, чәчүлек орлыгы, сиксән баш тана алдык.

Әтиле-уллы булсалар да, Кудрявцевлар эшне бүлгән. Владимир игенчелекне төп тармак итәргә хыяллана – арендага авылдашларының пай җирләрен алган. Җәмгысы 220 гектар чәчүлек җире. Дөрес, быел корылык аркасында, фермер чәчкән җирдән әллә ни файда алмаган. Шулай да җыелган иген кыш буе малларга ашатырга һәм язгы чәчүгә җитәргә тиеш икән.

Сергей нигездә мөгезле эре терлек үрчетү белән шөгыльләнә. Гереворд токымлы сыерлар тота ул. (Герефорд – итле токым. Сыерларны саумыйлар, чөнки сөтне бозаулар имә. Максат – сөт алу түгел, ә тизрәк бозау үстерү.) Сергей Кудрявцев сыерларны үзе дә үрчетә, чит төбәкләрдән дә алып кайта. Моның өчен махсус техникасы бар.

– Малларны алып кайткач, бер айга карантинга ябабыз, – ди фермер. – Кан анализларын алып, мөгезле эре терлекнең сәламәт икәнлегенә инангач, көтүлеккә кушабыз. Бер ел эчендә безнең аша өч мең баш терлек уза.

– Малларны ни өчен тере килеш кенә сатасыз? – дим. – Итләтә җибәрү отышлырак түгелме?

– Беренчедән, безнең БДБ илләре белән килешү терлекне нәкъ менә тере килеш сату турында төзелгән. Икенчедән, аларны суярга кул да күтәрелми – кызганам. Монда кан коясым килми.

Владимир берничә ел элек игенчелек белән шөгыльләнеп караган, тик бу өлкә аныкы түгеллеген аңлаган.

– Иген уңармы, юкмы икән, дип борчылып утырасым килми, – диде. – Ә менә улым Владимир җир эшен ярата. Күрәсең, һәркемнең үз тармагы.

КОМГАНЧЫ БАБАЙ

Авылларда сөннәтче бабай булган кебек, комганчы бабайлар да булган. Беренчеләре инде бөтенләй юк – чөнки хәзер өйдә сөннәткә утыртырга ярамый. Ә менә комган ясаучы бабайлар бүген дә очрый. Мортыштамакта без әнә шундый сирәк һөнәр иясе белән таныштык.

Марат Гыйззәтуллин егерме өч яшендә комган ясый башлаган. Бу эшкә аны җәмәгате Әлфия апаның әтисе, ягъни бабасы өйрәткән.

– Бабай берсендә без – кияүләрен җыйды да, калай бөктереп карады. «Синекендә генә өмет бар», – дигән Әлфиягә. Ничектер канатланып киттем. Шуннан өйгә кайткач, үземнең әнигә: «Бабай Маратның кулы тимер эшенә ята дип әйткән», – дим. Әни: «Ятмыйча, бабаң бит тимерче иде», – ди. Бактың исә, әнинең әтисе чиркәү гөмбәзләре ясап йөргән. Безнең әни рус милләтеннән иде. Дөрес, татар авылында яшәгәч, бик яхшы татарча сөйләште. Әнинең кыз фамилиясе Ратникова булган, Мортыштамакта колхоз бакчалары үстергән. Виноградка кадәр үрчеткән. Районда атаклы бакчачы саналган.

Марат абый калайдан самовар морҗасы, комганнар ясый. Шулай ук мич торбалары да эшли. Беренчесенә сорау аеруча зур икән, бигрәк тә җәй айларында.

– Хәзер бит күпләр табигатьтә самовар кайната, – дип аңлата моны калай остасы.

Кибетләрдә бу җайланма мең сум торса, Марат абый аларны 350 сумнан саткан.

– Хәзер калай бәясе нык артты, мин дә бәлки морҗаларның бәясен азрак күтәрермен, – ди ул.

Өй салуның ние бар, мүклисе дә чүтлыйсы, дип әйткән ди бер оста. Комган ясауны Марат абый да шулайрак әйтте: «Калайны бөклисең, каты итеп кысасың...» Югыйсә моның ни дәрәҗәдә авыр эш икәнлеге күз алдында. Дүрт миллиметрлы дүрт кат калайны берьюлы кысарга кирәк. Аз гына ялгышлык җибәрсәң, боздың дигән сүз. Ләкин оста елмая гына – зарлану турында сүз дә юк.

– Минем өчен ял бит ул, – ди.

Комганның бәясе җиде йөз сумнан башлана икән. Мунчага дип алучылар байтак. Шулай ук зиратка заказлар бирәләр.

Ул да түгел сүзгә останың хатыны Әлфия апа кушылды:

5
Кудрявцевлар Герефорд токымлы сыерлар тота.

6 7
Марат Гыйззәтуллин егерме өч яшендә комган ясый башлаган.

8
Чәкчәк пешерү остасы Саҗидә Галиева.

9 10 11
Илүзә Фәррахованың кул эшләрен күреп шаккаттык.

– Маратның гомере шушы сарайда узды инде. Әллә нинди салкыннарда да чыгып утыра. Яшь чагында төнге өчләргә кадәр эшли иде. Кайчакта чыгып алам: «Туңасың, әйдә, кер», – дим. Шул тимер-томырлары белән җенләнгән.

– Әтиегез дә шулай төне буе эшләп утыра идеме? – дим Әлфия апага.

– Әйе. Улниләр генә ясамый иде. Маратка бүләк итеп биргән тимер кул эшләнмәләре әле дә бар. Бабай мирасы, дип саклап тора.

– Марат абый,ә сез тимер эшен берәрсенә өйрәтеп калдырасызмы соң? – дим.

– Теләк бар да, өйрәнүче юк. Авыл малайлары килеп карады үзе, әле алдырып китмәделәр. Алга таба булса гына...

КАРТЛЫК НИЧӘДӘ БАШЛАНА?

Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы Илдар Һадиуллин, аның ярдәмчесе Алсу Илдарханова белән авылны карап чыктык. Берсеннән-берсе төзек йортлар.

– Бездә халык ашамаса ашамый, тик йортҗирен күршесенекеннән ким итми, – ди җирлек башлыгы.

Иң кызыгы – ике йортның берсендә ниндидер шөгыль иясе яши.

Җирле җитәкчеләр безне Саҗидә апа Галиева янына алып керде. Авылның атаклы чәкчәк пешерү остасы ул. Тагын әле матур җырлый да. Аның турында: «Авылның сандугачы», – диделәр. Киләсе февральдә сиксән яшен тутыра икән.

– Саҗидә апаның табагын кыстырып урам буйлап барганын күрсәк, кемдә мәҗлес була икән, дип карап калабыз, – ди Алсу апа.

– Ә табакны ник үзегез белән аласыз? – дим.

– Кул өйрәнгән. Зур ул, эшләргә җайлы.

Саҗидә апа чәкчәк пешерергә әнисеннән өйрәнгән. Дөрес, бу татлы ризыкны ашап үсмәгән ул. Дөньялар тынычланып, тормышлар җайлангач кына, чәкчәк пешерүгә ихтыяҗ барлыкка килгән.

– Мин туганда эти сугышта булган, – дип сөйләде Саҗидә апа. – Әни безне бик авырлык белән генә үстерде. Шөкер, этине күрү бәхетенә ирештек – сугыштан исән кайтты. Тик бик каты җәрәхәтләр алган иде, озак яшәмәде ул, вафат булды. Җиде баладан бер мин исән бүген.

Саҗидә апа ялгызы көн күрә. Кырык биш ел гомер иткән ире мәрхүм булган. Хәер, дүрт баласы да гаиләләре белән якында гына яши. Өч кызның икесе – Сарманда, берсе – Чаллыда, улы Җәлил бистәсендә гомер итә. Төп йортка гел кайтып йөриләр.

– 1960 нчы еллар башында мин фермада эшли идем, – диде авыл тарихы турында сорашкач, Саҗидә апа. – Озак та үтмәде, Сәрвәров фамилияле кеше колхоз рәисе булып килде. Ул чорларда кешеләр ипигә Сарманга йөрде. Анда чират торып, колхозчылар эшкә соңга кала иде. Шуннан Сәрвәров берәр капчык он бирде. И, шуңа сөенгәннәр! Халык шатлыктан күз яше белән елады! Бер уч онга тилмергән кеше өчен бер капчык он хыял бит ул! Менә шуннан халык азрак тернәкләнеп китте. Колхоз аякка баскач, безгә Дамир Әхмәтов исемле җитәкчене китерделәр. Ленин ордены иясе, бик абруйлы җитәкче иде. Менә шуннан соң колхоз ныклап аякка басты. 1969 елны инде йортларга газ керде.

Саҗидә апа без килешкә авызда эри торган чәкчәген пешереп куйган иде. Тәмлелеге... Заман үзгәрү белән әнисеннән калган рецептка яңалык керткән – чәкчәккә дигән йомырканы башта туңдыра икән. Элек төшләрне туң майда пешерсәләр, хәзер сыек майга салалар.

– Дөрес, сыек майга азрак туң май да кушам, – дип аңлатты Саҗидә апа.

Мортыштамакның тагын бер уңган хуҗабикәсе белән таныштык – Илүзә Фәррахова. Аның кул эшләрен күреп шаккаттык!

– Миңа алтмыш өч яшь тулды, – ди Илүзә апа. – Чигү, бәйләү, тегү эшләре яшьтән килә – әнием өйрәтте. Ә менә изолон, фоамираннан чәчәкләр, букетлар ясау белән соңгы елларда гына шөгыльләнәм. Хәзер бит Интернетта барысы да бар. Теләге булган кешегә өйрәнергә бик ансат.

Илүзә апа кәрзинле чәчәкләрдән башлап зур яктырткычларга кадәр ясаган. Заказга да эшли икән. Чәчәкләр ясау өчен чимал – изолон, фоамиранны сатып ала. Аның нинди генә төсләре юк.

– Изолонны кисәргә, ябыштырырга да бик җайлы, – ди хуҗабикә. – Юарга да рәхәт. Чәчәк бәйләмнәрен кран астына тыгып алам да, бер тузан да калмый.

Илүзә апаның чигүләре турында да әйтми кала алмыйм – мендәр тышлары, бит сөлгеләре күз явын алырлык. («Чишмә» ансамбленә алъяпкычларны нәкъ менә ул чиккән.) Яшь килennәр заказга да эшләтә икән.

– Балалар үстергәндә чикми торган идем. Зур фаҗига яңадан кулга инә белән җеп алырга этәрде. Егерме бер яшемдә улым вафат булды, – диде Илүзә апа. – Төн йокыларым качты. Азрак онытылыйм дип, чигүгә тотындым. Шуннан инде яңа үрнәкләр өйрәндем. Бүген үземне чигү остасы дип әйтә аламдыр...

Илүзә апаны язмыш нык сынаган – ике улы яшьли мәрхүм булган. Бүген төп юанычы, таянычы – ике кызы, кияүләре, оныклары.

Мортыштамакның тагын бер үзенчәлекле гаиләсе – Гәрәевләр. Ирле-хатынлы Роберт абый белән Галия апа хөрмәткә лаек ветеран укытучылар. Икесе дә спортка мөкиббән. Республика, район күләмендә уздырылган шашка, йөзү ярышларында, спартакиадаларда катнашалар, призлы урыннар яулыйлар. Медаль, грамоталарының исәбе-хисабы юк... Роберт абый – Мәгариф отличнигы, Галия апа – Россия, Татарстан һәм район мәгариф бүлеге биргән күпсанлы мактау кәгазьләре иясе.

...Сәяхәттән соң күңелдә кала торган авыллар була. Мортыштамак шулар рәтендә. Зарлана белмәүче, тырыш, шөгыльле халык яши биредә. Сокландык сезгә, мортыштамаклылар!



12 13 14 Ирле-хатынлы Галия апа белән Роберт абый Гәрәевләр – хөрмәткә лаек ветеран укытучылар.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Фәнүзә Сәлихова, «Киләчәк буыннарга: Мортыштамак авылы тарихы» китабы авторы:

– Мортыштамакта XVII гасырда кеше яшәгәнлеге билгеле. Архив документларында имам-хатыйп Габдерахман Туймөхәммәт улының 1691 елда безнең авылда туганлыгы турында мәгълүмат бар. Икенче ревизия документларында авыл инде бар. Димәк, Мортыштамакка ким дигәндә 500 ел дияргә була.

Сарман районында ике авыл «мортыш» сүзе белән бәйле. Ерак түгел Мортышбаш авылы бар. Менә шуннан безгә Мортыш елгасы агып килә. Авыл Мортышның Минзәлә елгасына койган урынында – тамагында урнашкан. Шуңа күрә дә авыл Мортыштамак дип аталган, дип уйлыйбыз. Китап чыгарган вакытта авылның исеме кайдан килеп чыккан дип, озак эзләндем. Тик кызганыч, конкрет дәлилләр тапмадым.

БӘХЕТЛЕ КЫР

Октябрьнең берничә көнендә Казан футбол уенын көтү кәефе белән яшәде. Россия җыелма командасы «Ак Барс Арена»да футбол буенча дөнья чемпионатының сайлап алу матчында Словакия командасы белән очрашырга тиеш.

Бу вакыйга чын бәйрәмгә әверелде! Үзебезнең җыелманы ипи-тоз белән генә түгел, чәкчәк белән дә каршы алу командандың остазы Валерий Карпинга туган якта иң күңелле мизгел җиңүнең баллы тәмен тату булачакка ишарә кебек тә тоелды. Илебезнең 38 шәһәреннән килгән җанатарларның барабан кагулары, уен һәм уенчыларны хуплап кычкырулары, плакатлар спорт аренасына бәйрәм рухы өстәде. Вип-трибунада билгеле шәхесләр – җаваплы урыннарда эшләүче түрәләрдән алып күренекле спортчылар һәм артистларга кадәр бар иде. Хәтта бу җаваплы көндә җыелма команда өчен җан атарга килүчеләрне көтеп торган каршылыкларга да (стадионга бары тик QR-код буенча гына кертү аркасында, керү урыннарында чират тезелде) карамастан, бәйрәм рухы сүрелмәде. Андый вак уңайсызлыклар уночу мең Россия футболы җанатарының кәефен төшерә алмады. Ике сәгать дәвам иткән футбол бәйрәме вакытында алар, тавышлары карлыкканчы кычкырып, безнең капка янында килеп туган куркыныч мизгелләрдә йөрәкләренә ябышып (кем ничек булдыра ала!), үзебезнекеләр өчен җан атты. Кунаклар футболчысы Милан Шкрыньяр үз капкасына хәлиткеч һәм бердәнбер тупны керткәч, чын күңелдән кул чаптылар.

Ә аннан соң, рефери финал сыбызгысын сызгыртуга, футбол кыры шатлыклы авазларга күмелде. «Ак Барс Арена» стадионы Россия җыелма командасы өчен бәхетле кыр булып чыкты: ул бөтенләй диярлек өмете булмаган очрашуда җиңүгә ирешә.

Фото: «Татар-информ» МА

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Татарстаннан
кайнар сәлам!

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

* Татарстаннан сезне яратып!
(төрекмән теленнән тәрҗемә)